# ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ ӘКИЯТЛӘРЕ



# СКАЗКИ НАРОДОВ ТАТАРСТАНА

# ТАТАРСТАН ХАЛЫКЛАРЫ ӘКИЯТЛӘРЕ

# СКАЗКИ НАРОДОВ ТАТАРСТАНА

Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2016
Казань. Татарское книжное издательство. 2016

УДК 821.1/.8-34
ББК 84(0)-4
Т23

*Издание осуществлено при финансовой поддержке
Федерального агентства по печати и массовым коммуникациям в рамках
Федеральной целевой программы «Культура России (2012 – 2018 годы)».*

Илдус Әҗемов, Айсылу Гарипова, Булат Гыйльванов,
Светлана Ибраһимова, Фәридә Ризаева, Алсу Тимергалина,
Рушан Шәмсетдинов, Ольга Ярикова рәсемнәре.

Иллюстрации Ильдуса Азимова, Айсылу Гариповой, Булата Гильванова,
Светланы Ибрагимовой, Фариды Ризаевой, Алсу Тимергалиной,
Рушана Шамсутдинова, Ольги Яриковой.

Т23 **Татарстан халыклары әкиятләре = Сказки народов Татарстана** / [төз. : Айсылу Галиәхмәтова]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2016. – 223 б.
ISBN 978-5-298-03117-2

Әлеге китапта Татарстанда яшәүче халыкларның йөзек кашы булырдай, буыннан буынга тапшырылып килгән, тарихи хәтерен саклаган, үз милләтенең сыйфатларын чагылдыра торган әкиятләре урын алды.

Сказка как сокровищница народной мудрости, передаваясь из поколения в поколение, отражает историческую память и раскрывает национальные особенности каждого народа. В эту книгу вошли лучшие образцы фольклора народов, населяющих Республику Татарстан.

УДК 821.1/.8-34
ББК 84(0)-4

ISBN 978-5-298-03117-2

© Татарстан китап нәшрияты, 2016
© Татарское книжное издательство, 2016
© Галиәхмәтова А. Ф., төз., 2016
© Галияхметова А. Ф., сост., 2016

*Китапның исемен укып гаҗәпләнгәнсездер, мөгаен? Татарстанда татарлар, руслар, чувашлар, марилар, удмуртлар яши дип җавап та биргәнсездер. Эчтәлектә корея, лезгин, һинд әкиятләрен күреп аптырагансыздыр. Бүген Татарстанда тарихи ватаннары төрле кыйтгаларда булган 173 милләт вәкиле яши, аларның шактые — икенче, өченче буында республикабыз гражданнары. Татарстан — һәммәбезнең уртак йорты.*

*Аларның иң активлары республикабызның шәһәр-районнарында үз милли-мәдәни автономияләрен булдырган. Китаптагы әкиятләр — Татарстан халыклары ассамблеясы каршындагы Милли-мәдәни автономияләр бүләге — янәшәбездәге башка этносларны, аларның иҗатын, мәдәниятен өйрәнүдә бер адым булыр дип ышанабыз.*

*Татарстан — многонациональная республика, где народы живут в дружбе и согласии. Как известно, Татарстан является домом для представителей 173 национальностей. Самые активные из них создали свои национально-культурные автономии. Национально-культурная автономия — это путь к добрососедству между людьми разных наций и разных вероисповеданий.*

*В данную книгу собраны сказки, которые были предоставлены представителями Национально-культурных автономий при Ассамблее народов Татарстана. Надеемся, что наша книга сказок станет маленьким ожерельем в сокровищнице народного творчества.*



# Тылсымлы шәмдәл

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер патша. Аның күзләре сукырайган. Бик күп табиблар килеп караса да, дәвасын таба алмаганнар. Ахырда берсе килеп:

– Падишаһым, күзләреңнән дәва бар, әмма кеше кулы җитмәс җирдә, – дигән.

Патша:

– Син урынын әйт, мин таптырырмын.

Табиб әйткән:

– Ак диңгездә ала балык бар. Аның канын сөртсәң, әүвәлгедән дә яхшырак күрә башларсың.

Табиб сүзләреннән соң патша илдәге бөтен балыкчыларны җыйдыра да улын чакырып әйтә:

– Улым, ала балык эләккәнче беркем дә кайтып китмәсен!

Егет балыкчыларга: «Кем дә кем ала балыкны тотса, бик зур бүләк алачак», – дип игълан итте. Балыкчылар, ятьмәләрен атып, балык тота башладылар. Берзаман бер ятьмәдә ала балык күренде. Егет караса, бу шулкадәр матур балык икән, кеше сәламәт кулын кисәргә кыяр, әмма аны үтерергә кыймас. Балык телгә килде:

– Әй, егет, мине үтермә, вакыты җиткәч, мин сиңа үзем кирәк булырмын.

Шаһзадә: «Табиб ялган сөйләгән булса, әтиемнең күзе дә ачылмас, балыкны да үтереп гөнаһлы булырмын. Бу җан иясен җибәрү яхшырак булыр», – дип уйлады да балыкны дәрьяга атты. Соңра балыкчыларга әйтте:

– Әгәр берәр кеше бу серне ачса, башын тәненнән аерачакмын.

Балыкчылар, бу серне ачмабыз, дип ант эчтеләр. Егет, аларга хезмәт хакын биреп, юлга чыкты. Кайтып атасы янына килде дә:

– И атам, диңгездәге бөтен балыкны тотып бетерсәк тә, ала балыкны таба алмадык.

Гөнаһ шомлыгына, патшага беркөнне килеп хәбәр бирделәр: «Әй патша, балыкчылар синең күзеңнең дәвасы – ала балыкны тотканнар иде, ләкин улың аны ятьмәдән чыгарып диңгезгә ташлады».

Патша, бу сүзне ишетүгә, улының башын кисәргә боерды.

– Ул, тизрәк үлүемне теләп, тәхетемә хуҗа булмакчы иде. Миннән алда үлсен! – дип, бик ачуланды.

Вәзирләре, аксакаллар, карасакалларның: «Ялгышма, улыңны үтермә, сөргенгә җибәр», – дип ялваруларына бераз йомшап, улын илдән чыгарып җибәрергә боерды.

Шаһзадә шул көнне үк юлга чыкты. Ак диңгез яныннан узып бара иде, юлда бер егеткә тап булды. Егет сорады:

– Кардәш, кая киттең?

Шаһзадә:

– Үзем дә белмим. Аягым кая барса, башым да шунда бара.

Егет әйтте:

– Алайса, мин дә синең кебек икән. Юлдаш булыйк.

Патша улы әйтте:

– Әйдә, дуслар гына түгел, туганнар булыйк.

Икәү, дуслашып, юлга кузгалдылар. Бераз киткәннән соң, теге егет шаһзадәдән сорап куйды:

– Соравымны гаеп итмә, кардәш. Нинди һөнәрең бар?

– Бер һөнәрем дә юк шул.

– Борчылма, мин – бик яхшы табиб. Шәһәрләрне, авылларны гизик, ни казансам, синең белән урталай бүләрмен. Шулай яшәрбез.

Хәйран юл үтеп, бер шәһәргә җиттеләр болар. Әлеге шәһәр патшасының кызы телсез калган, имеш. Җиде ел сөйләшми икән. Патша: «Кем дә кем кызымның телен ачса, кызымны аңа бирәчәкмен, ача алмаса, башын кисәчәкмен», – дип игълан иткән, имеш. Бик күп табиблар килсә дә, һичбер чара күрә алмыйлар, ди.

Табиб егет белән шаһзадә икәүләп патша янына баралар. Әдәпле итеп башын игәч, табиб әйтә:

– Мин кызыңның телен ачарга килдем.

– Әй егет, сиңа кадәр кырык табиб килде, берсе дә кызымны терелтә алмады. Һәммәсен үтерттем. Сине кызганам, юлыңда бул.

Егет әйтте:

– Патша исән булсын! Үлгән табиблардан артык җирем юк. Кызыңның телен ача алмасам, үтерерсең. Рөхсәт ит, дәвалап карыйм.

Табиб, юлдашын да алып, кыз янына кереп китте. Патша, вәзирләрен ияртеп, боларны күзәтергә ашыкты. Табиб, кыз янына керсә дә, аңа һич сүз катмады. Бүлмәдә якутлар белән бизәлгән матур алтын шәмдәл тора икән. Шәмдәлгә борылып болай диде:

– Исәнме, әй алтын шәмдәл!

Бу шәмдәл кызга әнисеннән калган ядкяр, кыз аны үзеннән артык сөяр иде. Чынында исә кыз, әнисе үлгәннән соң, җиде ел беркем белән дә сөйләшмим дип ант эчкән булган.

Табиб егет дәвам итте:

– Әй алтын шәмдәл! Бу кичтә мин – синең кунагың. Бер әкият сөйләрмен, ә син мине тыңла да җавап бир. Әй алтын шәмдәл, көннәрдән бер көнне бер тегүче, балта остасы һәм табиб, юлдаш булып, юлга чыгалар. Беркадәр үткәч, урманда төн кунарга туктыйлар. Йокылары килә. Бергәләп йокласалар аю-бүре зыян салыр дип, чиратлашып йокларга булалар. Шобага салалар болар. Беренче булып кизү торырга балта остасына төшә. Осталыгын күрсәтү нияте белән, тегеләр йоклаган чакта, агачтан бер кыз сынын юна да йокларга ята. Чират тегүчегә җитә. Тегүче матур сынны күрә дә, бер күлмәк тегеп, кызны киендерә. Таң якынлашканда, тегүчене табиб алыштыра. Ул да, үз һәвәслеген күрсәтер өчен, агачтан юнылган кызга дару биреп, аңа җан өрә. Иртән торгач, балта остасы әйтә:

– Бу кызны, агачтан юнып, мин ясадым. Кыз минеке!

Тегүче әйтә:

– Мин аңа күлмәк тектем, ул минеке!

Табиб әйтә:

– Аңа җанны мин бирдем, ул минеке булырга тиеш!

Өч юлдаш кыз өчен дәгъвалаша башлыйлар. Инде әйт, алтын шәмдәл, ул кыз өч юлдашның кайсысына булырга тиеш?

Алтын шәмдәл җавап бирмәгән.

Егет әйтте:

– Әй алтын шәмдәл, җавап бир, юкса сиңа бер агач белән шундый итеп орырмын, кырыкка ярылырсың!

Җансыз шәмдәл ничек җавап бирсен инде! Егет шәмдәлне ватарга дип кизәнгәндә, кыз түзә алмый, телгә килә:

– Әй егет, шәм сөйләшәмени? Аннан сорама, миннән сора.

Егет:

– Әйт, алайса.

Кыз:

– Балта остасына, тегүчегә хакын түләргә кирәк. Кызга җан биргән табибтыр, җанны акчага сатып алып булмый. Димәк, кыз табибка булырга тиеш.

Патша һәм аның вәзирләре, кызның тавышын ишетеп кереп, егеткә рәхмәт укыдылар. Патша, вәгъдә ителгәнчә, кызны егеткә бирмәкче иде, егет, үзенең гаиләсе булганын аңлатып, аны дусты шаһзадәгә бирүен үтенде.

Егет, шаһзадә, патша кызы – өчәү бергә юлга чыктылар, Ак диңгез ярына килеп җиткәч, кыз сорап куйды:

– Әй егет, син, хәйлә белән мине сөйләштереп, антымны боздырдың. Беләсем килә, сез кемнәр, мине кая алып барасыз?

Табиб әйтте:

– Мин – балыклар патшасының улы. Ак диңгездә йөзгәндә, балыкчылар ятьмәсенә эләктем. Каным патша күзләренә дәва иде. Бу егет миңа тимәде, кире

җибәрде. Мин сине бирнәләрең белән бергә шушы егеткә багышладым. Бүгеннән син – минем сеңлем, шаһзадә киявем булыр. Кирәгем чыкса, Ак диңгез ярына килеп, мине чакырыгыз.

Шуннан соң егет бармагын кисеп берничә тамчы канын шешәгә салды да патша улына бирде:

– Атаңның күзенә сөрт, күзләре ачылыр.

Табиб алар белән саубуллашты, диңгезгә чумып балыкка әйләнде дә күздән югалды.

Шаһзадә кызны үз шәһәренә алып кайтып китте. Әти-әнисе белән күрешеп, балык канын әтисенең күзләренә сөртте. Патшаның күзләре ачылды.

Патша, шәһәрне бизәтеп, зур бер мәҗлес ясады. Улын, кызылдан киендереп, үз урынына тәхеткә менгерде. Кырык көн, кырык төн туй ясадылар.

Икәү бәхетле гомер кичерделәр. Сез дә шулай бәхетле гомер кичерегез!

# Волшебный подсвечник

Жил-был слепой шах. Никто его не мог вылечить. Однажды появился во владениях шаха новый лекарь, осмотрел глаза правителя и говорит:

– Я знаю лекарство для твоих глаз. Но до него не достанет рука человека.

Шах так обрадовался, что даже подскочил на троне.

– Ты только скажи, где найти его, а уж я пошлю кого-нибудь за ним хоть на край света.

– Что ж, попробуй, – ответил врач. – В белом море водится пятнистая рыба. Если сделаешь примочки к глазам из крови этой рыбы, то прозреешь.

Только вымолвил врач эти слова, шах приказал трубить в трубы и созвать всех рыбаков, а затем позвал сына и сказал ему:

– Сын мой и наследник трона, бери рыбаков и отправляйся с ними на берег белого моря. Пусть выловят они всю рыбу, пока не попадётся та самая, пятнистая.

И отправился сын шаха с рыбаками к белому морю. Тому, кто выловит пятнистую рыбу, обещали дорогие подарки. Стали рыбаки забрасывать сети в море. Почти всю рыбу выловили. Наконец блеснула в одной сети пятнистая рыба. Поглядел на неё сын шаха, да так и замер. До того прекрасна была рыба, что легче было отрубить собственную руку, чем её голову. С болью в сердце поднял юноша меч, но вдруг рыба заговорила человечьим голосом:

– О прекрасный юноша, пощади меня, не губи! Придёт время, я сослужу тебе службу.

Задумался юноша: «А что, если врач солгал, и отец всё равно не прозреет. А рыба так прекрасна и так молит. Отпущу-ка я её на волю». И он бросил рыбу обратно в море, а затем повернулся к рыбакам и сказал:

– Тот, кто осмелится открыть эту тайну шаху, останется без головы.

Рыбаки поклялись хранить тайну до гроба. Юноша щедро заплатил им за их труды и отпустил по домам. Вернувшись во дворец, он сказал отцу:

– Как мы ни старались, не смогли выловить пятнистую рыбу.

Шах огорчился, слёзы выступили на глазах, и от этого глаза разболелись ещё сильнее.

Прошло время. Однажды явился к шаху доносчик и сообщил, что пятнистую рыбу, чья кровь была лекарством для его глаз, поймали, но сын нарочно бросил её обратно в море.

Страшно разгневался шах, ни секунды не медля, приказал отрубить сыну голову.

– Мой сын должен умереть, – твердил он, – он пожелал моей смерти, чтоб добиться власти.

Сбежались везир, советники, пали к ногам шаха, умоляя пощадить сына, не убивать. Шах смягчился, приказал сыну покинуть его владения и никогда больше здесь не появляться.

Разгневанный отец не дал ему ни коня, ни слуги, даже еды на дорогу. Долго шёл он, наконец дошёл до берега белого моря. Тут повстречался ему юноша. Незнакомец сказал:

– Как вижу, друг, идём мы с тобой в одну сторону. Так пошли же вместе, будем попутчиками.

Сын шаха истомился в тоске и одиночестве. Потому он очень обрадовался.

– Не только попутчиками, давай будем братьями. – Обнялись они крепко и продолжали путь вдвоём.

Пройдя немного, юноша спросил:

– Не сочти за любопытство, братец, но что ты умеешь делать?

Сын шаха грустно ответил:

– Ничего я не умею, только ездить на коне да стрелять из лука. Но ни того ни другого у меня теперь нет.

– Ничего, – утешил его юноша, – не печалься. Я врачую людей. Будем ходить по городам и деревням. Всё, что я заработаю, поделим пополам, как-нибудь проживём.

Наконец они добрались до большого города, где правил шах, у которого была одна-единственная дочка. Вот уже семь лет она не разговаривала. И шах поклялся, что тот, кто вернёт его дочери дар речи, станет её мужем. Но если возьмётся кто-нибудь лечить её и не вылечит – не сносить ему головы.

Каждый день во дворец приходили врачи, старые и молодые. Все они мечтали получить в жёны дочь шаха, но никто не мог её вылечить и головы одна за другой катились с плеч.

Юноша-врач, услыхав это, взял своего спутника за руку и отправился прямо во дворец к шаху.

Поклонившись низко, он сказал:

– Я пришёл исцелить твою дочь, о великий шах.

Шах сказал:

– О добрый человек! До тебя сюда приходило сорок врачей и никто не смог вылечить мою дочь. Всех их я велел убить. Мне тебя жаль. Ты красив и смел, но если

ты не сможешь её вылечить, мне придётся тебя убить. А я этого не хочу, лучше уходи.

Но юноша был настойчив:

– Чем я лучше тех, кто умер? Если я не смогу её вылечить, вели меня казнить. Только разреши войти к девушке.

Шах разрешил. Тогда врач снова взял за руку своего попутчика и брата и пошёл к девушке. Шаха разобрало любопытство, почему этот врач так настаивал на своём. Позвал он везира и советника, отправились они втроём к покоям девушки, спрятались в укромное место и стали подслушивать. Врач вошёл к девушке, но не сказал ей ни слова. Вместо этого он обратился к золотому подсвечнику, усыпанному драгоценными камнями:

– О золотой подсвечник, здравствуй!

Этот подсвечник был очень дорог девушке. Он остался на память от умершей матери. Девушка очень любила свою мать и после её смерти поклялась, что семь лет не будет ни с кем разговаривать. Она притворилась немой, и поэтому ни один врач не мог заставить её заговорить. А юноша, поздоровавшись с подсвечником, продолжал:

– О золотой подсвечник, сегодня ночью я твой гость. Я расскажу тебе сказку, а ты слушай и отвечай мне.

И он начал свою сказку.

– В один прекрасный день портной, столяр и врач шли по дороге. Шли они долго, и в лесу их настигла ночь. Им очень хотелось спать, но они подумали, что если заснут все трое, их могут растерзать звери. Поэтому они решили спать по очереди. Бросили жребий. Первое бдение выпало столяру. Взял он пилу, рубанок и выстрогал из дерева фигуру девушки, чтобы утром показать спутникам, какой он мастер. Настало время будить портного. Портной обошёл вокруг, убедился, что всё спокойно, и хотел присесть у костра, но тут увидел, что какая-то девушка прислонилась к дереву. Портной подошёл поближе и только тогда разобрал, что это деревянное изваяние. Понял он, что столяр во время бдения своего выстрогал её. Захотелось портному тоже показать свои способности. Достал ножницы, иголку с ниткой, сшил красивое платье и надел на девушку. Под утро настала очередь бдеть врачу. Увидел и он, что какая-то девушка стоит, прислонившись к дереву. Пригляделся юноша, понял, что она деревянная, и тут же догадался, чьих рук это дело. Тогда, чтобы показать своё умение, врач влил в девушку зелье и оживил её.

Наступило утро. Все проснулись. Столяр сказал: «Эту девушку из дерева выстрогал я, поэтому она моя». Но портной возразил: «Я сшил ей платье, значит, она моя». Третьим в спор вступил врач: «Я вдохнул в неё жизнь, она должна принадлежать мне».

Так они спорили. А ты, золотой подсвечник, скажи, пожалуйста, кому из трёх должна принадлежать девушка?

Подсвечник молчал.

Юноша снова спросил:

– О золотой подсвечник, отвечай, иначе я разобью тебя на мелкие кусочки.

Подсвечник молчал. Юноша отступил назад, размахнулся и хотел ударить по подсвечнику, но тут девушка не выдержала и заговорила:

– О юноша, разве подсвечник может говорить? Не разбивай его. Я отвечу вместо него.

– Ну, говори, – согласился врач. – А я послушаю, правильно ли ты отгадала.

Девушка сказала:

– Что касается столяра, он потрудился и должен получить за свои труды. Портному нужно уплатить за сшитое платье. Но жизнь девушке дал врач, а жизнь нельзя купить ни за какие деньги, поэтому девушка принадлежит врачу.

Шах, везир и советник из своего укрытия слышали и видели всё это. Они вошли в комнату и стали благодарить юношу, шах сказал:

– Я обещал, что отдам свою дочь в жёны тому, кто её вылечит. Теперь она твоя.

Поклонился врач шаху и ответил, что у него есть жена и дети.

– Тогда выдай её за кого хочешь, она твоя.

Сказав так, шах дал дочери большое приданое, много слуг, рабынь и отдал дочь врачу. И пошли они втроём – врач, сын шаха и девушка. Пришли на берег того самого белого моря. И тут девушка вдруг сказала:

– О врач, ты применил хитрость, чтоб заставить меня нарушить обет. Ответь мне, кто ты такой и куда ведёшь меня?

– Я сын шаха всех рыб, могу стать кем угодно. Однажды я плыл по этому морю, рыбаки поймали меня, потому что моя кровь понадобилась в качестве лекарства для слепого шаха. Этот юноша, сын того самого шаха, не убил меня и отпустил в море. Я поклялся помочь ему когда-нибудь. Теперь я дарю ему тебя со всем твоим приданым, слугами и рабынями. С сегодняшнего дня ты – моя сестра, а сын шаха – мой зять. Когда вам что-нибудь понадобится, приходите к белому морю, позовите меня, я тут же появлюсь. – Сказав это, юноша надрезал себе палец, налил в сосуд несколько капель крови, отдал сыну шаха и добавил:

– Отнеси это своему отцу, пусть протрёт глаза. Он сразу прозреет и простит тебя. – Юноша обернулся рыбой и нырнул в море.

А сын шаха с девушкой пришёл во владения своего отца, поклонился ему и протянул сосуд. И шах прозрел. Тогда простил он сына и, отдав ему свои красные одежды, посадил на свой трон. Сорок дней и сорок ночей играли свадьбу молодого шаха. А потом он жил со своей женой сорок лет да ещё сорок сороков.

# Аю Һанс

Күп еллар элек нарат урманында хатыны белән ярлы күмерче яшәгән. Аларның Һанс исемле уллары булган. Малай сабый вакыттан ук көче белән әти-әнисен таң калдыра торган була: бервакыт көчекләр белән уйнаганда, кысып кочаклап чак кына үтерми кала. Әти-әнисе орыша орышуын, Һансның көченә эчтән генә горурланалар да.

Шушы ук урманда ике баласы белән аю да яши. Балаларын аучылар алып китеп, ана аю ялгызы кала. Шундый көннәрнең берсендә, кайгысыннан үкереп урманда йөргәндә, Һансны очрата ул.

Балаларын алып киткән явыз кешеләрдән үч алам дип, Һансны тотып ашамакчы була да, ни хикмәт, нәни малай аюдан курыкмый, бер яшь агачны кубарып ала да аю белән тарткалаша башлый. Аю аның көченә шакката. «Туктале, – ди ул, – үземә алып китеп тәрбиялим әле мин моны. Картаймыш көнемдә таянычым булыр». Аю, Һансны сак кына күтәреп алып, өненә кайтып китә.

Өненә алып кайтып, Һансны үз балаларының йомшак түшәгенә сала. Ана аюның йомшак кына ырлавына малай тынычланып йокыга китә. Иртәгәсен күзен ачса, аю тәпиләренә яңа җыйган җиләк тотып утыра, ди. Ашап, сөт эчеп алгач, малайның кәефе күтәрелеп китә, ул әнкә аю белән уйный башлый, йоннарын чуалта, колакларын чәбәкли.

Һансны бераз уйнатып алгач, аю янәдән азык эзләргә китә, китәр алдыннан өнне зур таш белән капларга онытмый.

Вакыт уза, Һанс та үсә. Бервакыт, бал йә симезрәк куян тотып кайтырга дип аю урманга чыгып киткәч, малай ташны кузгатмакчы була. Ничек кенә тырышмасын, таш бирешми. Аю, кайткач, ташның урыныннан купканын күреп, Һанска усал итеп карап куя. Икенче юлы чыгып киткәндә өнне зуррак таш белән терәтә. Һанс көч җыйганчы качу уеннан кире кайта. Көннәр, айлар уза, Һанс үсә, көч җыя. Үз көченә тәмам ышанып җиткәч кенә, аю төшке аштан соң урманга чыгып киткәч, малай, өнне каплап торган ташны этеп, өннән чыга. Ә урманда шундый матур! Тирә-як ямь-яшел урман, кошлар сайрый. Һанс, аюның әйләнеп кайтуыннан куркып, өннән ераккарак йөгерә.

Чаба торгач, күмерче йортына килеп җитә. Кичкә каршы капка бикле икән. Малайны кызганып, өйләренә чакыралар. Һанс исендә калган кадәр башыннан үткәннәрне сөйләп бирә. Күмерче белән аның хатыны, малайны тыңлый-тыңлый, югалган улларын искә төшереп утыралар. Ахырында аның иңбашындагы миңне күргәч, Һансның нәкъ менә үз уллары икәненә шикләре калмый.

Күпмедер вакыттан соң Һанс, әти-әнисеннән рөхсәт алып, ил гизәргә чыгып китә. Туйганчы сәяхәт иткәннән соң, бер бай крестьян утарына килеп чыга. Озак та уйлап тормый егет, хуҗага эшкә яллана. Бакчада алмалар өлгергән чак була бу, Һансны агач селкетеп алма коярга җибәрәләр. Егетнең агачны селкетәм дип тотынуы була, алмалар ботагы-ние белән килеп төшә. Хуҗа килеп караса, алмагач ботаклары җирдә ята, Һанс:

– Хуҗа, карагыз әле, агачларыгыз картаеп беткән бит, аз гына селкетүгә дә сынып чыктылар! – ди.

Хуҗа алмагачын сындырган өчен орышкан да Һансны урманга агач кисәргә җибәргән. Һанс хуҗа биргән балтаны алып та тормаган, бер чылбыр әләктергән дә урманга киткән. Чылбыр белән агачны әләктереп ала икән дә аудара икән бу. Шулай итеп кичкә кадәр ярты урманны ауарган. Хуҗа эшчеләре белән килеп караса, әллә никадәр агач егылган, ди. Болар, сиңа бу хәтле көч каян килде, дип сорый башлаганнар.

Һанс башыннан кичкәннәрне сөйләп биргән дә, ике юан агачны култык астына кыстырып, ашыкмыйча гына кайтып киткән. Калганнар тамыры-ние белән кубып чыккан агачларны арбага урнаштыра алмыйча бик озак җәфаланганнар.

Күп тә үтми, бөтен тирә-якта Һансны аю урлаганы, аю тәрбияләп үстергәне хакында сүз таралган, аны Аю Һанс дип йөртә башлаганнар. Хуҗа белән башка эшчеләр, Һанстан куркып, аның үзен юкка чыгарырга план корганнар.

Хуҗа беркөнне килгән дә:

– Һанс, карале! Түти миңа атамны безнең коега байлык күмеп калдырган дип сөйләгән иде. Коеның суы бетте, шунда төшеп кара әле, – дигән.

Егет коега төшеп эшкә керешүгә, хезмәтчеләр аңа таш ата башлаган. Башта ул игътибар итмәгән, ташлар күбәя башлагач, түземлеге төкәнеп:

– Әй, кем анда, – дип кычкырган, – кое тирәсеннән тавыкларны куыгыз әле, ком тутыруларыннан туктамасалар, хәзинәгезне гомеремдә дә таба алмыйм.

Берзаман Һанс өстенә тегермән ташы килеп төшкән. Ул аны муенына киеп куйган да:

– Мине поп итмәкче буласызмы әллә? Шундый киң поп якасы ташламасагыз! – дип кычкырган. – Яле, тартып чыгарыгыз яхшы чакта!

Шулай дип, муенындагы тегермән ташын өскә ыргыткан. Хуҗа яхшы чакта мондый көчле кеше белән саубуллашу хәерлерәк дип, эшләгәне өчен күп итеп алтын биреп, аны озатырга ашыккан.

Һанс, төенчеген асып, юлын дәвам иткән. Юлда барганда, аңа очраган бер кеше король кызы турында сөйли, ди. Имеш, бер алпамша аңа яучы җибәргән, ә кыз



кияүгә чыгарга теләми. Король бик кайгыра икән, алпамшаны җиңгән кешегә кызын да, ярты байлыгын да бирергә вәгъдә итә, ди.

Моны ишеткән Һансның, күз кырые белән генә булса да, принцессаны күрәсе килгән. Сарай янына килеп кызны күрү белән, аңа гашыйк булган һәм инде өч батыр рыцарьны җиңәргә өлгергән алмапша белән алышка чыккан.

Һансны күргән алпамша, үзенең җиңәчәгенә шикләнмичә, аннан көлә башлаган:

– И адәмчек, син дә минем белән алышырга килдеңме? Әйдә, иң элек минем кылычымны күтәреп кара, аннары үзеңнекен тотарсың!

Алпамша кылычын биленнән алган да җиргә ташлаган. Һанс кылычны бер кулы белән генә тотып алган да бер читкә ыргыткан, кылыч тоткасына кадәр җиргә батып кергән. Моны күргән алпамша, егетне үгетли башлаган:

– Мондый сугышчыны очраткан юк иде, әйдә, килешик, мин сиңа алтын бирәм, ә син кызны миңа калдырасың, мин аны бик яратам.

Һанс алпамшаны тыңлап та тормаган, принцесса аның өчен дә бик кадерле булган шул, кынысыннан кылычын чыгарып, сугышырга әзерләнгән. Бик каты сугышканнар алар, һәм, ниһаять, Һанс кылычы белән алпамшаның башын өзеп төшергән. Алпамшаның кара каны яшел үләнне каплаган. Һанс, алпамшаның башын күтәреп, сарайга юнәлгән.

Килеп керергә дә өлгермәгән, Һансның каршына король йөгереп чыккан:

– Рәхмәт сиңа, улым! Принцесса да, ярты патшалыгым да синеке!

Принцесса да бик сөенгән, Һансны ошатып өлгергән булган инде ул. Карт король үлгәннән соң, Һанс король булып кала. Көннәрнең берсендә ул яшь хатыны белән әти-әниләренең хәлен белергә бара.

Урман эчендәге кечкенә генә йортның капка төбенә алтынланган карета килеп туктагач, өйдәгеләрнең гаҗәпләнгәннәре! Ә корольнең үз уллары, аның хатыны принцесса булуын белгәч, бигрәк тә шатланганнар. Һанс аларны каретага утырткан да аю өенә алып киткән.

Килеп җиткәч, Һанс каретадан сикереп төшкән дә, аю өенә кереп киткән. Мескен аю үлем хәлендә түшәгендә ята икән. Ул каты авырый, көче бетеп, үзенә азык таба алмаслык хәлгә килгән. Һанс килеп җитмәсә, ачтан да үлеп китәр иде. Һансны күреп, аю урыныннан кузгалырга талпынган, хәле булмагач, торып китә алмаган. Ганс хезмәтчеләренә ризык кертергә боерган һәм аюны тәрбияли башлаган. Аю, рәхмәтле күзләре белән карап, Һансның кулларын ялый икән, гүя: «Менә, тәки көтеп җиткерә алдым бит, соңгы минутларымда янымда син, юкка гына үстермәгәнмен», – ди.

Аю бик картайган булган шул инде, Һанс алып килгән азык-төлек кенә аның гомерен озынайта алмаган. Ул корольгә соңгы тапкыр карап алган да җан биргән.

Аюны меңьяшәр имән төбендә җирләгәннәр.

Аю Һанс, якыннарын үз янына алып, гүзәл хатыны белән бик озак еллар гадел патшалык иткән.

# Ганс-медведь

Много лет назад в сосновом бору жил бедный угольщик со своей женой; у них был ребёнок, звали его Гансом. Мальчик в самом младенчестве очень удивил своих родителей, показав необычайную силу; однажды ему дали трёх щеночков поиграть, так он их затискал до смерти. Родители побранили его за такую проделку, но в душе радовались его чудесной силе и тому, что у них растёт такой богатырь.

В том лесу жила большая медведица с двумя медвежатами, да как-то раз попались они охотникам, и осталась медведица одна. От горя медведица никак не могла утешиться, она бродила по лесу и ревела от тоски. И вот однажды медведица набрела на домик угольщика, а перед домом играл на травке маленький Ганс.

Увидела медведица малыша и захотела отомстить злым людям, которые отняли её медвежат; она бросилась на маленького Ганса, чтобы съесть. А Ганс не испугался, выдернул с корнями молодое деревце и начал храбро отбиваться. Подивилась медведица его силе и храбрости. «Дай-ка, – думает, – утащу мальчонку к себе в берлогу, вспою его своим молоком, он станет сильным, как медведь, и будет мне вместо моих медвежат на старости лет кормилец и защитник». Старая медведица осторожно взяла Ганса передними лапами и, как он ни кричал и ни брыкался, уволокла его к себе домой.

Придя в берлогу, она уложила мальчика на мягкую постельку своих детишек, распушила подстилку, и под её ласковое ворчание Ганс успокоился, усталость сморила его, и он заснул.

Утром он открыл глаза, а медведица уже тут как тут, сидит рядом и протягивает ему в лапах горсть свежей лесной земляники, которую успела набрать спозаранку; накормив мальчика, она дала ему попить своего молока; подкрепившись, маленький Ганс повеселел и стал играть с медведицей, хлопать её ладошкой и трепать за кудлатую шерсть, радуя свою кормилицу.

Поиграв с мальчиком, медведица снова отправилась в лес, но, перед тем как уйти, завалила вход в берлогу громадным камнем, и Гансу волей-неволей пришлось просидеть взаперти до её возвращения.

Время шло, Ганс подрастал и набирался сил, медвежье молоко шло ему впрок. Однажды, когда медведица ушла в лес, чтобы раздобыть себе на завтрак сладкого мёду или изловить жирного зайца, Ганс изо всей силы упёрся плечом в камень, но, сколько ни старался, камень почти не сдвинулся. Медведица вернулась и увидела, что камень лежит не на месте; она сердито посмотрела на Ганса и в следующий раз, перед тем как уйти, навалила перед входом побольше камней. Пришлось мальчику набраться терпения, потому что сдвинуть камни он всё равно бы не смог, а ещё он побаивался, как бы медведица не разозлилась, если во второй раз увидит, что он вместо благодарности за её заботу хотел от неё сбежать. Потом он ещё подрос и почувствовал наконец, что теперь ему хватит сил раскидать все камни; он больше не хотел сидеть взаперти. Дождавшись, когда медведица уйдёт после обеда в лес, он упёрся в камень, поднатужился… и рассыпал камни в разные стороны. Наконец-то Ганс выбрался на волю! Перед ним раскрылся зелёный лес, над головой заливались звонкими трелями весёлые птички. Ганс боялся, что медведица его поймает и снова загонит в берлогу. Поэтому он со всех ног пустился бежать и бежал без оглядки, пока не прибежал к домику угольщика.

Дело было вечером, угольщик уже воротился из леса, они с женой отдыхали, дверь была закрыта. Ганс постучался, хозяева пожалели его и впустили. Мальчик рассказал им свою историю, насколько сам её помнил. Угольщик и его жена хорошенько рассмотрели гостя и, как только заметили у него на плече чёрную родинку, поняли, что вернулся их сын, который так долго пропадал!

Ганс долго жил с родителями, и не один раз пересказал им свою историю. Наконец ему наскучило сидеть дома, и вот однажды он им и говорит: «Хочу попутешествовать». Родители перечить не стали, он собрал котомку и в одно прекрасное утро пустился в дорогу.

Вдоволь настранствовавшись, он набрёл на богатую крестьянскую усадьбу; недолго думая, попросился к хозяину в работники. Тот увидал, что парень он крепкий и сильный, и согласился. В ту пору в саду как раз поспели яблоки, и на другой день Ганса послали отряхивать деревья. Принялся Ганс за дело, да как начал трясти, все ветки пообломились и вместе с яблоками упали на землю; пришёл хозяин поглядеть, как новый работник потрудился, а Ганс ему и говорит:

– Гляньте-ка, хозяин, какие у вас в саду деревья старые и ломкие: я немного потряс, а ветки с яблоками на землю попадали!

Хозяин стал его бранить за то, что он поломал его лучшие яблони, да и послал Ганса от греха подальше в лес рубить деревья. Хозяин дал Гансу хороший, острый топор. А Ганс на топор даже не посмотрел, а подыскал себе железную цепь потолще. Обвяжет цепь вокруг дерева, повалит его и за другое принимается.

Хозяин и его работники пришли вечером, увидели, что он половину леса повалил, и стали спрашивать Ганса:

– Откуда у тебя столько силы, что ты за один день проделал такую работу, с какой нам и вдесятером-то за сто дней не управиться?

А Ганс поведал им о своей жизни. Потом он взвалил себе на плечи два толстенных дуба и не спеша отнёс их домой. А люди ещё долго пробыли в лесу, потому что никак не могли сложить на телеги поваленные вместе с корнями деревья.

Весть об этом происшествии скоро распространилась по всей округе, и с тех пор Ганса за его медвежью силу и за то, что его вскормила медведица, прозвали Гансом-медведем.

А хозяин усадьбы и его работники так стали бояться Ганса, что только и думали, как бы от него избавиться, но, как ни старались, ничего не выходило. Собрались и тайно сговорились на злое дело: надумали они Ганса со свету сжить, не дожидаясь, когда от него беда стрясётся.

По общему совету хозяин пошёл к Гансу и говорит:

– Послушай, Ганс! Моя тётка сказала мне по секрету, что её отец зарыл в моём колодце богатый клад, а нынче колодец пересох от жары; полезай-ка ты в колодец, гляди, и откопаешь сокровище.

Ганс исполнил его приказание и полез в колодец.

Только он спустился на дно, работники стали бросать вниз камни, чтобы убить Ганса. Ганс сразу понял их замысел. Камни не причиняли ему боли, и он ничего не сказал. Но уже когда счёт пошёл на сотни, у Ганса лопнуло терпение.

– Эй, наверху! – крикнул из колодца Ганс. – Прогоните-ка кур от колодца, чтобы они мне в глаза песок не сыпали, иначе я ваше сокровище вовек не отыщу!

Услышав такие речи, хозяин и работники совсем перепугались и скинули в колодец мельничный жёрнов. А Ганс поймал жёрнов руками, просунул в отверстие голову и надел его, точно воротник, на шею и со смехом крикнул:

– Никак вы меня в попы пожаловали, что обрядили в широченный поповский воротник! Однако довольно дурачиться, вытаскивайте-ка меня отсюда, да поживее!

И с этими словами Ганс запустил вверх мельничный камень, тот вылетел так, что сшиб насмерть одного работника. А остальные испугались до смерти и вытащили Ганса из колодца. Тут уж хозяин понял, что с таким силачом ему нечего тягаться, подарил силачу много золота и предложил уйти. А Гансу и без того уже наскучило сидеть на одном месте, он собрал котомку, взял золото и отправился куда глаза глядят.

По дороге ему попадались люди, которые наперебой расхваливали красавицу – королевскую дочь; а ещё говорили, что сватается к ней неотёсанный великанище и хочет взять её в жены; король, её отец, совсем затужил от этакой страсти-напасти. И с горя обещал, что тот, кто победит великана, получит в жёны принцессу и полцарства в придачу.

Гансу ужасно захотелось хоть одним глазком взглянуть на принцессу. Ведь чем ближе он подходил к королевскому городу, тем больше слышал разговоров о том, какая она добрая и прекрасная. Наконец он вошёл в город…

Остановился Ганс перед королевским дворцом и увидел принцессу за окошком. Он влюбился в неё, что тотчас же решил выйти на бой с великаном, который

уже погубил трёх отважных рыцарей, осмелившихся сразиться с ним за прекрасную принцессу.

Увидев Ганса, великан решил, что опять без труда одолеет противника. Поэтому он начал над ним посмеиваться:

– Знать, и ты, человечишко, пришёл со мной сразиться! Не спеши! Покажи, как ты приподнимешь мою худую сабельку с земли, а уж потом свой меч вытаскивай.

Великан снял с пояса свой громадный меч и кинул на землю. Ганс одной рукой подхватил меч, высоко размахнулся и забросил его далеко в сторону, что меч по самую рукоять вонзился в землю. Великан увидел его силу и пустился на уговоры.

– Такого бойца не часто встретишь; давай лучше с тобой помиримся. Я дам тебе столько золота и драгоценностей, сколько ты сможешь увезти на трёх возах. Бери и поезжай своей дорогой, а мне оставь принцессу, потому что я очень её люблю.

Ганс не стал слушать великана, потому что сам без памяти влюбился в принцессу, а выхватил из ножен меч. На всю округу пошёл звон, когда они скрестили мечи, искры так и посыпались от удара! Бились они, бились, наконец, могучим ударом Ганс снёс великану голову с плеч; так и хлынула чёрная кровь и разбрызгалась по зелёной траве. Ганс подобрал отрубленную голову и понёс её в знак своей победы во дворец.

Едва только Ганс вступил в королевские палаты – король выбежал ему навстречу и сказал:

– Пойдём со мною, сынок! Я отведу тебя к принцессе и отдам тебе половину царства.

Принцесса тоже обрадовалась, что великан погиб, а ей достался в женихи добрый молодец. Ганс-медведь был не только большим силачом, но и очень хорош собою. Принцесса вскоре вручила ему руку и сердце перед алтарём.

Когда старый король умер, Ганс стал повелителем целого королевства. Он поехал с молодой женой навестить своих родителей и забрать их вместе с братьями и сёстрами к себе во дворец.

Нечего и говорить, как они удивились, когда подъехала золотая карета и остановилась перед их убогой лачугой! А когда они поняли, что король – это их сын, а прекрасная принцесса – его жена, очень обрадовались! Ганс посадил их в карету, и они со всей свитой поехали к медвежьей берлоге, чтобы навестить медведицу. Когда доехали, Ганс выскочил из кареты и пошёл в берлогу. Бедная медведица лежала пластом на подстилке, она была при смерти. Бедняжка заболела, силы её ослабели, и она больше не могла, как прежде, добывать себе в лесу на пропитание. Она так и померла бы голодной смертью, не дождавшись Ганса, но он подоспел как раз вовремя.

Узнав своего приёмыша, медведица приподнялась и хотела к нему подползти, но силы её оставили, и она вновь упала на своё ложе. Ганс крикнул слугам, чтобы

они поднесли еду и питьё; затем он присел рядом с медведицей и стал её гладить и ухаживать за ней. Медведица лизала шершавым языком руки короля и глядела на него ласково, как будто хотела сказать: «Вот я и дождалась тебя, ты пришёл, чтобы оказать мне последнюю службу; значит, не зря я тебя вырастила».

Но всё было напрасно. Медведица была уже так стара и слаба, что не могла больше жить… Бросив последний исполненный благодарности взгляд на короля, она вытянулась и испустила дух.

Они похоронили медведицу под вековечным дубом и воротились в королевский город, и Ганс-медведь царствовал в нём со своей красавицей-женой, и они жили мирно и счастливо многие годы.



# Хәйләкәр белән беркатлы

Бер шәһәрдә ике сәүдәгәр яшәгән. Үзара дус булганнар. Аларның берсе хәйләкәр, икенчесе беркатлы булган. Көннәрдән бер көнне болар сәүдә белән сәфәргә кузгалганнар.

Ерак китәргә дә өлгермәгәннәр, беркатлы мең динар акча салынган янчык тапкан. Юлдашына күрсәткән. Шулкадәр байлык белән юлга чыгалармы инде, кире борылырга булганнар.

Шәһәр капкасына җиткәндә, утырып, акча бүлә башлаган бу икәү. Беркатлы әйткән:

– Әйдә, дустым, яртысы – сиңа, яртысы миңа булыр, – дигән.

Хәйләкәре, бу акчаларның барысын да алырга теләп:

– Ник алай итеп торырга? Бу акчалар безнең уртак хәзинәбез булсын, хәзер үзебезгә кирәк кадәр генә алыйк та, кирәк булган саен килеп алырбыз, – дигән.

Шулай иткәннәр дә: йөзәр динар алып, калган акчаны янчыгы-ние белән агач төбенә күмеп куйганнар. Озак та үтми, хәйләкәр килеп, акчаларны казып алып киткән.

Күпмедер вакыттан соң беркатлы, хәйләкәр янына килеп:

– Миңа акча кирәк иде. Әйдәле, күмгән җирдән бераз казып алыйк, – ди.

Тегендә акча юк бит инде. Барып казыганнар болар. Акча чыкмагач, хәйләкәр беркатлыга:

– Дуска да ышанырга ярамый безнең заманда! Динарларны син генә алгансың, икебездән башка беркем дә аларның кайда икәнен белми иде, – дип кычкыра башлаган.

Хәйләкәр казыйга киткән:

– Акчамны урлаганнар!

Казый аннан шаһитлар алып килүен сораган. Хәйләкәр, аптырап тормаган:

– Минем шаһитым бар, – дигән.

– Кем соң ул?



– Агач. Агач шаһитлык итәр.

Казый, гаҗәпләнеп:

– Агач шаһит була аламыни? – дип, хәйләкәрне җибәргән.

Хәйләкәр, өенә кайткач, әтисенә хәлләрне сөйләп биргән дә:

– Динарларны мин алган идем, син ярдәм итсәң, мин судта отармын, – дигән.

Әтисе, миңа нишләргә кирәк, дип сорагач, хәйләкәр аңа:

– Агачның эче куыш, төнлә шуның эченә кереп утырсаң, беркем берни сизмәс. Иртәгә мин казый һәм шаһитлар белән килгәч, син, акчаны беркатлы алды, диярсең,– дип өйрәткән.

Әтисе аңа:

– Улым, акылы булган кеше мондый эшкә бармас, теге челән хәленә калма, – дип, челән хикәятен сөйли. – Яшәгән, ди, пар челән. Аларның күршеләре елан булган. Елан челәннәрнең яңа туган бөтен балаларын ашап барган. Челәннәргә башка җиргә күчеп китү бик авыр булган. Бигрәк тә әнкә челәнгә. Челәннәрнең хәлләрен күреп торган кысла челәнгә еланнан үч алу юлын өйрәткән.

Кысла челәнгә ләтчә өенен күрсәткән дә елан оясыннан ләтчә өенә кадәр балык ташлап чыгарга кушкан. Елан, аларны ашый-ашый килеп, балык исенә чыккан ләтчә тозагына эләккән. Шулай итеп челән үз балаларын еланнан коткарган. Менә шуның кебек бәлагә эләгә күрмә!

Хәйләкәр:

– Әткәй, мин моны беләм. Курыкма.

Атасы, улы кушканча, агач куышына барып яшеренгән.

Иртәгесен казый, яраннары белән килеп, агачка сорау бирә башлаган. Агач эчендәге карт җавап бирә:

– Динарларны беркатлы алды.

Казый аптыраган, монда нәрсәдер дөрес түгел дип, агач тирәсен әйләнеп чыккан. Игътибар белән карасалар, агачта куыш барлыгын күргәннәр. Казый агач куышына салам тутырып ут төртергә кушкан. Эчтәге кеше кычкыра башлаган, төтенгә тончыгып үлеп тә киткән.

Аны тартып алганнар алуын, тик соң булган инде. Хәйләкәрне камчы белән суктырганнар, ә динарларны беркатлыга биргәннәр.



# Хитрый и простодушный

Однажды в некоем городе жили два купца. Они дружили между собой. Один был хитёр, другой – простодушен. И решили купцы отправиться торговать в другое место.

Не успели они далеко отъехать, как простодушный нашёл кошелёк, в котором была тысяча динаров. Свою находку он показал приятелю, после чего они повернули назад.

Приблизившись к городу, друзья уселись и принялись делить деньги. И сказал простодушный хитрому:

– Половина – мне, половина – тебе.

Но хитрый, надеясь, что ему удастся забрать у простодушного все динары, ответил:

– Зачем нам их делить? Если эти деньги останутся нашим совместным достоянием, то и дружба, которая нас связывает, останется непоколебимой. Пусть каждый возьмёт сейчас сколько ему нужно на расходы, ну хотя бы по сто динаров.

Так они и сделали. Затем, зарыв остальные деньги под деревом, они удалились. Но вскоре хитрый тайком вернулся, забрал все деньги, заровнял место и убежал.

Спустя некоторое время простодушный обратился к хитрому:

– Мне нужны деньги. Давай-ка пойдём и возьмём немного из тех, что мы с тобой зарыли под деревом.

И они оба отправились к дереву, под которым были зарыты деньги. Но, раскопав это место, они ничего не нашли.

Тогда хитрый стал бить себя по голове и по груди, завопил и с упрёком сказал простодушному:

– Никогда нельзя полагаться на друга! Ясно, что ты взял динары, ведь, кроме меня и тебя, о них никто не знал.

И он пошёл к судье с жалобой:

– Похищены мои деньги!

Судья потребовал от хитрого свидетелей, и тот, не смутившись, сказал:

– У меня есть свидетель.

Судья спросил:

– Кто твой свидетель?

Хитрый ответил:

– Само дерево будет свидетельствовать в мою пользу.

Судья удивился:

– Как может дерево быть свидетелем?

Однако он отдал хитрого на поруки, повелев ему явиться на следующее утро для дальнейших объяснений. Хитрый же отпросился у поручителей домой и, поведав отцу обо всём, что произошло, сказал:

– Эти динары взял я, и если ты, отец, мне поможешь, я выиграю тяжбу.

Отец его спросил:

– Что мне надо делать?

Тот ответил:

– Дерево это внутри полое – в нём большое дупло. Если ты ночью залезешь туда и усядешься в дупле, никто этого не заметит. И когда я завтра явлюсь туда с судьёю и он начнёт задавать дереву вопросы, ты отвечай: «Динары, спрятанные у моих корней, забрал простодушный».

Отец ему возразил:

– Сын мой, умный человек остерегается такой защиты, которая приносит лишь вред, не говоря уже об обмане. Берегись, чтобы из твоей хитрости не вышло столько вреда, сколько случилось однажды из-за серой цапли.

Тот спросил:

– Что произошло из-за цапли?

Отец рассказал: «Жили однажды цапли-супруги. По соседству с ними жила змея. Она поедала всех птенцов, которые у них рождались. Но птицам, привыкшим к этому месту, тяжело было с ним расстаться. Цапля-мать очень горевала, не ела и не пила. Это заметил рак и вызвался помочь цаплям.

Рак показал ей нору ласки и сказал:

– От этой норы до змеиного гнезда разбросай несколько рыб. Когда ласка выйдет полакомиться рыбой, выползет за рыбой и змея. Тут ласка её и прикончит.

Цапля так и сделала и навсегда спасла от змеиного жала птенцов.

Потому-то и говорю я тебе, – закончил отец, – умный предусматривает всё заранее, чтобы не попасть в беду».

И сказал хитрый:

– Отец, я об этом слышал. Нам с тобой бояться нечего.

И пошёл отец, как того пожелал его сын, и забрался в дупло. На следующий день к этому месту прибыл судья и стал задавать дереву вопросы. И вещал отец изнутри:

– Динары, спрятанные у моих корней, забрал простодушный.

Это повергло судью в изумление, и он сказал:

– Тут что-то неладно.

Люди со всех сторон осмотрели дерево и обнаружили в нём дупло. Увидев его, судья приказал наполнить дупло сеном и поджечь. Человек, находившийся внутри, стал задыхаться от дыма. Он горестно кричал, а затем умер. Мертвеца извлекли оттуда, хитрого же по приказанию судьи высекли, а динары отдали простодушному.



# Һөнәр алтыннан кыйммәтрәк

Яшәгән, ди, бер патша. Аның, хәерче киеменә киенеп, иле буйлап халыкның ничек яшәгәнен карап йөрү гадәте булган. Шундый сәфәренең берсендә патша бер кызны очраткан. Бер кашык су белән йотарлык гүзәлне күреп, патша башын югалтып гашыйк булмасынмы!

Кайткач, вәзирләрен җыеп болай дигән:

– Фәлән авылда шундый кыз яши, шуның атасына яучы булып барыгыз, мин аңа өйләнергә телим.

Вәзирләр барып кызны күргәннәр, чынлап та, кыз матур икән, аның әти-әнисенә хәлне аңлатканнар. Кызның әтисе ярлы булган, патшаның үз кызына өйләнергә теләвенә ышанмаган да. Ахырында, патша ничек дисә, шулай булыр дип, кызына эндәшкән:

– Кызым, падишаһыбыз сиңа яучылар җибәргән, ни дип җавап бирик?

– Аның һөнәре бармы соң? – дип сораган кыз.

– Патшаның нинди һөнәре булсын, ул – ил башлыгы, без – аның хезмәтчеләре. Ул ничек тели – шулай була.

– Юк, һөнәрсез кешегә чыкмыйм, өйләнәсе килсә, берәр һөнәргә өйрәнсен, – дип җавап биргән кыз.

Вәзирләр, кайтып, патшага кызның җавабын ирештергәннәр. Патша гаҗәпләнгән, тик нишләмәк кирәк, яраткан кешең хакына һөнәр үзләштерү кыен эш түгел. Ул иң җиңел һөнәрне сайлаган – палас тукырга өйрәнә башлаган.

Остарып беткәч, бик матур палас тукыган да кызга бүләккә җибәргән. Кыз паласны бик ошаткан, әти-әнисе белән саубуллашып, сарайга китәргә ризалык биргән.

Бер ел уздымы икән, икеме – билгесез, патша, хәерче киемнәренә киенеп, ил-йорты буйлап йөрергә чыгып киткән. Шушы сәфәрендә ул юлбасарлар кулына эләккән. Юлбасарлар, һөнәре барлыгын белгәч, аны үтермичә бай сәүдәгәргә сатканнар. Сәүдәгәр патшаны, бер бүлмәгә бикләп, палас тукырга утырткан. Патша шундый палас тукыган ки, бөтен җир йөзендә аңа тиңнәр юк икән.



Бу паласны күргән сәүдәгәр хатыны иренә:

– Зур палас тукыт син аннан. Патшага бүләк итәрсең, бәлки, ул да җавапсыз калмас.

Сәүдәгәр, тукучы янына кереп:

– Патшага бүләккә палас тукып бир. Дөньяда бүтән андый палас булмасын, зурлыгын патша идәненә таман ит. Зур да булмасын, кечкенә дә булмасын. Юкса башыңнан колак кагарсың, – дигән.

Патша моны ишетеп бик шатланган. Үз сараеның иңе-буен ул бик яхшы белгән. Сәүдәгәр кушканча, дөньяда тиңе булмаган палас тукып та биргән. Паласның бер читенә, патша хатыны укырлык кына итеп, үз хәлләрен бәян иткән.

Сәүдәгәр тукучысының эшеннән канәгать калган. Паласны күтәреп, патша сараена киткән. Патша хатыны паласны җәеп, аның бүлмәгә тап-таман гына булуына гаҗәпләнгән, паласның бер почмагында иренең хәбәрен күреп агарынып киткән. Патшаның элегрәк тә озак сәфәрләргә чыгып киткәне булганга күрә, мондый хәлгә төшкәндер дип беркем дә уйламый бит инде.

Патша хатыны шул ук минутта тукучыны сарайга китерергә әмер биргән.

Вәзирләр, сәүдәгәрнең өенә барып, патшаны сарайга алып кайтканнар. Аны беркем дә танымаган – патша ябыгып, үзгәреп беткән икән. Сәүдәгәр, тукучыны юындырып, киендереп, үзен сарайда ничек тотарга өйрәтеп җибәргән.

Патша сарайга килеп керүгә, хатыны аның каршына атылган.

– Хатын, һөнәр алтыннан кыйммәтрәк дип хак әйтәләр икән, – дигән патша.



# Ремесло дороже золота

Жил некогда богатый царь. Он часто тайком от везиров одевался в рубище нищего и ходил странствовать по городам и сёлам, слушал, что о нём говорит народ. Как-то раз в одном селе царь встретил девушку, такую красивую, что кто бы ни видел её – говорил: ни пить, ни есть, на неё смотреть.

Царь вернулся к себе во дворец и сказал своим везирам:

– В такой-то деревне живёт прекрасная девушка. Пойдите и скажите, что царь хочет на ней жениться.

Везиры отправились в ту деревню, нашли дом девушки и тоже были восхищены её красотой. Сказали они отцу и матери девушки, что царь очарован их дочерью и хочет на ней жениться. Отец девушки был бедный крестьянин. Не поверил он, что царь удостоил его дочь такой чести. Но люди царя убедили его, и тогда он сказал:

– Мы слуги царя, как он прикажет, так и будет.

И обратился к дочери:

– Дочь моя, царь послал своих везиров, сватается за тебя. Что им ответить?

Девушка спросила:

– А какое у царя ремесло?

– Что ты, дочь моя, ума лишилась? Какое у царя может быть ремесло? Он владеет миром, что захочет – сделает, а мы все – его слуги.

– Нет, мой муж должен владеть каким-нибудь ремеслом, иначе я за него замуж не пойду.

Пошли везиры, передали царю ответ девушки. Удивился царь, но ничего не поделаешь, ради девушки решил выучиться ремеслу. Выбрал он самое лёгкое ремесло – стал учиться ткать ковры.

Овладев этим ремеслом, царь соткал для своей невесты красивый ковёр и послал ей в подарок.

Девушке понравился ковёр. Распрощалась она с отцом и матерью и с везирами отправилась в царский двор.

Прошёл не то год, не то два, и снова царь в одежде нищего стал обходить свои города и сёла, решив узнать, что о нём говорит народ.

Во время одного из таких странствий царь попал в руки разбойников, которые, узнав о его ремесле, не убили его, а продали богатому купцу. Купец запер царя в тёмную каморку, дал ему шерсти, чтобы он её растрепал и соткал ковёр. Царь соткал ковёр, да такой красивый, подобного которому не было во всём мире.

Увидев этот ковёр, жена купца сказала мужу:

– Пусть он выткет большой ковёр. Отнесёшь его в подарок царю, а он авось в долгу не останется.

Купец пошёл в каморку к ткачу и сказал ему:

– Хочу сделать царю подарок. Вытки ковёр, да только смотри, чтобы в целом свете такого не было. И чтоб он был величиной с царский зал, ни на волос не больше и не меньше. Не сносить тебе головы, если не выполнишь моих условий.

Царь, услышав это, очень обрадовался, а длину и ширину своего зала он хорошо знал. И соткал он такой ковёр, какой требовал хозяин. А в углу ковра выткал буквы (так, чтоб только одна царица могла прочитать), что попал он в беду и просит освободить его.

Купец остался доволен работой и понёс ковёр в царский дворец. Везиры дали знать царице о принесённом подарке. Царица расстелила ковёр, увидела, что он ни на волос не больше и не меньше комнаты, удивилась очень, осмотрела весь ковёр и в одном углу увидела буквы. Прочитав надпись и узнав, что случилось с её мужем, царица побледнела. Царь и прежде ходил по стране недели, месяцы и годы, но никогда ей и в голову не приходило, что может его постигнуть такая участь.

Царица тотчас повелела привести того, кто соткал этот ковёр, целым и невредимым во дворец.

Везиры отправились с купцом к нему домой, зашли в тёмную каморку, но царь очень изменился, и они его не узнали. Ткача повели в баню, искупали, нарядили в новые одежды и отвели в царский дворец. А купец наставлял его как вести себя во дворце, как стоять и кланяться.

Когда царь вошёл в палату, царица тотчас же бросилась к нему, обнялись они, поцеловались.

– Правду говорят, жена, – сказал царь, – что ремесло дороже золота.



# Гадел казый

Бер егет, сәфәр чыгып китәр алдыннан, саклап торырга дип, күрше картына йөз әфгани акча калдырган.

Күпмедер вакыттан соң әйләнеп кайткач, картка акчасын алырга кергән. Ә тегесе усал елмаеп болай дигән:

– Синең беркатлылыгыңа шаккатам! Миндә синең акчаң юк, үз юлыңда бул!

Егет югалып калган. Кешеләр аңа казыйга барырга киңәш иткәннәр. Егет шулай эшләгән дә. Казый картны чакырткан да сорый икән:

– Каршыңда утырган егетнең акчасын алдыңмы?

Карт казый каршында тезләнеп елап җибәргән:

– Ходай үзе шаһит, мин бернинди акча турында да белмим! Агарган сакалым белән алдашып утырмам бит!

Аннары казый егеттән сораган:

– Шаһитларың бармы?

Егет юк дип башын чайкаган.

– Ярар. Акчаны кайда бирдең соң син?

– Бер агач төбендә.

– Ярар, алайса, шул агачка бар да сине казый чакыра дип әйт.

Егет, аптырап:

– Хөкемдар, агачны ничек чакырыйм инде мин? – дип инәлгән.

– Менә сиңа минем мөһер! Шуны күрсәтеп куркыт үзен. Килмәсә, үзенә үпкәләсен.

Егет киткән, карт мыек астыннан гына елмаеп утырып калган.

Ярты сәгать үткән. Казый кояшка карап алган да карттан сорый икән:

– Барып җиттеме әле?

– Юк әле, – дигән карт.

– Ярый-ярый, – дип елмайган казый.

Тагын бер сәгать үткән.

– Барып җиттеме, юкмы? – дип сораган казый.

– Менә хәзер җитте, – дип җавап биргән карт.

Егет әйләнеп килгән дә, казыйга мөһерен биреп, күңелсезләнеп кенә әйткән:

– И хөкемдар, агач килмәде бит.

– Ялгышасың, килде, – дигән казый.

– Ничек килсен? – дигән карт. – Нишләп күрмәдем мин аны? Әллә минем күзләрем юкмы?

Казый болай дигән:

– Күзләрең бар. Мин «егет теге агачка барып җиттеме әле» дип сорагач, син миңа «юк» дидеңме?

Карт баш каккан.

– Мин синнән барып җиттеме әле дип сорагач, «әйе» дидеңме? Әгәр син шул агач янында акча алмаган булсаң, аның кайда булуын белер идеңме?

Карт йөз әфганине егеткә бирергә мәҗбүр булган.

АФГАНСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Мудрый судья

Один юноша, уезжая в дальние страны, принёс старику сто афгани. Отдал он их ему на хранение и уехал.

Много ли, мало ли времени прошло – неизвестно. Но когда юноша вернулся на родину и попросил старика вернуть ему сто афгани, тот злобно усмехнулся:

– Твоя наивность радует шакалов. Я не брал у тебя никаких денег. Ступай своей дорогой!

Юноша совсем было растерялся, но добрые люди научили его. «Пойди, говорят, к судье и пожалуйся на хитрого старика!» Так юноша и поступил.

Судья вызвал к себе старика и спрашивает:

– Ты брал деньги у юноши, который сидит прямо перед тобой?

Заплакал старик, упал на колени, взмолился:

– Аллах видит, не брал я никаких денег! Неужто я буду лгать с моей седой бородой?!

Затем судья спросил юношу:

– А у тебя есть свидетели?

Юноша отрицательно покачал головой.

– Хорошо. А где ты давал старику деньги?

– Да под одним деревом.

– Пойди к тому дереву и скажи, что я вызываю его на допрос.

Взмолился юноша:

– Как же я скажу это дереву, о мудрый судья?

– Вот тебе моя печать. Пригрози ему! Скажи, что, если не придёт, пускай потом пеняет на себя.

Грустно поплёлся юноша к дереву, а старик, пряча в бороде улыбку, остался его ждать.

Прошло полчаса. Взглянул судья на солнце и спрашивает старика:

– Ну как, дошёл он до того дерева?

– Нет ещё, – смиренно ответил старик.

– Так, так, – улыбнулся судья. Прошёл ещё час.

– Ну, а теперь пришёл он к дереву? – спросил судья.

– Пришёл, – ответил старик.

– Так, так, – улыбнулся судья.

Наконец юноша вернулся, отдал судье печать и грустно сказал:

– Дерево не пошло со мной, о мудрый судья.

– Дерево приходило, о честный юноша! – возразил судья.

– Как приходило? – воскликнул старик. – Почему я его не видел? Или у меня глаз нет?

На это судья ему ответил так:

– Глаза у тебя есть. Но помнишь, я спросил тебя, дошёл ли юноша до дерева, и ты мне сказал «нет»?

Старик кивнул головой.

– А помнишь, я спросил тебя, возвращается ли юноша, и ты сказал «да»? Если ты не брал денег под тем деревом, то как же ты мог знать, где оно и как долго до него идти?!

Злобно плюнул старик на землю, вытащил из кармана сто афгани и бросил их к ногам юноши.



# Камыр батыр

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бабай белән әби. Бабай балык аулаган, шуның белән көн күргәннәр. Тик балалары булмау гына эчләрен пошырган. Беркөнне бабай, гадәтенчә, балыкка барган. Ау салып тартып алган икән – сәер бер балык эләгеп чыккан. Балыкның тәңкәләре алтыннан да көмештән, гәүһәрдән дә якуттан, ди. Күзнең явын алып торалар, ди.

Бабай, балыкны учына алып, озак карап торган да: «Моны ашап тамак туймас, яши бирсен», – дип, диңгезгә ташлыйм дигәндә генә, балык телгә килгән:

– Бабай! Мине алып кайт. Итемне улларыңа ашат, канымны атларыңа эчер, кылчыкларымны этләреңә бир, – дигән.

Бабайның уллары булмагач, аптырап калган. Ни эшләргә белми торган-торган да, ни булса да булыр дип, балыкны алып кайтып киткән.

Кайткач, ишектән кереп сүз катарга өлгермәгән, ике малай күтәреп, каршысына карчыгы килеп баскан.

– Бу малайлар – безнең улларыбыз! – дигәч, бабай тагын да ныграк гаҗәпләнгән.

Шуннан моның карчыгы бабай балыкка киткәч ни булганын сөйләп биргән.

– Син балыкка чыгып китү белән камыр бастым да, ике малай ясап, сандыкка салдым, – дигән әби. – Шул арада үзем ишегалдына чыгып әйләндем. Килеп керсәм, колагыма бала елаган тавыш ишетелгәндәй булды. Иплəбрәк тыңласам, тавыш сандык эченнән килә. Карасам, шаккаттым: минем бая салып куйган малайларыма җан иңгән!

Ни әйтергә белми катып калган бабай, һушына килгәч, балыкның әйткән сүзләрен исенә төшергән. Шуннан балыкның итен малайларга ашаткан, канын ике атына эчергән, кылчыкларын ике этенә ташлаган.

Могҗизалы балыкның итен ашагач, малайларның башы алтын балык тәңкәләре кебек асылташлар белән капланган. Малайлар көн үсәсен бер сәгатьтә үскәннәр. Бабай белән әби бик куанганнар, үзләрен дөньяда иң бәхетле кеше итеп санаганнар, зурысына Камыр батыр дип исем кушканнар.

Бервакыт Камыр батырның дөнья гизеп кайтасы килгән. Камыр батыр атасына:

– Атам! Миңа унбиш пот чуеннан чукмар койдыр, аннан да авыррак итеп кылыч суктыр. Юл йөргәндә кирәк булыр алар миңа, – дигән.

Атасы чукмар белән кылыч эшләтеп биргәч, Камыр батыр, коралларын сынарга дип, бер яланга чыккан. Унбиш потлы чукмарны күккә чөеп җибәргән, төшеп җиткәндә, Камыр батыр аның астына башын куйган, чукмар, Камырның башына бәрелеп, челпәрәмә килеп ватылган. Камыр батыр аның ватыкларын җыеп алган да, аннан да авыррак итеп, икенче чукмар койдыртып алган. Аны да шулай итеп сынап карагач, ярарлык дип тапкан.

Чыгып китәр алдыннан Камыр батыр бер укны җепкә бәйләп келәт өрлегенә элгән дә энесенә:

– Син бу укны көн саен карап тор. Май тамса, мин исән-сау булырмын, кан тамса, үлгән булырмын. Ул чакта мине эзли чыгарсың, – ди.

Камыр батыр ата-анасы, энесе белән хушлашкан да, чукмары белән кылычын тагып, атка атланып чыгып киткән. Бик озак чапкач, ялгызы гына торган бер өйгә барып җиткән. Атын бәйләп, шунда ятып ял итмәкче булган. Бу йортта убырлы карчык яши икән. Ул Камыр батырны ишек ачып каршы алган:

– Кем син, улым? Каян киләсең? Кая китеп барышың? – дип сораган.

Камыр батыр, аның сорауларына җавап биргәч:

– Бик ачыктым, әби, капкалап алырга берәр нәрсәң булмасмы? – ди.

Убырлы карчык Камыр батырга ашарга-эчәргә китергән. Камыр батыр шикләнмичә ашап эчкән дә һушсыз булып ауган. Убырлы моның эчәренә агу салган булган икән. Шуны гына көтеп торган убырлы Камыр батырны йоткан да җибәргән, ә асылташлы башын өен бизәргә дип алып калган.

Камыр батырның чыгып киткәненә байтак вакыт узган бит инде. Беркөнне әнкәләре кече улын келәттәге өрлекне карап керергә чыгарып җибәргән. Энесе караса, уктан кан тамып тора, ди. Ул, кереп, әти-әнисе белән саубуллашкан да, балык кылчыкларын кимергән теге этләрне ияртеп, агасын эзләргә чыгып киткән. Этләр моны туп-туры убырлы өенә алып килгәннәр. Өйгә килеп керсә, егетне бик сылу бер кыз каршы алган.

– Егет, җаның кадерле булса, чыгып кит тизрәк, – дигән кыз.

– Агамны күрми китмим, – дигән егет.

– Алай булгач, тыңла: әби сине табынга чакырыр, син бернәрсәне дә ашамаэчмә, – дип, кыз күздән югала.

Бу аптырап торган арада, убырлы карчык килеп кергән. Кергән дә егетнең кемлеген, кая барышын сораштыра башлаган. Аннары:

– Ачыккансыңдыр, улым, ашап-эчеп кит, – дип, табын янына чакырган.

Егет бер әйбергә дә кагылмагач, кыстый да кыстый, ди, бу. Алай да ашамагач, бу егетне үтермәкче булган. Көче җитмәгән. Шуннан егет үзе, торып, убырлының чәчләреннән урап алган да: «Агамны кайтар», – дип, убырлыны камчысы белән ярырга тотынган.

Убырлы нишләсен, Камыр батырның сөякләрен чыгарып, башын ялгаган да өстенә тере суы бөркегән. Шуннан соң Камыр батыр күзен ачып сикереп торган.

– Ай-һай озак йоклаганмын, – дигән ул.

– Йоклагансың, йокламый ни! Мин булмасам, мәңге уянмас идең, – дип, энесе булган хәлләрне сөйләп биргәч, Камыр батыр явыз карчыкны суккан да үтергән. Шуннан убырлының бөтен байлыгы белән теге кызны энесенә биргән. Энесе ата-анасы янына кайтып, теге кызга өйләнеп яши башлаган, Камыр батыр ары киткән.

Бара торгач, бер патшалыкка җитә бу. Бер картка фатирга төшә. Карт моны хәзинәдә бары белән кунак итә, үзе шәһәр хәлләрен сөйли:

– Бәхетсезлек килде әле калабызга, – ди ул. – Әйбәт кенә яшәп ятканда, дию килеп төште. Шушында яшәмәкче булып, барыбызны да кырып бетерү белән яный башлады. Инде диюгә илчеләр җибәреп, бездән күпме түләү сорыйсың, бирәбез, безне генә тынычлыкта калдыр, диделәр. Дию көн саен бер кыз җибәреп торуларын сораган. Нишләмәк кирәк, кала халкы шуңа риза булды. Инде хәзер чират патшаның берdәнбер кызына җитте. Кызын коткарган кешегә патша зур бүләкләр вәгъдә итә. Әле кызны чуен сарайга яшерделәр, аны патшаның бер вәзире саклап тора.

Бабай сөйләп бетерү белән, Камыр батыр чукмарын алып, шунда киткән. Чуен сарайга барып җитеп, ишекне тартып караса, ишек ачылган да киткән. Патша кызы, Камыр батырны күреп:

– Егет, нишләп йөрисең монда? – дип сораган, ди.

Камыр батыр:

– Сине коткарырга килдем, – дип кенә өлгергән, шул арада, күк күкрәп, яшен яшьнәп, коточкыч зур дию килеп баскан. Аның янында Камыр батыр малай кебек кенә күренә, ди. Дию аңа:

– Син монда нигә дип килдең? – ди.

– Сине үтереп, патша кызын коткарырга килдем! – ди Камыр батыр.

Шулай дигән дә Камыр батыр, чукмарын күтәреп диюгә суккан икән, гәүдәсеннән башы өзелеп, читкә тәгәрәгән. Камыр батыр диюнең башын, чуен сарайны күтәреп, сарай нигезенә тыгып куйган, ә гәүдәсен диңгезгә ташлаган. Шуннан, кыз белән хушлашып:

– Мин сезгә соңрак килермен, хәзер миңа ял итәргә кирәк, – дип кайтып киткән.

Ул арада патшаның чуен сарайны сакларга куелган вәзире килеп җиткән.

– Әгәр атаңа диюне мин үтерде дип әйтмәсәң, хәзер үк башыңа җитәм, – дип, кызны куркытып куйган.

Кайтканнар болар патша сараена. Патша, кызының исә-сау кайтып керүен күргәч, үз күзләренә ышанмый торган. Шул ук минутта кызын шушы батырга кияүгә бирәчәген игълан иткән.

Инде өченче көн туй бара. Патша да, кияү дә, кунаклар да шат, бары тик кыз гына күңелсез, ди. Патша кызы туйга килгән һәрбер кешене күздән кичереп утыра.

Бервакыт сарайга хәерче генә киенгән берәү килеп ишек төбенә утырган. Патша моны күреп, ачуланып, куып чыгарырга боерган. Патша кызы Камыр батырны танып алган да атасыннан аны сарайда калдыруны сораган.



Патша рөхсәт иткән, кыз Камыр батырга бер касә бал китереп биргән. Камыр батыр балны күтәреп эчеп җибәргән дә җырларга рөхсәт сораган. Камыр батырның моңлы тавышыннан кунаклар оеп киткәннәр, бер патша кызы гына уяу килеш калган. Камыр батыр хәерче киемнәрен салып ташлаган. Патша кызы аңа чуен сарайдан чыккач булган хәлләрне сөйләп биргән. Камыр батыр аңа:

– Кунаклар һушларын җыйгач, миңа сөйләгәннәреңне аларга да сөйләрсең, – дигән.

Икенче җырга кунаклар уянган. Патша кызы үзен диюдән чынлыкта кем коткарганы турында сөйләп биргән. Кияү:

– Юк-юк, диюне мин үтердем, патша кызын мин коткардым, – дип кычкырына, ди.

Патша аңа:

– Диюне син үтергәнсең икән, расла! Ничек расларсың? – дип сорау биргән.

– Диюнең башын чабып өздем дә, чуен сарай астына салып куйдым, – дигән вәзир.

Ул шулай дигәч, җыелышып, чуен сарай янына киткәннәр. Патша вәзиренә:

– Әйдә, диюнең башын яшергән җиреңнән алып күрсәт инде, – дигән.

Вәзир тегеләй иткән, болай иткән, чуен сарайны күтәрү түгел, урыныннан да кузгата алмаган.

Камыр батыр чыккан да, чуен сарайны күтәреп:

– Диюне мин үтердем. Менә аның башы! – дип, диюнең килбәтсез башын алып күрсәткән.

Шуннан соң диңгездән диюнең гәүдәсен дә алып чыккан. Халык Камыр батырның көч-куәтен күреп хәйран калган.

Шуннан патша Камыр батырга:

– Вәгъдәм буенча ярты байлыгым белән кызымны сиңа бирәм, варисым булырсың, – дигән.

Ә алдакчы вәзирен асарга боерган, ди.



# Камыр-батыр

Жили старик со старухой. Старик промышлял рыболовством. Они ни в чём не нуждались, но отсутствие детей делало их жизнь тоскливой.

В один пасмурный день старик по обыкновению пошёл к морю ловить рыбу. Закинул в море сеть, и вскоре попалась необыкновенная рыбка: вместо чешуи блестели у неё драгоценные разноцветные камни, от которых исходил свет, подобный солнечному. Старик положил рыбку себе на ладонь, долго смотрел на неё и наконец сказал:

– Этой рыбкой сыт не будешь, пусть живёт. – Он хотел было уже бросить рыбку в море, как она промолвила человеческим голосом:

– Старик! Возьми меня, накорми моим мясом своих сыновей, напои моей кровью своих коней, а косточки мои отдай собакам.

Старик изумился: ведь у него не было сыновей. Стоит он и не знает, что делать – верить или не верить. Как бы там ни было, взял старик рыбку и понёс домой, размышляя о происшедшем. Так был взволнован, что едва добрёл до своего дома. Не успел вымолвить и слова, как старуха поднесла к нему двух мальчиков:

– Смотри, вот эти мальчики – наши дети.

Ещё больше удивился старик. Жена рассказала ему, что произошло в избушке, когда он ушёл:

– Я замесила тесто и, вылепив из него фигурки двух мальчиков, положила в сундук, а сама вышла. Когда возвратилась, я услышала детский плач из сундука. Скоро я отперла сундук и увидала, что мои мальчики, сделанные из теста, ожили.

Когда потрясённый всем, что произошло, старик пришёл в себя, поступил так, как советовала рыбка: её мясом накормил мальчиков, кровью напоил двух коней, а косточки бросил двум собакам. Тогда головы мальчиков покрылись теми же разноцветными камнями, какими была покрыта сама рыбка. Мальчики росли не по дням, а по часам на радость старикам, которые считали себя самыми счастливыми на свете.

Скоро Камыр-батыр – так назвали старшего – стал скучать: ему захотелось попутешествовать по белу свету. Старик со старухой, узнав о намерениях сына, силь-

но огорчились, но делать было нечего, и решили не задерживать его. Камыр-батыр сказал отцу:

– Закажи мастеру сделать для меня чугунную палицу в пятнадцать пудов и шашку потяжелее. Это оружие необходимо для моего путешествия.

Желая испытать прочность оружия, Камыр-батыр вышел на поляну, метнул палицу ввысь с такой силой, что та исчезла из глаз. Когда палица показалась на обратном пути, Камыр-батыр подставил под неё обнажённую голову. Та, ударившись, разлетелась. Собрал Камыр-батыр обломки и заказал себе новую палицу, ещё тяжелее. Испытал и эту – остался доволен.

Собираясь в путь, Камыр-батыр взял стрелу, привязал к концу верёвки, повесил в амбаре и сказал брату:

– Каждый день смотри на эту стрелу: если из неё будет капать масло, знай, что я жив и здоров; если же потечёт кровь, знай, что я мёртв, и немедленно отправляйся искать меня.

Простился Камыр-батыр с отцом, матерью, братом и поехал.

Спустя некоторое время он подъехал к какой-то избушке и решил отдохнуть. Привязав своего скакуна неподалёку, вошёл в эту избушку. Жила в ней мэскэй[1]. Камыр-батыра на пороге встретила старушка и стала расспрашивать, кто он, откуда и куда едет. Тот ответил на все вопросы и сказал:

– Я устал и проголодался, нет ли у тебя поесть? Старушка подала ему много разных кушаний и между прочим какую-то жидкость. Камыр-батыр, ничего не подозревая, отведал всего и вдруг потерял сознание. Оказалось, что мэскэй напоила его ядом. Как только Камыр-батыр потерял сознание, ведьма съела всё его тело, а голову повесила на стену.

Прошло довольно много времени после отъезда Камыр-батыра, а дома его как бы совсем забыли. Однажды мать предложила брату Камыр-батыра взглянуть на стрелу, по которой можно было узнать о судьбе того. Брат входит в амбар и видит, что из стрелы течёт кровь. Согласно обещанию, он сейчас же должен был ехать на розыски Камыр-батыра. Благодаря тем собакам, которые были накормлены косточками чудной рыбки, младший брат легко разыскал избушку, где погиб Камыр-батыр. В избушке находилась красавица-девушка. Она сказала:

– Уходи отсюда, если тебе жизнь дорога.

Но брат Камыр-батыра возразил:

– Я не уйду, пока не увижу своего брата.

Девушка предупредила:

– Если старуха будет тебя угощать, не ешь ничего. – Сказав это, девушка исчезла. Вскоре появилась старуха. Поздоровались, пригласила за стол. Брат Камыр-батыра от кушаний отказался. Тогда старуха схватила его, хотела убить, но не смог-

---

[1] *Мэскэй* – ведьма.

ла справиться с противником: сила у него была неимоверная. Брат Камыр-батыра схватил ведьму за косу и, избивая плёткой, стал приговаривать: «Верни моего брата, верни!» Ведьма обещала немедленно выполнить его требование. Собрала кости Камыр-батыра, приставила к ним голову, брызнула живой водой, и Камыр-батыр ожил, стал таким, как будто с ним ничего не случилось. Узнав от брата обо всём, что произошло, Камыр-батыр тут же убил ведьму. Всё её богатство отдал брату, а сам поехал дальше. Брат привёз старикам-родителям богатства ведьмы и женился на той девушке, которая дала совет не прикасаться к кушаньям ведьмы.

Братья разъехались. Ехал, ехал Камыр-батыр, наконец подъехал к городу, в котором жил падишах. Камыр-батыр остановился у одного старика. Старик угостил гостя чем только мог. Камыр-батыр стал расспрашивать о городе. Старик, вздохнув, поведал:

– Наш город несчастный. В один прекрасный день к городу подлетел див. Он хотел перебить всех жителей и поселиться в городе. Собрался народ на площади. Там был и царь. Отправили несколько человек для переговоров с дивом. Послы пришли к диву и сказали: «Возьми с нас выкуп, какой хочешь, и только оставь в покое». Див сказал послам: «Я вам не причиню никакого зла, если ежедневно вы будете выдавать мне по девушке». Жители согласились и стали ежедневно доставлять диву по девушке, каждый по очереди. Сегодня дошла очередь до единственной дочери царя. Царь обещает большую награду тому, кто спасёт её. Сегодня падишах запер свою дочь в чугунный сарай и приказал одному из придворных караулить её, надеясь, что див не доберётся до неё.

Когда старик закончил рассказ, Камыр-батыр взял палицу и вышел. Пришёл он к чугунному сараю, дёрнул дверь. Она мигом отворилась.

– Зачем ты явился сюда? – удивилась, увидав его, царевна.

– Спасти тебя.

Едва он вымолвил это, как поднялась страшная буря. Царевна предупредила, что буря предвещает близкий приход дива. И действительно, загремел гром, сверкнула молния, и как из-под земли вырос див. Камыр-батыр в сравнении с ним казался мальчиком. Див спросил Камыр-батыра:

– Для чего ты явился сюда, несчастный?

Камыр-батыр ответил:

– Я пришёл убить тебя и спасти царевну.

Затем он схватил палицу и ударил дива по голове. Обезглавил чудовище, и туловище того пало на землю. Камыр-батыр приподнял сарай, вкатил под него голову, а туловище сбросил в море, которое было неподалёку. Затем он поклонился царевне:

– Я приду во дворец после, а теперь мне надо отдохнуть.

Как только Камыр-батыр скрылся из виду, выскочил придворный, которому было поручено стоять на карауле возле сарая, подбежал к царевне и пригрозил:

– Я тебя убью, если ты не поклянёшься сказать отцу, что див побеждён мною.

Напуганная царевна дала обещание. Они вместе отправились во дворец. Царь

не верил своим глазам, видя свою дочь невредимой. Он от радости забыл даже расспросить, каким образом придворный спас её. Немедленно объявил народу, что выдаёт свою дочь за спасителя-придворного.

Свадебный пир идёт уже третий день. Веселятся все: и падишах, и жених, и гости. Одна царевна грустит: ведь её выдают за нелюбимого, между тем сердце её принадлежало Камыр-батыру, а его всё ещё нет. Царевна встречает взглядом каждого входящего. Вдруг замечает: вошёл нищий и сел у дверей. Царь, увидев нищего, разгневался, велел прогнать. Но царевна уже узнала в нём Камыр-батыра. Подошла к отцу и говорит:

– Пусть останется здесь.

Она взяла чашку мёда и поднесла нищему. Нищий, выпив мёду, попросил у падишаха разрешения спеть что-нибудь. Тот разрешил. От чудесного пения Камыр-батыра все, за исключением царевны, впали в забытьё. Камыр-батыр сбросил с себя нищенское рубище. Царевна ему поведала, что произошло после того, как он расстался с нею.

– Когда все очнутся, ты это им расскажи, – посоветовал Камыр-батыр.

Он снова запел. Своим пением теперь пробудил всех, и царевна начала рассказывать, как она была спасена. А придворный стал уверять падишаха, что див убит им, царевна спасена им. Царь, выслушав его, предложил:

– Если ты убил дива, докажи это! – Все отправились к чугунному сараю. Придворный заявил:

– Вот доказательство: я голову дива положил под дворец.

– А если так, – сказал царь, – достань её и покажи нам.

Придворный смутился, ведь он не в силах был поднять чугунный дворец. И вот выступил из толпы Камыр-батыр:

– Див убит мною!

Приподнял батыр дворец и показал безобразную голову дива. Потом кинулся в море, нырнул на дно. Достал оттуда туловище дива и вынес на берег. Изумлению присутствующих не было границ.

Царь обратился к Камыр-батыру:

– Возьми мою дочь и будь моим наследником.

Обманщика-придворного падишах приказал казнить.



# Каня

Бик күптәннән булган инде бу хәл. Җир дә ясалып бетмәгән булган әле. Җирдә таулар, далалар, урман-кырлар булган, елга-күлләр, чишмәләр, инешләр булмаган. Кешеләргә нәрсә: кое казыганнар да шуннан су алып рәхәтләнеп яшәгәннәр. Ә хайваннар белән кошлар нишләсен? Эчәсең килгәч, әллә кая, ерактагы диңгезгә су эчәргә барып булмый, яңгыр яугач барлыкка килгән күлләвекләр дә тиз кибә.

Кошлар, хайваннар җыелышып уйлаша башлаганнар. Уйлаганнар-уйлаганнар да, күлләр, елгалар, инешләр, чишмәләр казырга булганнар. Уртак эш вакытында бүре – сарыкка, карчыга – чебешкә, төлке куянга тимәскә дип килешкәннәр. Бер каня-тәкәрлек кенә озын аяклары белән әрле-бирле йөренә, ап-ак түшен сыйпый-сыйпый:

– Сез болай да күп, – ди икән. – Минем тырнакларым да юк, аягым нечкә, җирне ничек итеп казыйм? Ап-ак каурыйларым пычраныр, җирдә йөрергә иялә шмәгән дә мин, күбрәк күктә очам.

– Без синең өчен дә эшләргә тиешмени? – дип ачуланганнар башка киек-кошлар.

– Мин эшләгез димим дә, – дигән каня, – чык төшкәч, үләннәрдән чык җыям, яңгыр астында очып барган килеш тә тамчыларны эчеп туям. Миңа күп кирәкми.

Кош-кортлар, җанварлар каняга ияручеләр булыр дип куркып, шундый карар да чыгарганнар:

– Каняга һәм аның нәселенә беркайчан да елга-инешләрдән, кое-чишмәләрдән, күлләрдән, диңгезләрдән су эчәргә рөхсәт юк!

Үзләре эшкә тотынганнар: сукыр тычканнар җир астында су юлларын эзләгәннәр, аюлар таш актарган, кабан дуңгызлары канау казыган, кертлекләр туфрак күчергән. Карлыгач, аңа ияреп башка кошлар да елга үзәннәреннән туфрак ташып өйгән. Бик озак тир түккән алар: күлләр, елга үзәннәрен казу елларга сузылган. Бер михнәтнең бер рәхәте булган шикелле, аларга да бәйрәм килгән. Кая телисең, шунда яшә, балалар үстер – бөтен җирдә дә су җитәрлек. Эшләгән урыннарыннан еракка китмәгәннәр дә алар, шунда яшәргә калганнар. Ә каз-үрдәк, акчарлак, кондыз, кама суда яшәргә үк калганнар. Каня да су янында урнашкан. Тик, ни могҗиза, елгадан да, чишмәдән

дә су эчә алмый, томшыгыннан узмый икән. Бары тик чык суларын эчеп, йә булмаса, яңгыр тамчыларын йотып кына сусынын баса, ди.

Корылык башланса, хайваннар, кош-кортлар борчылмыйлар: елгада су бетми бит, ә каняга – кайгы.

– Су, су, су, – дип оча башлый, яңгыр яумый туктамый.

Кешеләр каня кычкыра башласа яңгыр буласын беләләр.





БЕЛОРУССКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Каня

Давно это было, в самом начале света, когда земля была ещё недоделанной. Были на ней горы, долины, леса и поля, но не было ни рек, ни озёр, ни криниц с холодной водой. Людям было ещё так-сяк: выкопают глубокий колодец, достанут воды и живут себе припеваючи. А вот зверям и птицам как? Ведь не побежишь, если захочешь пить, к далёкому морю, а лужи после дождя быстро высыхают, вода в землю уходит. И собрались звери и птицы на большое собрание, чтобы решить, что делать. Долго думали, так и сяк прикидывали и решили выкопать большие водоёмы, озёра, прокопать реки и ручьи, выкопать криницы[1]. И пока будут работать, чтобы ни волк ягнёнка, ни коршун цыплёнка, ни лиса зайца не тронули. И все согласились с этим. Одна только каня-пигалица возомнила что-то о себе: на длинных ногах похаживает, белую грудку поглаживает.

– Вас, – говорит, – и без меня много. У меня когтей нет, ноги тонкие, где мне ими землю рыть? У меня пёрышки белые, ещё испачкаюсь. Да и не привыкла я по земле бегать. То ли дело в небе купаться, тут я, как дома у батюшки.

– Так что ты, – возмутились звери и птицы, – хочешь, чтобы мы на тебя работали?

– А я вас и не прошу, – заносчиво отвечает каня, – роса опадёт, я с листочка напьюсь, дождик пойдёт, крылья у меня быстрые, я на лету капель наглотаюсь. Много ли мне той воды надо?

Видят звери и птицы, что вносит каня разлад в большое собрание, может погубить всё дело, если найдутся ещё такие охотники. И постановило большое собрание зверей и птиц проклясть каню страшным проклятием:

– Чтобы никогда каня, ни весь род её не пили воды ни из рек, ни из ручьёв, ни из озёр, ни из криниц, ни из самого моря синего.

А сами взялись за работу. Кроты под землёй водяные жилы искали. Медведь корчи корчевал, камни выворачивал. Дикие свиньи рвы рылом рыли. Куропатки землю разгребали. Ласточка первая земли комок в клюв взяла, отнесла его на пригорок

---

[1] *Криница* – родник или колодец.

и высыпала. А за нею и все остальные птицы землю в клювах носить стали из будущих речных русел. Долгие годы работали они, пока по всей земле реки и озёра не выкопали, землю из них по крупинке на пригорки не вынесли. Зато настала и для них жизнь хорошая: где хочешь – живи, где хочешь – деток расти, вода везде есть. И так привыкли они к тем местам, где вместе работали, что и селиться стали чаще всего возле воды, а гуси, утки, чайки, из зверей – бобр, выдра и многие другие и вовсе на воде жить остались. Каня тоже возле воды поселилась. Хочет она напиться воды из реки или криницы, да не может: застревает вода в клюве у неё. Только тогда может она напиться, когда капля росы ей просто в горло скатится или дождевые капли прямо в рот попадут.

Если даже сушь случится, птицы и звери не горюют: пересохнут мелкие ручьи – большие реки и озёра останутся. А кане тогда горе горькое, и начинает она летать и канькать:

– Пить, пить, пить...

И канькает, пока дождь не пойдёт.

Вот почему, когда кани летают и пить просят, люди знают, что скоро дождь будет.



# Байкал һәм Ангара

Карт баһадир Байкал бик бай. Меңнәрчә еллар буена тирә-яктан ясак җыеп туплаган ул байлыгын. Аңа өч йөздән артык тугры хезмәтчесе тирә-як таулардан, далалардан ясак китерә. Байкалның бердәнбер кызы Ангара исемле. Ангара төсе белән дә, килеше белән дә бик матур кыз, үзе тыныч, яхшы күңелле дә. Ангараның гүзәллеге, күркәмлеге турындагы хәбәр бөтен дөньяга таралган. Ангарага байлар да, көчлеләр дә – иң яхшы кияүләр яучы җибәреп карый, берсе дә кызның ризалыгын ала алмый. Ангара барысын да кире борып җибәрә тора икән. Аның йөрәгендә бары тик Енисейга гына урын бар. Ангара күңеленә Енисейның көче, елгырлыгы, аксыл бөдрәләре кереп урнашкан булган.

Тик әтисе барысын да үзенчә хәл иткән. Байкал күптән инде Иркут баһадирны күз уңында тотып йөргән була. Үзе көчле, үзе вәкарь – кызына менә дигән кияү. Инде килешәбез дигәндә, Ангара киреләнә башлый бит. Гомердә күрелмәгән хәл: тыныч, тыңлаучан кызы Иркутка кияүгә чыгарга каршы! Үз сүзеннән кайтмаска күнеккән Байкал туй алдыннан тыңлаусыз кызын йозак астына утырткан. Әйдә, уйлансын, ата сүзенә колак салсын, дип уйлаган.

Ангара таш капчыкта күз яшьләрен түккән, сөйгәнен ярдәмгә чакырып та караган, тик файдасыз, Енисей бик еракта, ишетмәгән шул. Ангара дусларын ярдәмгә чакырган. Елгалар һәм инешләр бик тиз килеп җиткәннәр, Ангара бикләнгән зинданның стеналарын юдыра башлаганнар. Ә вакыт бара, туйга барысы да әзер. Ангара елаудан туктаган. Бөтен көче белән стенага китереп бәргән, таш дивар селкенеп куйган. Икенче тапкыр китереп бәргән – таш ярылган. Бөтен көчен җыеп өченче тапкыр бәргән икән, гранит стена җимерелеп төшкән. Ангара шатланып йөгереп тә чыккан, дуслары – елга-инешләргә рәхмәт әйтеп, сөйгәне янына ашыккан.

Ангараның юкка чыкканын Байкал күреп алган:

– Тукта! Тукта, акылсыз!

– Юк, әтием, мин Енисейга китәм! – дип җавап бирә Ангара.

– Китмә, кайгыдан гүргә кертәсең! – дип шаулый Байкал.

– Хуш, әтием, – дип кычкыра Ангара.

Байкал ачуыннан тешләрен кыскан, үкереп җибәргән. Суларын күбекләндереп,

күкләргә кадәр күтәргән. Ангара ваклаган ташларның берсен алып, качкын кыз артыннан аткан. Соң булган шул инде... Күпме генә котырынса да, Байкал берни дә үзгәртә алмаган. Кыз сөйгәне янына йөгереп килеп җиткән, аңа тугры хатын булган. Янәшә басып, күзгә күз карашып, киң далалар буйлап йөгергәннәр дә йөгергәннәр Енисей белән Ангара. Дус һәм тату яшәп, мул сулары белән тирә-юньдәге кешеләргә бәхет-шатлык китергәннәр алар.

Яши-яши, тыңлаусыз кызын Байкал баһадир да кичергән. Ата белән кызның бәхәсе хатирәсе булып, Ангара башында Шаман-таш калкып тора – кыз качып киткәндә аның артыннан Байкал-ата ыргыткан кыя-таш шул инде.





БУРЯТСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# О Байкале и Ангаре

Богат Байкал – седой богатырь. Много сокровищ скопил он за тысячи тысяч лет, собирая ясак с окрестностей. Несут ему богатства со всех ближних гор и долин более трёхсот верных слуг. Есть у него одна-единственная дочь – Ангара. Прекрасна Ангара и ликом, и нравом, спокойным и добрым. Весть о её красе облетела весь мир. Сватались к ней лучшие женихи – самые богатые, самые уважаемые, самые сильные. Всем женихам отказывала красавица без сожаления. Один только красавец Енисей пришёлся ей по душе. Сила, ловкость и светлые кудри его очаровали Ангару. Но Байкал по-своему решил, по-отцовски распорядился. Давно приглядывался к богатырю Иркуту. Могуч и важен Иркут, чем не зять? Но тут вдруг всегда послушная дочь воспротивилась, заупрямилась. А отец привык на своём стоять. И назначена уже свадьба, а строптивую дочь посадил Байкал под замок. Пусть взаперти подумает, отцовской воле покорится. Горько плакала Ангара в каменной темнице. Звала на помощь любимого, но далеко Енисей, не слышал. Тогда позвала Ангара верных друзей. Ручьи да речки тут же откликнулись. Стали они стены темницы подмывать да подтачивать. А время идёт, и к свадьбе уж готово всё. Тогда перестала Ангара лить слёзы. Ударилась о стену со всей силы – шелохнулась каменная твердь. Ударилась второй раз – треснул камень. Собрала все свои силы Ангара, вспомнила светлый лик Енисея и ударила в третий раз. Недаром она дочь Байкала! Не выдержал вековечный гранит, рухнул и рассыпался огромными глыбами. Радостно Ангара вырвалась из темницы, поблагодарила друзей – ручьи да речки. Не оглядываясь, побежала она к своему милому. Схватился тут старик-отец, закричал громовым голосом вслед беглянке:

– Стой! Остановись, неразумная!

– Нет, отец, я так решила! – отозвалась Ангара.

– Не оставляй меня, я умру от горя! – загрохотал Байкал.

– Прощай, отец! – донеслось уже издалека. Зарычал от ярости Байкал, заскрежетал зубами. Вспенил волны до самых небес. Схватил обезумевший отец первую под руку попавшую глыбу, из тех, что Ангара раскрошила, и метнул вслед беглянке. Но было поздно... Бушевал и свирепствовал Байкал, но ничего изменить не смог.

Прибежала Ангара к своему суженому, стала ему верной женой. Вместе побежали они по широким раздольям, не отводя глаз друг от друга. В мире и согласии понесли свои воды, даря жизнь людям вокруг. А скоро и отец простил непокорную дочь, смирившись с её выбором. Но, как памятный знак, высится теперь у истока Ангары величавый Шаман-камень – та самая скала, что метнул когда-то Байкал в убегающую Ангару. Тут и сказке конец, а кто слушал – молодец!



# Кечкенә балык саран байны ничек алдаган

Бервакыт еланбалык, бака һәм ташбаш бай алпавыт ятьмәсенә эләккәннәр. Бетүебез шушы икән дип елыйлар икән. Елап эш чыкмас дип, ташбаш еланбалыкка әйтә:

– Еланбалык абый, моннан котылып булмасмы икән?

– Уйласаң да, уйламасаң да юк, – дип җавап биргән еланбалык, күз яшен сөртә-сөртә, – ятьмәдән чыгу әмәле юк. Инде бамбук үрентесеннән тәмләткеч тә ясый башлаганнардыр.

Ташбаш бакага эндәшкән:

– Бака түти, син ни диярсең, үлемнән котылып булырмы?

Бака күзен кыскалап бакылдаган:

– Иртәгә еланбалык белән син табада сикерерсең, мине шешкә эләрләр.

Еланбалык белән бака тагын сулкылдый башлаганнар. Ташбаш бу тозактан котылу хакында уйлый, ди. Бераздан ташбаш еланбалык белән баканы чакырган.

– Абый! Түти! Таптым бит! Котылабыз! – ул әйтеп тә бетермәгән, еланбалык белән бака аны бүлдереп сорашырга тотынганнар:

– Ничек? Әйт тизрәк!

– Байларның барысы да саран була, – дигән ташбаш, – безне күрү белән шатлыгыннан башын югалта ул. Бай ярга тартып чыгару белән, бака түти, син читкә сикер, ә еланбалык агай белән без суга таба шуарбыз.

Иртәгесен бай килеп ятьмәне комга тартып чыгарган. Сүтә генә башлаган икән, бака читкә сикереп тә киткән. Бай, баканы кулдан ычкындырмас өчен, артыннан чаба, ди. Тотам гына, ди, бака сикерә дә куя! Артына борылып караса, ташбаш белән еланбалык суга таба шуышалар. Баканы онытып балыклар янына чаба бу. Өлгерми шул: бай килеп җиттем дигәндә генә, еланбалык белән ташбаш суга төшеп китәләр. Бай балыклар белән əвәрә килгән арада, бака да качып өлгерә.

Шул гомердән бирле бака ташбашны икрасы белән сыйлый, ә еланбалык, ташбашка ризык табу җиңелрәк булсын өчен, су төбендәге ләмне болгатып тора, ди.



ВЬЕТНАМСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Как маленькая рыбка обманула жадного богача

В давние времена все звери, птицы и рыбы умели говорить и жили в мире и согласии друг с другом.

Однажды угорь, лягушка и пескарь запутались в сетях, поставленных богатым крестьянином. Считая себя уже погибшими, они горько-прегорько заплакали.

Но вот пескарь спросил угря:

– Дядя угорь! Не подумать ли нам, как отсюда выбраться?

– Думай не думай – толк один! – ответил угорь, вытирая слёзы. – Завтра к нам будут готовить приправу из молодых побегов бамбука. Из сетей ведь не выскользнешь!

Тогда пескарь обратился к лягушке:

– Тётя лягушка! А ты как думаешь, удастся нам избежать смерти?

Лягушка в ответ зажмурила глаза и горестно квакнула:

– Уверена, что завтра вы с угрём окажетесь на сковороде, а я – на вертеле!

И угорь с лягушкой снова зарыдали, а пескарь постарался успокоиться и собраться с мыслями. Немного погодя он снова окликнул своих товарищей по несчастью:

– Дядя! Тётя! Я придумал, как нам спастись! Не успел пескарь договорить, как лягушка и угорь кинулись к нему:

– Что ты придумал? Говори!

– Все богачи очень жадные, – стал объяснять пескарь. – Когда хозяин сетей увидит, что попалась добыча, он от радости совсем потеряет голову. Вот тут-то и нужно быть начеку. Как только он выбросит нас на берег, тётя лягушка пусть скачет в сторону, а мы с угрём постараемся скользнуть назад в воду.

Так они и порешили. На следующее утро, едва богач вытряхнул улов на песок, лягушка сразу же быстро поскакала в сторону. Богач погнался за ней, несколько раз даже пытался схватить её, да всё тщетно. Тогда он оглянулся назад, а пескарь

с угрём уж у самой воды! Бросился богач к ним, но и тут не успел: рыбы юркнули в омут перед самым его носом, а лягушка тем временем ускакала в кусты.

С тех пор лягушка в знак благодарности всегда мечет свою икру в воду и кормит ею пескаря, а угорь поднимает со дна ил, чтобы пескарю легче было находить в нём пищу.



# Зирәк бәдәви

Бер гарәп чүлдә иптәшен югалткан. Күне буе эзләп тә таба алмаган. Кичкә каршы бер бәдәвине очратып, аннан иптәше турында сораша башлаган.

– Иптәшең юан һәм аксак идеме? – дип сораган бәдәви.

– Әйе, кайда ул? – дип сораган гарәп.

– Кая икәнен белмим. Шунысын да әйт әле, аның кулында таягы бар идеме? Дөясенә финик төялгән идеме? Дөясенең бер күзе дә юкмы?

Гарәп сөенеп кычкырып җибәргән.

– Әйе, бу – ул! Минем иптәшем, дөясе дә аныкы. Бу эсседә бик арыдым, эзләп тә таба алмадым бит. Кайчан күрдең син аларны? Кай якка киттеләр?

– Кичәге көннән бирле синнән башка беркемне дә очратканым юк. Мин аларны күрмәдем, – дип җавап биргән бәдәви.

– Син нәрсә, миннән көләсеңме? – дип бүлдергән аны гарәп. – Бөтен нечкәлекләренә кадәр сурәтләп бирдең дә, күрмәдем димәкче буласыңмы?

– Чынлап та күрмәдем, – дип җавап биргән бәдәви, – шулай да менә шушы пальма төбендә озак кына ял иткәнен, аннары Сүриягә таба китеп барганын беләм. Бу өч сәгать элек булган.

– Күрмәгән килеш каян беләсең соң син боларны? – дип кычкырып җибәргән гарәп.

– Эзләреннән, – дип җавап биргән бәдәви. Ул гарәпне кулыннан алып комдагы эзләр янына алып килгән.

– Менә кара. Монысы – кеше эзләре, болары – дөянеке, ә менә бу – таяк эзе. Кеше эзенә игътибар ит, күрәсеңме, сул аяк эзе тирәнрәк? Бу узып киткән кешенең аксак булуы турында сөйли. Менә минем эзләрем белән чагыштырып кара, минем эзгә караганда тирәнрәк эз калдырып киткән, димәк, миңа караганда авыррак гәүдәле.

Гарәп гаҗәпләнгән:

– Анысы шулай. Ә дөянең бер күзе сукыр икәнен каян белдең? Күзе белән комга тимәгән бит ул.

– Тимәгән, – дип көлеп җибәргән бәдәви, – туктаган җирендә дөя үләнне уң яктан гына чүпләгән, бу аның бер күзе генә барлыгын күрсәтә.

Гарәп тагын да ныграк гаҗәпләнгән:

– Ә финиклар нинди эз калдырган?

– Кырмыскаларны күрәсеңме? Алар финик согына җыелганнар.

Гарәп бик озак эндәшми торган.

– Ә вакытны каян белдең?

Бәдәви пальмага төртеп күрсәткән:

– Кара әле, күрмисеңмени, иптәшең дөясе белән монда ял итеп киткән.

– Анысын күрәм, ә вакытын каян беләсең?

– Пальманың күләгәсенә кара. Кеше кояшта ял итеп утырмас бит инде. Әлбәттә, иптәшең күләгәдә утырган. Күләгә ул утырган урыннан хәзерге урынга күчсен өчен өч сәгать вакыт кирәклеген һәрбер бәдәви белә.



# Проницательность бедуина

Один араб потерял в пустыне своего товарища с верблюдом. Целый день искал он его и не мог найти, а вечером повстречал бедуина. Араб обрадовался и начал расспрашивать о своём пропавшем товарище и его верблюде.

– Товарищ твой толстый и хромой? – спросил бедуин.

– Да. Где он? – воскликнул араб.

– Я не знаю, где он. Но скажи мне, в руках у него была палка? А верблюд его был одноглазый и вёз финики, да?

Человек обрадовался ещё больше и закричал поспешно:

– Да, да! Это мой товарищ и его верблюд. Но меня одолела усталость. Как я буду искать их в такую жару?! Когда ты видел их? Куда они пошли?

Бедуин ответил:

– Я не видел их и вообще со вчерашнего дня никого, кроме тебя, не встречал.

– Ты что, смеёшься надо мной?! Как ты не видел, если только что подробно описал моего товарища и его верблюда?

– Да, я не видел его, – спокойно повторил бедуин. – И всё же я знаю, что он долго отдыхал под этой пальмой, а потом отправился по направлению к Сирии. И всё это было три часа тому назад.

– Откуда же ты знаешь всё это, если ты не видел его?! – воскликнул араб.

– Я не видел его, – ответил бедуин. – Но я узнал о нём по его следам.

Он взял араба за руку, подвёл его к отпечаткам следов на песке и сказал:

– Посмотри на эти следы. Это – следы ступни человека, это – след верблюжьего копыта, а это – отпечаток палки. Посмотри на следы человека. Видишь, отпечаток левой ноги глубже и больше, чем правой? Не говорит ли это о том, что человек, проходивший здесь, – хромой? Теперь сравни его следы и мои – он оставил более глубокие отпечатки, чем я. Разве это не значит, что он более тучный, чем я?



Араб удивился и сказал:

– Всё это очень хорошо. Но скажи, как ты узнал, что у верблюда один глаз? Ведь глазом-то он не касался песка.

– Это верно, – засмеялся бедуин. – Глаз его не касался земли. И всё-таки он оставил на ней свой след. Разве ты не видишь, что верблюд щипал траву только с правой стороны? И разве это не говорит о том, что у верблюда один глаз и поэтому он видит только одну сторону дороги?

Ещё больше изумился араб и спросил:

– А какой след оставили финики?

Бедуин прошёл вперёд шагов двадцать и сказал:

– Посмотри на этих муравьёв, которые собрались здесь. Разве ты не видишь, что их привлёк сок фиников?

Араб долго молчал, потом спросил наконец:

– А время? Как ты мог определить время?

Бедуин указал на пальму и сказал:

– Посмотри сюда. Неужели ты не видишь, что твой товарищ отдыхал здесь со своим верблюдом?

– Но как же ты догадался, что это было три часа тому назад?

Бедуин снова рассмеялся и объяснил:

– Посмотри на тень от пальмы. Ведь не думаешь же ты, что человек откажется от прохлады и сядет отдыхать на солнце? Конечно, твой товарищ отдыхал в тени. Я кочевник и знаю, что нужно около трёх часов, чтобы тень от места его привала переместилась на то место, где она сейчас.



# Бетмәс-төкәнмәс әкият

Яшәгән, ди, бер патша. Ул әкият тыңларга яраткан. Көннәр буе урыннан тормый ята, әкият сөйләтә, ди. Әкиятчеләр патша йоклаган арада гына ял итеп ала икән. Патшалары әкият яраткан бу патшалыкта ничек яшәгәннәрен күз алдына китерәсезме?

Патша яраннарына нәрсә: әкият тек әкият, сөйләргә тек сөйләргә. Ә гади халык борчыла башлаган. Әкияттән башканы белмәгән патша ничек ил белән идарә итә алсын инде? Халыкка бит яшәргә дә, ашарга да кирәк. Ничек тә патшаны әкияттән биздерергә кирәк дип уйлаганнар.

Үч иткәндәй, патша озын әкиятләр яраткан. Атналар, айлар буена сузылганнарын. Ә бер әкиятне хәтта мең дә бер кичә буена сузганнар.

Әкиятнең дә бер ахыры була. Тыңлый торгач, бөтен әкиятләр дә сөйләнеп беткән. Бер әкият тә калмаган. Патша кайгысыннан авырый башлаган. Авырый башлаган да әйткән:

– Бетмәс-төкәнмәс әкият сөйли белүчене тапмасагыз терелмим, – дигән ул.

Патшалыкның төрле почмакларына чапкыннар җибәрелгән. Алар, патшаның бетмәс-төкәнмәс әкият белүчене эзләве турында хәбәр тараткannar. Алай гына да түгел, патша ул кешегә бер капчык алтын һәм үзенең кызын кияүгә бирергә вәгъдә итә, ди.

Бер дә аз бәя түгел, ә кем белә соң әле ул бетмәс-төкәнмәс әкиятне?

Бөтен кеше дә килеп ялкытмасын өчен патша бер шарт өстәгән: әкият сөйләп туктаучы башыннан колак кагачак!

Халык борчуда икән: ничек кенә итеп патшаны акылга китерергә? Ниһаять, бер батыр табылган бит. Әллә башы кадерле булмаган, әллә башкаларны коткару өчен үз башын кызганмаган – анысы билгесез. Кем акыл биргәндер: атасымы, бабасымы, әллә үзе зирәк булганмы?

Килгән егет патшага, башын орган һәм:



– Бөек падишаһым, бетмәс-төкәнмәс әкият сөйләүчегә бер капчык алтын белән кызыңны вәгъдә иткәнсең дип ишеттем, хакмы шул? – дип сораган.

– Вәгъдә иттем, – дигән патша. – Вәгъдә – иман. Шартымны беләсең булыр?

– Алай булса, мин риза, – дип җавап биргән егет.

Кул сугышканнар. Патша шатлана: йә әкият була, йә егетнең башы муены белән хушлаша. Тегеләй дә яхшы, болай да начар түгел. Патша кәнәфиенә сузылган да әйткән:

– Әйдә, сөйлә!

Егет паласка утырып сөйли дә башлаган:

– Яшәгән, ди, бер патша. Ул үзенең иксез-чиксез патшалыгындагы кырлардан бодай җыеп алган да аларны бер амбарга китереп аударган. Амбары бик зур булган, атка атланган килеш тә бер көн эчендә әйләнеп чыгарлык түгел, ди. Илнең башкаласына бәхетсезлек килгән бит – саранча явы ябырылган. Шулкадәр күп, ди, саранча: өйләргә тулалар, урамда кыштырдап яталар, хәтта кояшны каплап бетергәннәр. Бер көн эчендә илдәге бөтен виноградлыкларны кимереп, бөтен урманнарны сыдырып чыккан саранча явы. Тегендә-монда йөргәндә, амбардагы бодай исен сизеп алган бит болар. Амбарга керергә тырышып караганнар, керә алмаганнар. Амбар кирмән кебек тора, ди, тәрәзәсе дә юк, тишек-ярыклары да юк, ишекләре ябык. Бер саранча тәки тапкан бит бәләкәй генә бер тишекне. Тишек шундый да бәләкәй булган, аңа бер саранча гына сыйган. Саранча бер ярма алган да кире чыккан. Икене ала алмаган, ике ярма белән тишеккә сыймаган. Аның артыннан икенче саранча кереп киткән. Икенчесе артыннан өченчесе. Өченчесе артыннан дүртенчесе. Берсе чыга, икенчесе керә, ди.

Көннәр үткән, атналар, айлар, безнең кыю егет патша каршында утыра, үзе һаман әкият сөйли, ди:

– Аннары тагын берсе кереп киткән. Анысы амбардан чыккач, аның артыннан икенчесе бодайга кереп киткән...

Патша түзә алмаган:

– Әйт әле, зинһар, бу саранча амбарга кайчан кереп бетә инде?

– Падишаһым! – дип җавап биргән егет. – Саранча бит әле ярык янындагы бодайны гына ташый, ә амбарның башка җирләрендәге ашлык шул килеш ята.

– Бу саранчаның очы-кырые буламы-юкмы? – дигән ачуы чыга башлаган патша.

– Ашыкма, падишаһым, көтеп тор! – дигән егет. – Бәлки, йөз, бәлки, мең ел узар. Башта саранча бөтен бодайны ташып бетерергә тиеш. Без синең белән сөйләшкән арада тагын бер саранча ярыктан бер бөртек алып чыкты, ә аның артыннан...

Патшаның тәмам түземлеге беткән:

– Саранчаң кадалып китсен! Саранчаң белән акылдан яздырасың! Алтының да, кызым да синңа булыр, бу әкиятеңне генә туктат!

Зирәк егет шулай итеп патша кияве булып куйган. Алтынын мохтаҗларга таратып, үзе патшалык белән идарә итә башлаган. Аның эшеннән барысы да канәгать калган: халыкка гадел, зирәк, кайгыртучан патша күптән кирәк булган. Ә карт патша һаман әкиятләр тыңлап ята, ди.

# Бесконечная сказка

Жил-был один царь. Целыми днями он только и делал, что, развалившись, лежал на своём царском ложе и сквозь дрёму слушал сказки. А если рассказчик умолкал, то царь впадал в уныние, только не плакал. Вот до чего ему нравилось полёживать и слушать сказки! Поэтому ему их рассказывали целый день с утра до вечера и даже до глубокой ночи. И только когда царь наконец засыпал, измученные сказочники удалялись потихоньку на цыпочках, чтобы малость передохнуть. Представляете себе, каковы были дела в этом царстве, где царь на сказках был помешан.

Царедворцы ему льстили, ведь им всё равно было: сказки так сказки! Они царскими милостями жили, лишь бы царь доволен был, а вот простой народ забеспокоился. Народ-то трудом и потом кормился, он хотел лучшего и знал, что царя от сказок обязательно отвадить надо, да, мало того, поскорее.

А царь, на беду, любил сказки длинные. Особенно те, что ему по нескольку дней рассказывали, а то и неделями. Вот так! Одна сказка была такая длинная, что тысячу и одну ночь тянулась. Царь, слушая её, до того радовался, что даже плакать принимался.

Но в жизни всему конец приходит, как ни длинны были сказки, они все до одной кончались. И царь расстраивался. И случилось так, заболел однажды царь. Заболел и сказал:

– Пока, – говорит, – не найдёте вы такого сказочника, который бы бесконечную сказку знал, буду болеть и ни за что не поправлюсь! Вот как хотите, а будет так, а не иначе!

Поскакали гонцы во все стороны царства сказочника искать, который бы знал бесконечную сказку. Обещал ему царь величайшую милость – мешок золота и дочь свою за него замуж выдать.

Что ж, на худой конец, для бедняка совсем неплохая плата! Только вот кто её, бесконечную сказку-то, знает?

Но, чтобы люди зря не толклись, царь ещё одно условие добавил: кто за сказку примется, а у неё конец будет, тому сразу, не мешкая, отрубать голову!

Как услышали об этом любители разбогатеть, тотчас отпала у них охота богатство лёгкое нажить.

А народ о другом думал: как царя образумить. Так вот и нашёлся смельчак. То ли ему голова своя была не дорога, да кто в такое поверит? Вернее всего, не боялся он за людей голову свою отдать, вот что. А кто помог – неизвестно: может, отец его, или дед, или другие старики, одним словом, в народе он ума набрался, да и сам сметлив был.

Пришёл к царю, поклонился, спросил:

– Говорят, великий царь, что обещал ты наградить мешком золота и дочь выдать замуж за того, кто тебе бесконечную сказку расскажет?

– Обещал, – говорит царь. – А раз обещал, значит, награжу и выдам. А если с концом сказка будет – голову отрублю.

– Коли так, – сказал парень, – уговор у нас будет твёрдый. Я согласен.

Ударили по рукам. Царь радуется: или сказка будет, или у парня голова с плеч слетит. И так хорошо и эдак неплохо! Вот и развалился царь на своём царском ложе и сказал:

– Ну, давай рассказывай!

Уселся смельчак на половичке, напротив царя, и начал:

– Жил-был царь. Собрал он пшеницу со всех полей своего необъятного царства и ссыпал в один амбар. А амбар-то этот был такой огромный, что, если вдоль него на лучшем коне скакать, так за день его не объедешь! И случилась напасть: на столицу того царя налетела туча саранчи. Да такая огромная, что солнце заслонила. На улицах шелестит, в дома ломится, от саранчи этой дышать нечем. Дня не прошло, пожрала саранча все виноградники, все леса пожрала и не насытилась. Заметалась туда-сюда... И тут-то пшеницу в амбаре почуяла. Налетела саранча на амбар, да без толку. Стоит амбар, как крепостная стена: ни окон в нём, ни щёлочки. А двери наглухо закрыты. Сколько дней крутилась саранча возле амбара! Наконец одной повезло: нашла-таки дырочку самую маленькую. Да такую, что только одна туда и пролезла.

Пролезла и взяла одно зёрнышко. С двумя-то бы назад не выползла: в щёлочку не прошли бы два зёрнышка. Выползла саранча обратно. А за ней вторая полезла. Эта тоже одно зёрнышко пшеницы взяла и назад выползла. Ну, за второй третья в амбар пробралась. Только выбралась, а за ней – четвёртая... И пошло, и пошло: одна за другой полезли. Одна вылезет, другая лезет.

...Дни шли, недели, месяцы, сидит перед царём смельчак-парень и твердит своё:

– Потом ещё одна в амбар пролезла. Только вернулась, за ней другая. А эта с зерном пшеницы вернулась, ещё одна полезла...

Не выдержал наконец царь и спросил:

– Скажи на милость, сколько времени саранча в амбар лазить будет?

– О великий царь! – ответил умный парень. – Это ещё только она у самой щёлочки пшеницу вытаскивает, а пшеница вся в амбаре целёхонькая лежит!

– Ну, а конец-то, – сказал царь в гневе, – конец этой саранче будет?

– А вот с этим ты, ваше величество, погоди! – сказал парень. – Может, сто, а может, тысяча лет пройдёт. Только сначала саранча должна всю пшеницу вытащить, а уж потом будь что будет, тогда и речь о том пойдёт... А пока мы с тобой так беседуем, ещё одна саранча в щёлочку пролезла и одно зёрнышко пшеничное взяла и обратно из амбара вылезла. А за ней...

Тут царь не выдержал да как закричит:

– Будь она проклята, твоя саранча! Ты с ума с ней сведёшь! Забирай скорее мешок с золотом и дочку, только оставь меня в покое!

Так и женился на царёвой дочери умный тот человек. Мешок-то с золотом он людям роздал, а сам стал царством править. И все довольны были, потому что он правил с умом, с заботой. А царю не до того было: стали ему сказки покороче рассказывать, у которых был конец. Они и интереснее. Вот он и занят был делом, слушал их и не мешал тому царством править, кто мудр был и опыт имел.



# Көлөргеч

Борын-борын заманда Көлөргеч дигән бер кеше яшәгән. Ул шундый ялкау булган, һичнәрсә эшләргә теләмәгән. Көннәр буена учак янында, эше булмаганнан көлгә өреп, шунда казынып утыра икән. (Әнә шуның өчен аны күршеләре Көлөргеч дип йөрткәннәр.) Ярый әле, аның турында кайгыртучы карт апасы булган, югыйсә ул инде әллә кайчан ачтан үлгән булыр иде. Бу хәлгә апасының һич түзәрлеге калмаган.

– Әй, тыңла әле! Синең оятың кая? Тор, бар, эшлә! Сине туйдырам дип хәлдән тайдым бит инде.

Тормый торсын әле! Учак төбендә утыра бирә, ди, Көлөргеч, берничек тә урыныннан кузгатыр хәл юк, ди.

Ахырында бер бәйрәм көнне Көлөргечебез йөреп, кешеләр күреп кермәкче булган. Әйләнеп кайтса, ишек бикле, ди. Апасы аны өйгә кертмәгән, тәмам туйдырган ул апасын.

– Куасың икән, юлга бирәр нәрсә бир син миңа, болай булмый бит инде! – дип ялына башлаган Көлөргеч.

Апасы аңа тәрәзәдән бер без, кәҗә сөтеннән яңа гына ясалган бер баш сыр һәм бер капчык көл ташлаган.

– Боларга да тормыйсың әле син! – дип кычкырган ул ачуын тыя алмыйча.

– Монысына да рәхмәт, – дигән Көлөргеч һәм юлга чыгып киткән.

Күп йөргәндерме, аз йөргәндерме, анысы билгеле түгел, шулай да ул мул сулы елга янына барып җиткән һәм елганың икенче як ярында зур, куркыныч дию күргән. Дию суга иелгән дә су эчеп тора, ди.

Көлөргеч бик курыккан, ләкин ни эшләмәк кирәк? Башка юлны да белмәгән ул, ә алга барсаң – диюгә азык буласың. Уйлаган, уйлаган да уйлап тапкан: «Тукта әле, тузан туздырыйм да диюне куркытыйм. Алар акылга чамалы булалар бит».

Ул капчыгын без белән тишкән дә, аны селки-селки, яр буенда йөри башлаган. Көл чәчелгән, болыт кебек тузан күтәрелгән.

Курыккандырмы-юктырмы дию, ләкин бик гаҗәпләнгән һәм әйтә икән:



– Әй, син! Булдыра алсаң, менә шушы ташның суын кысып чыгар, – һәм аңа елга аша таш ыргыткан.

Көләргеч кесәсеннән үзенең яңа ясалган сырын алган һәм шундый нык итеп кыскан, хәтта аның сары сулары бармак буйлап ага башлаган.

Мондый көчлелектән дию бик нык курыккан, ә Көләргеч аңа:

– Йә әле, чык бу якка! Мине теге якка чыгар, аякларымны чылатасым килми, – дип кычкыра икән.

Дию елганы атлап чыккан да Көләргечне җилкәсенә атландыргач:

– У, нинди җиңел икәнсең син! – дип әйтә икән.

– Мин бер кулым белән күккә тотынганмын бит, шуның өчен җиңел, әгәр кулымны ычкындырсам, авырлыктан синең җилкәләрең сызлаячак.

– Йә, җибәреп кара әле, – дигән дию.

Көләргеч безен алган да диюнең муен тамырына кадаган. Дию кычкыра башлаган:

– Ай, булмаса, тотын инде күккә, түзәрлек түгел бит!..

Ярның икенче ягына чыгып җиткәннәр. Дию Көләргечне үзенә кунакка чакыра икән. Көләргеч бик курыккан, ләкин ни эшләмәк кирәк, барырга риза булган.

Менә диюгә килгәннәр. Көләргечкә диюнең көн күреше бик тә ошаган. Күрә, ди, ул: учакка чамасыз зур кеци – икмәк пешәргә куелган, ди. Дию аш әзерли башлаган, ә Көләргечкә, янып китмәсен өчен, икмәкне карап торырга кушкан.

Кецинын бер ягы яна башлавын күргәч, Көләргеч аны әйләндереп куймакчы булган. Тотынган гына икән, икмәк әйләнеп авып киткән дә Көләргечнең өстенә капланган. Ничек кенә тырышса да, ул зур, эссе икмәк астыннан чыга алмаган. Барлык диюләр җыелганнар! Кунакның икмәк астында ятуын күреп, бик гаҗәпләнгәннәр:

– Нигә син анда кереп качтың? – дип сорыйлар икән.

– Эчем авыртып китте минем, – ди икән Көләргеч, – файдасы тимәсме дип, кайнар икмәк куярга уйлаган идем! Авыртуы басылды, алып куегыз әле! – дигән ул.

Тартып чыгарганнар, ди, Көләргечне, чак кына үлми калган, ди, ул.

Өстәл тирәсенә утырышканнар.

Бөтен эчемлекләрне эчеп бетергәч, бер дию бик зур бер саплы чүмеч алган да кунакка әйтә икән:

– Туганыбыз бул, бар әле, әнә анда, ишегалды уртасында җиргә күмелгән чаннан эчемлек алып керче!

Көләргеч зур чүмечне көчкә-көчкә генә сөйрәп алып чыккан, чыккан да кире керми генә, ди. Ә диюләр эчемлек көтәләр, ләкин көтеп ала алмыйлар икән. Ишегалдына карасалар, ни күзләре белән күрсеннәр: Көләргеч тимер көрәк алган да җирдәге чанны казып маташа, ди.

– Син нәрсә эшлисең? – дип сораганнар аннан.

– Чанны берьюлы казып чыгару яхшырак булыр дим, туйганчы эчәрбез, ә бу кеп-кечкенә чүмеч белән ташый-ташый алҗып бетәрсең.

«Без, тугыз туган, буш чанны көч-хәл белән җиргә күмеп куйдык, ә бу эчемлек белән тулы чанны берүзе казып алмакчы була, җитмәсә әле, өйгә дә алып керергә тели», – дип уйлаганнар диюләр.

Диюләр эчемлекне чүмечкә үзләре тутырганнар да өйгә алып кергәннәр һәм тагын сыйлана башлаганнар. Кинәт кенә бер дию өстәл янында төчкереп җибәргән, һәм төчкерү җиленнән Көләргеч каурый кебек очып түшәмгә күтәрелгән дә матчага ябышкан. Диюләр түшәмгә карыйлар икән.

– Әй, кеше, син анда нәрсәгә мендең?

– Ничек син минем алда төчкерергә батырчылык итәсең? – дип кычкыра икән Көләргеч. – Менә шушы таякны алырмын да, кабыргаларыңны санармын мин синең!

Диюләр бик нык куркышканнар: «Без, тугыз туган, бу бүрәнәне монда көчкә генә алып кергән идек, ә ул аны таяк дип кенә атый».

Алар бар да урыннарыннан торганнар да куркуларыннан төрле якка йөгерешкәннәр, ә Көләргеч бик кыенлык белән генә идәнгә төшкән.

Олы дию урман эченнән йөгерә икән, ә аңа каршы төлке килә, ди:

– Әй, дию, нәрсә булды сиңа, кая йөгерәсең?

– Ах, сорама инде! Безгә бер кеше килгән иде, барыбызны да ашап бетерә язды.

Һәм төлкегә бу хәлләрнең ничек булуын сөйләп биргән.

– Тапкансыз икән куркыр кеше! – дип көлгән төлке. – Көләргеч бит ул, көлдә казынып ятуны гына белә. Хәтта апасы да аны өеннән куып чыгарды. Киттек әйдә, курыкма.

– Юк-юк, ышанмыйм! Барыбызны да һәлак итеп бетерер ул.

Төлке бик озак үгетләгән, ахырда кайтып киткәннәр.

Дию белән төлкене күргәч, Көләргеч шүрләгән шүрләвен, ләкин ни эшләмәк кирәк? Бусагага чыккан да кычкыра икән:

– Әй син, җирән кодагый! Уникене алып килер урында, нәрсә син миңа бер генә дию алып киләсең!

Шуны гына ишеткән икән, дию чабарга керешкән.

Ә Көләргеч котылуына бик шатланган.

– Җитәр инде, күрмәгәнне күрдем, – дигән Көләргеч һәм өенә кайтып киткән.

Карт апасыннан гафу үтенгән ул һәм шуннан бирле бөтенләй башка кеше булып киткән.

Озакламый барысы да аның кушаматын да онытып бетергәннәр. Эшли башлаган, ди, ул, хезмәте белән мал җыярга, карт апасын тәрбияләргә керешкән, ди.

ГРУЗИНСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Нацаркекиа

Жил-был, а может и нет, лентяй. С утра до вечера сидел он у очага и копался палочкой в золе. Его так и прозвали: Нацаркекиа – «копающийся в золе». Как ни старалась пожилая тётя, не могла заставить племянника работать – лентяй лишний раз даже с места не сдвинется! Надоело старой женщине кормить бездельника. Вот вышел однажды Нацаркекиа во двор, а она взяла да и заперла за ним двери. Подала ему через окошко хлеба, молодого сыру, мех золы и говорит:

– Ступай куда хочешь, корми себя, как знаешь. Вот тебе мешок золы, копайся в ней, сколько пожелаешь.

Просит, молит лентяй не выгонять его из дому, да всё напрасно. Не впустила его в дом.

Побрёл Нацаркекиа, куда ноги понесли.

Долго ли плёлся, коротко ли, очутился лентяй на берегу широкой реки. На другом берегу стоит див, пьёт воду. Как увидел его Нацаркекиа, задрожал со страху. А куда деваться? Если бежать, то див вмиг настигнет!

Нацаркекиа был ленивым, да не был глупым.

«Может, самому напугать дива? – думает он. – Прикинусь храбрым, авось он струсит и уберётся!»

Достал Нацаркекиа из кармана ножик, проткнул свой мех с золой и как заорёт во всё горло:

– Эй, мозгляк, как ты посмел воду в моей реке мутить?

Кричит, а сам по берегу прохаживается, мехом с золой потряхивает. Сыплется зола, крутится, клубится.

Смотрит див: что за чудо? Человека едва видать, а такая могучая поступь, такую пыль поднял! Схватил он с земли камень и кричит в ответ:

– Придержи-ка язык, человечишка, не то пыль от тебя останется, как от этого камня!

И див так стиснул камень, что рассыпался тот прахом. Недолго думал Нацаркекиа, нагнулся, будто подобрать камень, а сам неприметно взял в руку сыр.

– А вот что от тебя останется! – закричал он. – Гляди на мою силу! – Сжал кулак, и потекла сыворотка из молодого сыра.

Удивился див, сроду такого сильного среди людей не встречал. Решил не ссориться с ним и пригласил к себе домой, братьям своим показать. Очень не хотелось Нацаркекиа идти к диву. Не знает, бедняга, как увильнуть от приглашения. Идти страшно, и отказаться невозможно.

– Перенеси меня через реку. Неохота мне ноги мочить, – говорит он диву.

Див зашагал по воде – боязно ослушаться Нацаркекиа, и усадил его к себе на плечо.

– Эге, ну и лёгонький ты, будто пушок!

– Ещё бы, я одной рукой за небо держусь. Отпущу, так не удержишь меня.

– А ты отпусти, может, удержу.

Вытащил Нацаркекиа ножичек и вонзил острие диву в затылок. Взвыл див от боли:

– Ой, не губи! Ухватись снова за небо!

Пришли они к жилищу дивов. Дом высокий, просторный. Подивился Нацаркекиа, никогда не видел такого дома.

На очаге стоял огромный кеци. На этой глиняной сковороде дивы пекли хлеб.

Дивы попросили гостя приглядеть за кеци, чтобы хлеб не подгорел, а сами вышли во двор зажарить оленя.

Нацаркекиа показалось, будто хлеб подгорел с одной стороны. Стал он поворачивать кеци, да не справился и опрокинул его на себя! Бьётся, бедняга, никак не выберется.

Вошли дивы и рты разинули от удивления – гость под кеци!

– Что ты делаешь, человек? – спрашивает старший див.

– Спина что-то разболелась, вот и приложил я кеци, погреть кости, – отвечает Нацаркекиа. – Поутихла уже боль, сними-ка с меня кеци!

Сели обедать.

Вина в кувшине оказалось мало. Хозяева дали Нацаркекиа большой кувшин и послали за вином в марани[1].

Нацаркекиа чуть ума не лишился, как увидел этот кувшин. Он пустой кувшин еле поднял, как же с вином донесёт?

Да что было делать, потащился Нацаркекиа в марани. Ждут дивы, ждут, а гостя всё нет и нет.

Пошли дивы посмотреть, что с гостем случилось, и что же они видят: Нацаркекиа окапывает землю лопатой вокруг квёври[2].

– Ты что, спятил? – спрашивают дивы.

---

[1] *Марани* – винный погреб.
[2] *Квёври* – большой кувшин для хранения вина.

– Лучше уж вытащить квёври и распить всё вино, чего таскать понемногу кувшинчиками!

Удивились глупые дивы – они впятером с трудом врыли в землю пустой квёври, а гость один собирается вытащить его, да ещё полный вина!

Забрали дивы у Нацаркекиа кувшин, сами наполнили его вином и отнесли в дом.

Сидят все, едят, пьют. Вдруг один из дивов ка-ак чихнёт! Подбросило Нацаркекиа под самый потолок. Хорошо ещё сумел ухватиться за балку и не упал.

– Зачем ты туда забрался? – удивляются дивы.

– Как вы смеете чихать при мне! Вот вырву сейчас этот прут и всем вам живо бока обломаю! – кричит Нацаркекиа.

Затрепетали дивы, затряслись в страхе. Они вдевятером еле дотащили эту балку, а гость говорит – прут!

Выскочили дивы из дома и разбежались кто куда. А Нацаркекиа кое-как сполз вниз и стал с тех пор хозяйничать в доме дивов.

Бежит самый старший див, встречается ему лиса и спрашивает:

– Куда бежишь, что случилось?

Див рассказал. Лиса послушала и рассмеялась.

– Эх вы, – говорит, – он сам всего боится, лентяй к тому же. Целыми днями копается в золе. Тётушка не стерпела, выгнала его. Давай вместе пойдём.

Див стоит, сомневается. Идут они, а Нацаркекиа на крыльце стоит. Струсил Нацаркекиа, как увидел их, да что было делать? Вышел он на порог и кричит на лису:

– Ах ты обманщица, что ты тащишь одного дива, когда задолжала мне двенадцать!!!

Див как услышал это, бросился бежать, ну и потащил за собой лису на верёвке, а куда ей деваться. И лису всю искалечил, и сам еле ноги унёс.

А Нацаркекиа собрал всё, что мог, из дивового богатства, погрузил всё на верблюдов и отправился домой. Стал другим человеком: жил своим трудом и ухаживал за пожилой тётей.



# Яшьлек сере

Бер авылда бик гадел һәм намуслы тегермәнче яшәгән. Чит кешенең бөртегенә дә тимәгән, шул ук вакытта мохтаҗларга соңгы уч онын да кызганмаган.

Бервакыт, тегермән канавын чистартканда, ул зур кызыл алма күреп ала. Алып ашамакчы гына була, башына: «Туктале, бу мин үстергән алма түгел бит, моны ашарга да хакым юктыр», – дип, аның хуҗасын эзләп китә. Канау буйлап елгага чыга, елга буйлап өскә күтәрелә. Берникадәр вакыттан соң ак сакаллы бер картка очрый.

– Әссәламегаләйкем, аксакал! Шушындый да матур алмалар синең бакчаңда үсәме? – дип сорый тегермәнче.

– Юк, алар агым буйлап өскәрәк күтәрелгәч, минем абый бакчасында үсә, – дип җавап бирә аксакал.

Тегермәнче агым буйлап югарырак күтәрелә һәм сакалы агара башлаган бер кешене очрата.

– Әссәламегаләйкем, аксакал! Агым уңаенда яши торган картның абыйсы түгелме син? Бу алма синең бакчаңда үсәме? – дип сорый.

– Ул кеше чынлап та минем энем, ә бу алмалар минем абыем бакчасында үсә, аның бакчасы агым буйлап өскәрәк күтәрелгәч булыр, – дип җавап бирә бу кеше.

Агымга каршы бара торгач, тегермәнче бер ак чәче дә булмаган бер кешене очрата.

– Әссәламегаләйкем, агай. Бу алма синең бакчаңда үсәме? Агым уңаена яши торган картларның абыйсы синме инде ул?

– Вәгаләйкемәссәлам! Әйе, мин инде ул. Алманы да мин үстердем. Әйдә, юлчы, түрдән уз, кунагыбыз булырсың.

Тегермәнче өйгә узган.

– Хатын, безгә ашарга китерсәңче. Карбыз алып килергә дә онытма, – дигән өлкән аксакал.

Алар аштан авыз иткәч, хуҗабикә карбыз китергән. Хуҗа карбызны кискән дә әйткән:

– Бу карбыз өлгермәгән әле, әйбәтрәген китер!



Хуҗа шулай итеп хатынын биш тапкыр карбыз алырга җибәргән, бары тик бишенчесендә генә карбызны яраклы дип тапкан.

Тегермәнче, хуҗаларга рәхмәт әйтеп, кайтыр юлга кузгалган. Саубуллашыр алдыннан хуҗадан:

– И хуҗа, бер соравыма гына җавап бир әле. Ни өчен син, туганнарның иң өлкәне, барыннан да яшьрәк күренәсең? – дип сораган.

– Күргәнсеңдер, мин хатынымны карбызга биш тапкыр җибәрдем. Шул ук вакытта аның да, минем дә – беребезнең дә ачуы чыкмады. Без бик тату яшибез, бер генә вак-төяккә дә исебез китми. Энеләремнең, кызганыч, тормышлары андый ук түгел.

Шулай итеп, тегермәнче мәңге яшь калу серен белеп кайткан, ул да гаиләсе белән татулыкта, тынычлыкта яши башлаган. Йөз яше тулганда да аның ак чәчләре сирәк булган дип сөйлиләр.



# Секрет молодости

В одном ауле жил мельник, человек честный и справедливый. Никогда не брал он ничего чужого и готов был поделиться последней горстью муки с нуждающимся.

Однажды он расчищал мельничную канаву и увидел большое спелое яблоко, которое несло водой. Хотел было съесть его, но подумал: «Это яблоко не я вырастил и поэтому не имею права его есть». Но красота яблока его поразила, и он решил узнать, откуда оно.

Пошёл мельник вдоль канавы к реке и через некоторое время повстречал старика с белоснежной бородой.

– Салам алейкум, о старец! Не в твоём ли саду растут такие прекрасные яблоки?

– Нет, добрый человек, они растут выше по реке в саду моего старшего брата.

Мельник пошёл дальше и встретил пожилого человека, у которого в бороде было много седых волос.

– Салам алейкум, старец. Не ты ли старший брат того почтенного старика, что живёт ниже по реке? И не в твоём ли саду растут эти яблоки?

– Этот человек действительно мой младший брат. А яблоки эти растут в саду нашего третьего, самого старшего брата, который живёт ещё выше по реке.

Через некоторое время мельник встретил моложавого человека без единого седого волоса.

– Салам алейкум, добрый человек. Не из твоего ли сада эти яблоки? И не ты ли старший брат стариков, живущих ниже.

– Ваалейкум ассалам! Я старший из братьев, и эти яблоки вырастил я. Но заходи же, путник, в дом, будь гостем.

Мельник принял приглашение.

– Жена, дай нам поесть, да не забудь выбрать самый спелый арбуз, – сказал старший брат, заходя в дом.

Когда они поели, жена принесла арбуз. Хозяин разрезал его и сказал:

– Это неспелый арбуз, принеси-ка получше!

Пять раз муж посылал жену за новым арбузом, и только последний ему понравился.

Поблагодарил мельник хозяев и спросил:

– О гостеприимный хозяин! Разреши задать тебе один вопрос. Как могло случиться, что ты, самый старший из братьев, выглядишь так молодо?

– Ты видел, как я пять раз посылал свою жену за арбузом. Ни я, ни она при этом нисколько не раздражались. Знай, мы с женой живём в отменном мире и согласии, и ничто до сих пор не омрачало нашу жизнь. Мои младшие братья, увы, не могли этого добиться.

Так узнал мельник секрет молодости и с тех пор стал жить с женой в мире и согласии. Говорят, что даже после ста лет у него почти не было седых волос.



# Карт шайтаннарны ничек алдаган

Тау итәгендәге урман авызында салынган бәләкәй генә балчык сакляда[1] карт белән карчык яшәгән. Карт ауга йөргән, карчык йорт-җир караган.

Беркөнне карт куак астында йоклап яткан куянны күреп алган. Ләкин атмаган, кызганган. Бара-бара тау куышында балалары белән аюны очраткан. Аңа да тимәгән.

Бу елларда урманга шайтаннар килеп урнашкан. Алар, урманны үзләренеке санап, картны куып җибәрергә булганнар. План корганнар. Иң элек шайтаннарның олысы Паң-Паң барырга булган. Ул болай дигән:

– Мин барам да әйтәм, «Әйдә, картлач, көрәшәбез! Җиңсәң, урманыбызда йөрерсең, әгәр мин җиңәм икән, урманга ике аягыңның берсен дә атламыйсың» диярмен.

– Шәп уйлап таптың син! – дип кычкырганнар шайтаннар.

Шулай иткәннәр дә. Паң-Паң урман ешкынлыгында картны эзләп тапкан да:

– Мин – Паң-Паң, иң куркыныч шайтан! Әйдә, картлач, көрәшәбез! Җиңсәң, урманыбызда йөрерсең, әгәр мин җиңәм икән, урманга ике аягыңның берсен дә атламыйсың, – дигән.

– Ярый соң, мин риза, – дигән карт. – Тик иң элек минем энем белән көрәшеп кара, минем белән көрәшсәң, йә кабыргаларың сынып бетәр.

Шулай дип, карт шайтанны мәгарә авызына алып килгән.

– Минем энекәш менә шушында яши. Кер дә көрәш. Аны җиңсәң, минем белән көч сынашырсың.

Паң-Паң аны тыңлаган да тау куышына кереп киткән. Кыштырдаган тавышка уянып киткән аю, арткы аякларына күтәрелеп, Паң-Паңны бәргәли башлаган. Бәргәләгән-бәргәләгән дә чокырга чыгарып ташлаган.

---

[1] *Сакля* – йорт.



Пан-Пан көчкә-көчкә генә чокырдан үрмәләп чыкса, карт көлемсерәп басып тора икән:

– Минем белән дә көрәшеп карыйсыңмы соң?

Пан-Панның сүз әйтерлек тә хәле булмаган, ул, картны күрмәмешкә салышып, урман эченә кереп киткән.

Кайтып, хәлне сөйләп биргәннән соң, ул:

– Аны җиңеп булмый, – ди.

Ярар, шайтаннар уйлый инде, тагын ни эшләп карарга? Иң тиз, иң җитез шайтан Таң-Таң:

– Әйдәгез, мин аны йөгерешкә чакырам, ул мине уза алмас, – ди.

– Шәп әйттең! – дип, шайтаннар шатланышалар инде.

Таң-Таң урман арасында картны эзләп таба да әйтә:

– Мин – Таң-Таң, иң җитез, иң йөгерек шайтан. Әйдә, картлач, узышабыз! Җиңсәң, урманыбызда йөрерсең, әгәр мин җиңәм икән, урманга ике аягыңның берсен дә атламыйсың, – ди.

– Ярар соң, – ди карт. – Син башта минем улым белән узышып кара. Иң йөгерек шайтан булырлыгың бармы икән – шуны күрәсем килә.

Куян йоклап яткан куак янына бара да, куянга нарат күркәсе ыргыта, ә шайтанга:

– Менә шуның артыннан чап! – ди.

Куян тора да чаба, шайтангамы соң инде аны куып тоту! Ярты көн чаба куян артыннан, сыдырылып бетә, тирләп-пешә – барыбер куып тота алмый. Бер сукмакта хәле бетеп ава гына, карт килеп җитә:

– Йә, мине куып тота алырсыңмы соң? – ди, үзе көлә.

Таң-Таң, аны ишетмәмешкә, күрмәмешкә салышып, өйләренә кайтып егыла.

– Юк, беребез дә куып тота алмый аны! – ди ул.

Шайтаннар тагын баш вата, ни генә эшләп карарга да, картны ничек кенә урманнан сөреп җибәрергә? Ахырында иң кечкенәләре – кечкенә булса да, иң көчлесе, хәйләкәре Маң-Маң барырга була.

– Мин бабайлардан калган зур чукмарны алып барам. Чукмарны кем югарырак чөя, шул урманга хуҗа була, дип әйтәм, – ди.

– Шәп уйлагансың! – дип куанышкан шайтаннар.

Маң-Маң картны эзләп тапкан да аңа сүз кушкан:

– Мин – Маң-Маң, шайтаннарның иң көчлесе, иң хәйләкәре. Әйдә, карт, көч сынашабыз, менә бу чукмарны күккә чөябез. Син өскәрәк ыргытсаң, урманыбызда йөрерсең, мин өскәрәк чөйсәм, китәрсең, – ди.

– Ярар, мин риза, – ди карт. – Син беренче ташла.

Маң-Маң авыр чукмарны ала да чөеп җибәрә. Чукмар очып китә-китә тауларны да уза, болытларны да уза. Чукмар берәр сәгатьтән генә килеп төшә дә тоткасына кадәр җиргә бата.

– Инде синең чират, карт! – ди Маң-Маң.

Карт чукмарны тоткан, күтәреп ташларга көче җитми. Басып тора икән бу, үзе күккә карый, ди.

Маң-Маң түзми, сорый:

– Ник атмыйсың инде?

– Узган ел шушындый ук чукмарны атып күкне тишкән идем, шул тишекне карыйм. Болыт узып китсә, ачылыр, бәлки, башка тишек тишәсе килми иде.

– Син нәрсә, карт, – дип курыккан Маң-Маң, – бу чукмарны бөтенләйгә ташларга ярамый, ул бит безгә ата-бабалардан калган.

Маң-Маң, картның җавабын көтеп тормастан, чукмарны тартып алган да торып чапкан. Үзе чаба, үзе, карт куа килмиме икән дип, артына борылып карый, ди. Туганнары янына килеп җиткәч, булган хәлләрне сөйләп биргән.

– Бу карт берешә торган түгел, – диләр шайтаннар һәм үзләренә урманнан китү яхшырак булыр дигән фикергә киләләр.

Шулай итәләр дә. Чукмарларын алып, әллә кая таулар арасына менеп китәләр.

Карт белән карчык урман авызындагы сакляларында яшәп яталар икән. Карт ауга йөри, карчык йорт карый, ди.



ИНГУШСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Как старик шайтанов перехитрил

У подножия высокой горы, на опушке леса, стояла маленькая сакля[1], обмазанная глиной, с плоской крышей, небольшими окнами и низенькой дверью. В той сакле жили старик со старухой. Детей у них не было. Старик ходил в лес на охоту, а старуха за домом смотрела.

Однажды на рассвете шёл старик лесом и под кустом увидел спящего зайца, но пожалел его и стрелять не стал. Пошёл он дальше и в глубокой пещере заметил медведицу с медвежатами. Их он тоже не тронул и пошёл своей дорогой.

А в том лесу с некоторых пор поселились шайтаны. Они считали лес своим, и им не нравилось, что старик как хозяин бродит по лесу и охотится. Собрались они и порешили выжить старика из леса. Но как это сделать? Долго думали, но не могли ничего придумать. Наконец самый старший шайтан, огромный, страшный, – звали его Панк-Панк – сказал:

– Я выйду к нему и скажу: «Я – Панк-Панк, самый страшный среди шайтанов! Давай, старик, бороться с тобой! Если ты меня поборешь, то можешь и дальше в нашем лесу охотиться. А уж если я тебя поборю – ты уйдёшь отсюда и больше никогда в лес не будешь приходить».

– Хитро ты придумал! – закричали шайтаны.

Отыскал Панк-Панк старика в чаще, подошёл к нему и сказал:

– Я – Панк-Панк, самый страшный среди шайтанов! Давай, старик, с тобой бороться! Если ты меня поборешь, то можешь и дальше в нашем лесу охотиться. А уж если я тебя поборю – ты уйдёшь отсюда и больше никогда в наш лес не будешь приходить.

– Хорошо, я согласен, – отвечает старик, – но только сначала ты поборись с моим младшим братом, а то я боюсь, что переломаю тебе все рёбра.

Повёл он страшного Панк-Панка к той пещере, где заметил медведицу, и говорит:

---

[1] *Сакля* – дом.

– Мой младший брат живёт в этой пещере. Зайди к нему и поборись с ним. А уж если его поборешь, тогда и я стану с тобой силой мериться.

Послушался его Панк-Панк и вошёл в пещеру. А медведица проснулась на шорох, поднялась на задние лапы, обхватила непрошеного гостя и давай его мять. Помяла-помяла, в пыли поваляла и сбросила в пропасть.

Выбрался Панк-Панк из пропасти еле живой, а старик тут как тут – стоит усмехается:

– Ну что, теперь со мной поборешься? – А Панк-Панк и слова не в силах вымолвить. Притворился, что не видит старика, и побрёл в чащу. Добрался к своим, еле в себя пришёл, а потом поведал, что с ним случилось.

– Нет, никому из нас не побороть старика! – закончил он свой рассказ.

Стали шайтаны думать, советоваться, как дальше быть. Наконец средний шайтан, самый ловкий и быстрый, – звали его Танк-Танк – предложил:

– Я выйду к старику и скажу ему: «Я – Танк-Танк, самый быстрый и самый ловкий среди шайтанов! Давай, старик, с тобой наперегонки побежим. Если ты прибежишь первым, то можешь и дальше в нашем лесу охотиться. А уж если я буду первым – ты уйдёшь из нашего леса и больше никогда сюда не вернёшься».

– Хитро ты придумал!

Отыскал Танк-Танк старика в чаще, подошёл к нему и сказал:

– Я – Танк-Танк, самый быстрый и самый ловкий среди шайтанов! Давай, старик, с тобой наперегонки побежим! Если ты прибежишь первым, то можешь и дальше в нашем лесу охотиться. А уж если я буду первым – ты уйдёшь из нашего леса и больше никогда сюда не вернёшься.

– Хорошо, я согласен, – отвечает старик, – но только сначала ты моего сынка догони. Хочу убедиться, быстро ли ты бегаешь.

Повёл он Танк-Танка в ту сторону, где видел зайца, который спал под кустом. Не доходя до куста, остановился, поднял сосновую шишку и бросил в зайца, а шайтану сказал: «Беги за ним!» Заяц вскочил и бросился наутёк, а Танк-Танк помчался за ним следом. Полдня носился он за зайцем, но так и не смог догнать его. Исцарапался он, запыхался – вот-вот задохнётся. Свалился на тропинку и лежит – отдышаться не может. А старик тут как тут – стоит усмехается:

– Ну что, теперь со мной наперегонки побежишь?

А Танк-Танк и слова не может вымолвить. Притворился, что не видит старика, поднялся и побрёл скорее в чащу. Добрался кое-как к своим, еле в себя пришёл и рассказал шайтанам, что с ним случилось.

– Нет, никому из нас не обогнать старика! – закончил он свой рассказ.

Стали шайтаны думать, как дальше быть. Наконец самый младший, самый сильный и самый хитрый, – звали его Манк-Манк – предложил:

– Я возьму булаву, которая нам от наших предков досталась, выйду к старику и скажу ему:

«Я – Манк-Манк, самый сильный и самый хитрый среди шайтанов! Давай, старик, будем с тобой бросать эту булаву. Если ты бросишь её выше, чем я, то можешь и дальше в нашем лесу охотиться. А уж если я брошу булаву выше, то ты уйдёшь из нашего леса и больше никогда сюда не придёшь».

– Хитро ты придумал!

Вышел Манк-Манк из чащи, отыскал старика и сказал ему:

– Я – Манк-Манк, самый сильный и самый хитрый среди шайтанов! Давай, старик, будем с тобой бросать эту булаву. Если ты бросишь её выше, чем я, то можешь и дальше в нашем лесу охотиться. А уж если я брошу булаву выше – ты уйдёшь из нашего леса и больше никогда сюда не придёшь.

– Хорошо, я согласен, – отвечает старик, – только начнём с тебя, ты бросай первый.

Схватил Манк-Манк тяжёлую булаву, замахнулся и изо всей силы бросил её вверх. Взлетела булава выше самых высоких деревьев, выше самой высокой горы и скрылась в тучах. И только через час послышался вой и свист и булава упала, ушла в землю по самую рукоятку.

– Теперь твоя очередь, старик! – сказал Манк-Манк.

Старик взялся за рукоятку, но бросать не спешил – он знал, что такую тяжёлую булаву ему и не поднять. Стоит он, на небо поглядывает, будто высматривает что-то.

А Манк-Манку не терпится:

– Что же ты не бросаешь?

– В прошлом году я забросил на небо такую же булаву и пробил там дыру. Этой дыры сейчас не видно, её облаком закрыло. Подождём, пока облако в сторону уйдёт, чтобы не пробивать новых дыр, – отвечает старик.

– Что ты, что ты, старик! – испугался Манк-Манк. – Эту булаву нельзя насовсем забрасывать. Она нам от наших предков досталась!

Не стал он дожидаться, что ему ответит старик, вырвал булаву из земли и бросился с нею в чащу. Бежит, а сам всё оглядывается – не догоняет ли старик, чтобы отобрать заветную булаву и забросить на небо. Прибежал он к братьям своим, долго в себя не мог прийти, а потом рассказал, как старик хотел забросить на небо булаву, которая им от предков досталась.

– Нет, ничего с этим стариком нам не сделать! – сказали шайтаны.

И решили они, что лучше им самим покинуть этот лес и перебраться в другое место.

Так они и сделали. Взяли свою булаву и побрели куда-то в горы – подальше от хитрого старика.

А старик остался со своей старушкой жить в сакле на опушке леса. Он спокойно охотился в лесу, а старуха за домом смотрела.

# Алдар Күсә Җирәнчәне ничек акылга утырткан

Алдар Күсәгә йөз яшь булганда, Зирәк Җирәнчә аны беренче тапкыр күрә. Болай була ул. Җирәнчә авыл артындагы калкулыкта уйланып утыра икән. Берзаман күтәрелеп караса, дала сукмагы буйлап таякка таянган карт килгәнен күрә. Килеп җиткәч, исәнләшеп, Җирәнчә янына утыра карт. Җирәнчә аны танып ала: картаеп бетсә дә, хәйләкәр Алдар Күсәнең яңагында бер генә төк тә юк икән. Җирәнчә, аны күрүенә сөенеп, сүз башлый:

– Алдар Күсә, йөз яшькә җитеп, синең бармаган җирең, күрмәгән илең калмагандыр. Сөйлә әле, зинһар, шушындый озын гомереңдә ниләр күрдең? Бик рәхәтләнеп тыңлар идем.

Алдар Күсә җавап бирмәгән. Дәшми утыруында булган. Ишетмәде, ахры, дип, Җирәнчә соравын кабатлый. Алдар Күсә хәйләкәр елмаеп куя да китаптан укыган шикелле сөйләп китә:

– Зирәк Җирәнчә, дөрес сөйлисең син. Күрмәгән җирем, аяк басмаган урыным калмагандыр минем. Уйлаганымның барысын да эшләдем шикелле. Минем ниләр күрүемне беләсең килә синең. Ярар, җавап бирәм сиңа. Үз гомеремдә мин ун кәҗә, егерме бүре, утыз аю, кырык арыслан, аннары илле симез куй, алар артыннан алтмыш буталган һәм җитмеш өшәнгән алаша, аннары сиксән сасыган йомырка, туксан кара курган күрдем. Курганнар арасыннан болганчык су ага иде. Менә шуларны күрдем. Башка берни дә күрмәдем.

Шулай дигәч, Алдар Күсә урыныннан торган да, таягына таянып, юлын дәвам иткән.

Җирәнчә аның артыннан карап бик озак утырган. Үзалдына кабат-кабат кабатлап караса да, Алдар Күсә сүзләреннән берни дә аңлый алмаган: әллә картлыктан теләсә нәрсә сөйләп йөри, әллә аның сүзләрен аңларга Җирәнчәнең зиһене җитми?

Кәефе кырылган Җирәнчә өенә кайткан, башын салындырып, учак янында утыра, ди, бу.

– Ни булды, җаным? – дип сораган аннан хатыны Карачәч.

Җирәнчәгә үзенең Алдар Күсәне аңламавы турында әйтүе бик оят булса да, Карачәчкә йөзьяшәр белән очрашуы турында сөйләп биргән.

– Үземне белә-белгәннән бирле бәхәсләрдә оттырмый идем, Алдар Күсә мине аяктан екты, – дигән ул. – Менә шуңа кәефем төште дә инде.

Гүзәл Каракаш елмаеп болай дигән:

– Алдар Күсәнең башваткычын аңладым, ахры, мин. Гомеренең беренче ун елында кеше кәҗә бәтие кебек уйный-шаяра. Егерме яшьлек егет тормышның бөтен шатлыкларына корбанына ташланган бүре кебек ташлана. Утыз яшендә ул аюның көче белән үҗәтлегенә ия була. Кырык яшендә арыслан белән көрәшер дәрәҗәдә кыюлана. Иллегә җиткәндә, арыслан хәрәкәтчәнлеген югалтып, симертелгән бәрән шикелле тазара. Алтмыш яшендә адәмнең йөреше буталган атка, җитмешендә өшәнгән алашага охшый. Сиксәнендә ул бозылган йомырка кебек, ризыкка да батмый, чебеш тә чыгармый. Туксан яшьлек карт авыл артындагы карт курган шикелле, болганчык су – аның төссез күзләреннән аккан яшьләре. Менә, Җирәнчә җаным, шулай итеп Алдар Күсә сиңа бөтен тормышын сөйләп чыккан.

– Шулай икән шул, – дип аһ иткән Җирәнчә. – Ә нишләп йөз яше турында берни дә әйтмәгән соң ул?

– Йөзгә җиткәч, иң озын гомерле адәмгә дә теге дөньяга китәр вакыт җитә, сиңа әйтмичә генә шундый билгесез юл буйлап китеп барасыбызны аңлаткан инде Алдар Күсә дә, – дип җавап биргән Карачәч.

– Рәхмәт, Карачәч! – дигән, сөенеп, Җирәнчә. – Алдар Күсә бик зиһенле кеше икән. Син дә зирәк, Карачәч. Синең ярдәмең белән минем тәкәбберлегем кимеде, һәм акылым артты.



# Как Алдар-Косе перемудрил Жиренше

Сто лет было Алдару-Косе, когда мудрец Жиренше увидел его впервые. Случилось это так. Сидел Жиренше в раздумье на холмике за аулом. Поднял он глаза и видит: бредёт по степной дороге древний старик, опираясь на посох. Подошёл ближе, поздоровался, сел рядом. Тут Жиренше и узнал в путнике Алдара-Косе: ведь и в глубокой старости не было у хитроумного Алдекена ни волосинки на подбородке. Обрадовался Жиренше такой встрече и повёл разговор:

– Алдар-Косе, ты прожил на свете сто лет, исходил всю землю, побывал во всех странах; верно, не найдётся места, где бы ты не оставил следа. Так расскажи мне, прошу тебя, что посчастливилось тебе видеть за долгую жизнь. Буду благодарен тебе за рассказ.

Ничего не ответил Алдар-Косе. Сидел и молчал. Жиренше подумал, что старик его не расслышал, и громче повторил просьбу. Тогда Алдар-Косе посмотрел на него с лукавой улыбкой и заговорил, да так складно, точно читал по книге:

– Премудрый Жиренше, справедливы твои слова, везде я побывал, куда только не достигала моя мысль, и, что бы я ни затевал, всё мне удавалось совершить. Но тебе хочется знать, что я видел в жизни. Ладно, отвечу на твой вопрос. Видел я десять козлят, да двадцать волков, да тридцать медведей, да сорок львов, затем пятьдесят тучных баранов, за ними шестьдесят спутанных и семьдесят стреноженных лошадей, потом восемьдесят тухлых яиц и, наконец, девяносто чёрных курганов, меж которых протекал мутный ручей. Вот что я видел. А сверх того ничего не видел.

С этими словами поднялся Алдар-Косе с земли и поплёлся дальше, опираясь на посох.

Долго глядел ему вслед Жиренше и повторял вслух про себя сказанное старцем, однако ничего не мог понять в странных речах Алдара-Косе: то ли выжил совсем из ума столетний дед и несёт бессмыслицу, то ли слишком он умён, так что самому мудрому не под силу постигнуть его мысли.

Раздосадованный пришёл Жиренше домой, молча сел у очага и уронил на грудь голову.

– Чем ты так расстроен, душа моя? – спросила у него жена, красавица Карашаш. Стыдно было Жиренше признаться в своём поражении, но всё же он не удержался и рассказал жене о встрече и разговоре с Алдаром-Косе.

– С тех пор, как помню себя, никто ещё не одолел меня в словесных состязаниях. А вот Алдар-Косе своими словами сбил меня с ног. Потому-то я и печалюсь, милая Карашаш.

Тогда красавица улыбнулась и сказала:

– Успокойся, дорогой, я, кажется, разгадала головоломку старого Алдара. Вот как, по-моему, следует её истолковать.

В первые десять лет дитя резвится и прыгает, словно беззаботный козлёночек. Двадцатилетний джигит рыскает по степи, что поджарый волк, набрасываясь на все радости, как на добычу. В тридцать лет человек, если не обделила его природа, обретает силу и упорство медведя. В сорок лет он доблестью и отвагой спорит со львом. К пятидесяти годам тот, кто ещё недавно был похож на льва, теряет подвижность и жиреет, как откормленный баран. В шестьдесят лет он подобен спутанному коню, а в семьдесят – ковыляет, точно стреноженный. На восьмом десятке человек становится бесплоден и бесполезен, как тухлое яйцо: не годится оно в пищу и не будет уже от него птенца. Девяностолетний же старец – что чёрный курган за аулом, а мутный ручей – это слёзы, что точатся беспрестанно из его тусклых глаз. Как видишь, мой супруг, Алдар-Косе поведал тебе в затейливых словах всю свою жизнь.

– Да, – сказал поражённый Жиренше, – это так. Но почему же старик не обмолвился ни звуком о своём столетии?

– Потому, что в сто лет наступает пора и для самого долговечного уйти из жизни, как ушёл от тебя в неведомый путь Алдар-Косе, – ответила Карашаш.

– Благодарю тебя, моя жена! – радостно воскликнул Жиренше. – Велик разум Алдара-Косе. Велик и твой разум, Карашаш. С вашей помощью и у меня сегодня прибыло ума и убавилось гордыни.





# Ширмага ясалган юлбарыс

Бер өязгә яңа башлык куйганнар – бик таләпчән һәм буйсындыручан хаким булган ул. Эшкә керешү белән, ул укымышлы кешеләрне чакырта башлаган. Шулай итеп иң гыйлемле һәм укымышлы кешеләрне үзенә каршы эш йөртмәсеннәр өчен кисәтеп куярга уйлаган. Хезмәткәрләренә өяздәге иң акыллы һәм иң белемле кешеләрне эзләп табарга боерык биргән.

Иң беренче итеп бер малайны алып килгәннәр. Каршысына бәләкәй малай кертеп бастыргач, башлык акырып җибәргән:

– Иреннәндә сөте дә кипмәгән бу маңка малайны каян таптыгыз? Каян килсә, шунда китсен!

Хезмәткәрләр, боерыкны ишетмәгән төсле басып тора биргәннәр.

– Нәрсә Будда шикелле катып торасыз? – дип кычкырган башлык.

– Бу – өяздәге иң акыллы кеше. Бер генә олы кеше дә аның белән ярыша алмый. Әгәр дворян гаиләсендә туган булса, ул, һичшиксез, йә өяз башлыгы, йә дөнья хакиме булыр иде, – дип җавап биргән өлкән хезмәткәр.

– Нәрсә сөйлисез сез! Ничек шушы аңгыра өяз белән, йә булмаса, дөнья белән идарә итә алсын? Әгәр сез әйткәнчә үк акыллы булмаса, җәзага тартам! – дигән башлык.

Хезмәткәрләр куркудан калтырый башлаганнар. Ә малай башын күтәргән дә болай дигән:

– Яхшы. Соравыгызга җавап бирә алмасам, мине җәзага тарттырыгыз!

Башлык хезмәткәрләренә юлбарыс рәсеме төшкән ширма белән бау китерергә кушкан, аннары малайга эндәшкән:

– Әй, син, бау белән бу ширмадагы юлбарысны тота аласыңмы? – дип сораган.

– Әлбәттә, сезнең боерыгыгызны үти алам, – дип җавап биргән малай. – Мин юлбарысны ишек төбендә көтәм, ә сез, әфәндем, аны миңа таба куыгыз! Мин баудан элмәк ясап, аны юлбарысның муенына ташларга әзер!



Башлык малайның кыюлыгына һәм тапкырлыгына шаккатып кычкырып җибәргән:

– Син акылдан яздыңмы әллә? Ширмага ясалган юлбарысны ничек куып булсын инде?

– Ә рәсемдәге юлбарысның муенына ничек итеп бау ташлап булсын? Хо-хо-хо! – дип көлгән малай.

Бу сөйләшүнең шаһитлары булган хезмәткәрләр рәхәтләнеп көлгән, ә малайның зиһененә шаккаткан башлык, телдән калып, бүлмәдән чыгып киткән.



КОРЕЙСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Тигр, писанный на ширме

В одном уезде появился вновь назначенный наместник – властный и строгий правитель. Вступив в должность, он первым делом взялся за обработку грамотных и умных жителей. Самоуправец решил вправить им мозги, чтобы никто не посмел его ослушаться. Он дал распоряжение слугам вызывать одного за другим грамотных и умных людей.

Выполняя приказ, слуги первым вызвали мальчика. Когда тот появился перед наместником, последний заорал:

– Зачем вызвали такого молокососа? Скажите, пусть он уходит!

Но слуги стояли молча, как бы не слыша приказа.

– Что вы стоите словно Будда? – не унимался наместник.

– Это умник. С ним по уму не идёт в сравнение никто из взрослых. Если бы он родился в дворянской семье, то стал бы наместником уезда или властелином мира, – отозвался старший слуга.

– Что за вздор! Как же такой несмышлёныш может стать местным правителем или даже властелином мира? Если докажу, что это неправда, придётся казнить вас! – заявил наместник.

Все слуги затрепетали от страха. А мальчик гордо поднял голову и сказал:

– Хорошо. Если я не смогу решить, пожалуйста, казните меня!

Наместник приказал слугам принести ширму с рисунком тигра и верёвку, а затем обратился к мальчику:

– Эй, ты! Сможешь поймать верёвкой тигра, нарисованного на этой ширме?

– Да, я могу сделать это по вашему велению, – ответил мальчик и добавил: – Я буду ждать тигра у ворот, а вы, господин, гоните его дубинкой ко мне! Я готов сделать из верёвки петлю и набросить её на шею тигра!

Наместник, растерявшийся от дерзости и смекалки мальчика, закричал:

– С ума сошёл? Как же погнать тигра, если он нарисован на ширме?

– А как же можно надеть петлю на шею тигра, изображённого на рисунке? Хо-хо-хо! – смеялся мальчик.

Присутствовавшие при этом разговоре слуги и вестовые захохотали, а наместник удалился из комнаты, лишённый дара речи.

# Төлке, юлбарыс, аю, бүре

Юлбарыс, бүре, төлке, аю – дүртәү юлдаш булды. Тапканны уртага салып, ризык итәргә вәгъдә кылыштылар. Бара торгач, бу дүртәү дөягә юлыктылар. Тегене дә «безгә юлдаш бул» дип урап алдылар.

Озак юл йөреп карыннары ачты.Төлке боларга киңәш бирде:

– И-и-и, бу дөянең бәясе ун куйга торырлык. Яз көне һәрберебезгә икешәр куй тотсак, дүртебездән сигез куй була. Ике куй дөянең үзенә дә кала, – диде. Төлке, дөяне бурычка суярга тәкъдим итеп, аңа таба борылды: «Дүртебездән сигез куй ал, икесе үзеңә калсын. Җае килсә, син яз көне барлык бурычка бирелгән куйларыңны кире алып, рәхәтләнеп ятачаксың. Куйлар буаз булса, артым белән барысы уналты булыр. Бәрәннәре синең файдаң, мондый файда гел булмый», – дип, төлке бернинди шиккә урын калдырмады.

Дөя, уйланып: «Бу зур табыш була икән, боларның куйларын алырга кирәк», – дип, үзен ун куйга бәяләп, күзе белән сөзеп, муенын сузып җиргә ятты.

Хәйләкәр төлке: «Йөргән җирем көлке, бу дөя – төлке әкәмнең милке», – дип, дөя итен бишкә бүлеп, бер өлешен – юлбарыска, бер өлешен – аюга, бер өлешен бүрегә атап, бер өлешен үзенә алды. «Дөя коры каламы әллә?» дип, бер өлешен дөягә бүлде дә үзенә тиешле иткә кушып куйды. Дөянең бүленгәннән артып калган бөерен төлке тиз арада шыпырт кына үзенә алды. Бүрегә берсен ал дип торганда, аю, тузынып: «Йөрәге юк бит», – дип ду килде.

Шунда юлбарыс:

– Дөянең бөере кайда? – диде.

Төлке: «Бүре алганга ошый» дигән булып, борыны белән бүрегә ымлады.

Ачуы килгән юлбарыс бүрене бер сугуда үтереп ташлады. Төлке, аю белән юлбарысның итләрен яшерергә тау куышына кереп китте.

Бервакыт аю белән юлбарыс килделәр дә:

– Ит кайда? – диделәр. Боларга төлке:



– Шул вакыттан бирле җәнҗалдан башлары чыкмаган нәрсәләр миңа ахырда куй бирәме, дип, дөя айнып торып китте, – диде.

Аю белән юлбарыс моңа ышанды. Төлке аларны алдап, үз артыннан ияртте дә, бер биек кыяга алып барды һәм, юлбарыска карап:

– Атаң, мәрхүм, шушы тарлавык аша теге яктан бу якка сикереп йөри иде! Син алай эшли алмыйсын бит, бик куркак күренәсең! – диде.

Юлбарыс «минме?» дигәндәй, аңа мәкерле караш ташлады. Мактанасы килде, күрәсең, йөгереп килеп, биек кыя башына ыргылып менеп китте. Төлке ялкынга май тамызды:

– Чапканы, басканы, сын-сыйфаты атасы мәрхүмгә охшаган. Азрак куркуы да булмаса, бөтенләй атасы булачак!.. – диде.

Шуннан юлбарыс кыядан сикерде.

Күкрәге таштан ташка тиеп, биле сынган юлбарыс һәлак булды. Юлбарысның сөяген чиста җиргә куйыйм дип, төлке итне елгага яшерде. Янында ялгыз аю гына калды бит. «Хәзер аю әкәмә чират җитте бит, моның да юлын табыйм», – дип уйланды. Яткан җирендә яшереп куелган итне төлке әкәң, аюга күрсәтмичә, аз-азлап ашый бирде. Аны аю белми бит, шуңа ачка алҗанып, тәмам йөдәп бетте:

– Әй, төлке дус, син нәрсә ашап ятасың анда? – диде.

– Әй, аю-пәһлеван, чыдый алмый, ачлык газабыннан эчемне ярып, эчәгемне ашап ятам. Ачлык – газап бит, – диде төлке.

– Алай булса, мин дә шулай итимме?

– Син минем кебек куркак түгел, тырышып кара. Бәлки, иртәгә әле терелеп тә китәрсең.

Аю, тиресен каты итеп тешләп, бер генә тартты, авыртудан җаны чыга язды. Ул:

– Әй, төлке дус, үз-үземне тешләдем, ләкин авыртуга түзәрлек түгел, син нинди әмәл табып ашап ятасың аны? – диде.

– Син аның җаен таба алмыйсың, әйдә, үзем булышыйм.

Аю чалкан ятты. Төлке авызы белән аюның эчәгесен сөйрәп алды. Эче ярылып, ыңгырашып, җаны күзенә күренгән аю шунда ук үлде.

Аюның, юлбарысның, бүренең, дөянең итенә төлке әкәң ялгызы хуҗа булып калды. Ул теләгәндә ашап, теләгәндә йоклап, зарыкканда иткә кереп, сусаганда су эчеп, кәеф-сафа корып йөрде.

Үткен акыллы төлке, көче җитмәсә дә, коты очып куркып, кайчандыр качып йөргән ерткычларның барын да юкка чыгарды. Хәзер бет газабыннан котылыйм дип, бер киезне авызына кабып, су буена барды. Башта койрыгын суга салды. Бет койрыгыннан качып, йонына килде. Йонын суга салган иде, йонынннан өркеп, муенына китте. Төлке муенын суга тыкты. Бетләр, өркеп, авызына капкан киезгә ябышты. Төлке, киезне суга ташлап: «Бет, нигә котырдың, хәзер синнән котылдым», дип һаваланып, үз юлы белән китеп барды.

# Лиса, тигр, медведь, волк

Встретились как-то тигр, волк, лиса и медведь. Решили они, что отныне всё у них будет общее, и пустились в путь.

Шли они, шли, навстречу им попался верблюд. Верблюду тоже было предложено стать их спутником. Верблюд согласился, дальше пошли впятером.

Долго ли шли, коротко ли, им захотелось кушать. Лиса предложила зарезать в долг верблюда:

– И-и-и, верблюд стоит десять овец. Если будем держать каждый по две овцы, то к весне будет восемь овец. – Лиса обратилась к верблюду: – Верблюд, мы тебе дадим восемь овец, а две себе забирай, а весной, ты только послушай, у тебя будут десять овец, если от них ещё ягнята родятся – ты станешь хозяином целого стада!

Верблюд думал-думал, предложение показалось ему заманчивым, он взял да согласился.

Ну и желудок
У хитрой лисицы,
Хочет верблюдом
Она поживиться!

Дело было сделано, верблюда зарезали. Мясо разделили на пять частей: тигру, волку, медведю, лисе и верблюду оставили. Часть, предназначенную для верблюда, лиса забрала себе. Оставшуюся после дележа одну почку верблюда она спрятала, вторую – втихаря подсунула волку.

Медведь начал метаться – искать сердце верблюда, а тигр – почки. «Где почки верблюда?» – зарычал он. Лиса указала на волка, тигр тут же растерзал предателя. Пока медведь и тигр разбирались с почками верблюда, лиса спрятала мясо в пещере. А когда те вернулись и начали спрашивать, где же мясо, лиса ответила:

– Верблюд, поняв, что от вас никогда не получит своих овец, встал и ушёл. Вы ведь и мясо спокойно делить не умеете, сразу начали драться.

Медведь и тигр поверили.

Лиса их потащила за собой в ущелье и сказала тигру:

– Смотри, видишь это ущелье? Твой покойный отец был ловким и бесстрашным, любил прыгать через ущелье. Ты на него не похож, ты, наверное, побоишься, – сказала она, улыбаясь.

Тигра одолела гордыня. Он ответил:

– Кто? Я? – И побежал на скалу.

Лиса подливала масла в огонь:

– Похож чуть-чуть. Вот бы ещё храбрости немного, будешь вылитый отец!

Тигр не выдержал, спрыгнул, сломал хребет и погиб. Лиса втихаря спустилась в ущелье и спрятала мясо тигра. Лиса легко избавилась от своих спутников. Рядом с ней остался только медведь.

Лиса украдкой ела мясо. Медведь не знал об этом, он думал, что верблюд воскрес и ушёл, а тигр пошёл по стопам своего отца. Он голодал, день за днём ему становилось плохо. Медведь заметил, что лиса что-то ест, и спросил:

– Лиса, а что ты ешь?

– Ох, медведь-богатырь, я не стерпела, с голодухи распорола своё брюхо, вот сижу и ем свои кишки. Голод – это мучение, – ответила лиса.

– Может, мне тоже так сделать?

– Конечно, ты смелее меня. Попробуй. Поди, тебе завтра лучше станет.

Медведь укусил себя за брюхо, да чуть не умер от боли.

– У-у-у, лиса, как ты можешь так есть? Это же больно... – застонал он.

– Ты просто не умеешь, давай я тебе покажу, – предложила ему лиса.

Медведь лёг на спину, а лиса распорола ему брюхо. Медведь тут же умер от ран.

Лиса стала хозяйкой целого воза мяса: верблюда, волка, тигра и медведя. Она жила в своё удовольствие: ела, когда хотела, пила, когда хотела. Хитрая лиса одолела всех, кого боялась больше всего в жизни. Но... остались вши.

Что делать? Придумала. Прикусила кусок войлока и подошла к речке. Сначала опустила в воду хвост. Вши с хвоста перешли на туловище. Лиса вошла в воду по грудь, вши с туловища перешли на шею. Потом – по шею. Вши перешли на войлок. Лиса выбросила войлок с вшами, встряхнулась и пошла дальше, напевая:

Вши, зачем взбесились?
Я от вас освободилась.



# Аучы белән сандугач

Яшәгән, ди, бер аучы. Бик төз мәргән булган ул, аудан бер генә тапкыр да табышсыз кайтмаган. Моның өчен аны бик хөрмәт иткәннәр.

Беркөнне аның авы уңышсыз булган. «Болай кайту оят, туктале, тагын бераз йөреп карыйм, – дип уйлаган ул. – Бәлки, берәр нәрсә эләгер».

Бара икән, күрә бу: бодай башагында сандугач утырган да өзелеп-өзелеп сайрый, ди. Аучы мылтыгын күтәреп сандугачка төзи. Сандугач аучыны күреп ала һәм калтыранган тавыш белән:

– Бетүем шушы икән. Аучы, нишләтмәкче буласың син мине? – ди.

– Атарга җыенам, – ди аучы.

– Синең яхшы мәргән икәнеңне беләм, шуңа син йөргән урманнан качтым, – ди сандугач. – Минем гәүдәм бәләкәй. Итем дә тешеңнән үтмәс, кече телеңә җитмәс, үтермә мине! Чәчәктән чәчәккә куныйм, җырларым белән кешеләрне сөендерим.

– Әй сандугач! Мин сине ашар өчен атмыйм. Табышсыз кайтканым юк, буш кул белән кайту миңа хурлык.

– Атсаң атарсың инде, аңа кадәр мин сиңа өч нәсыйхәт әйтим.

– Ярар, сандугач, әйт әйдә.

Сандугач әйткән:

– Кеше ышанмастай сүзгә ышанма. Эшләгән эшеңә үкенмә. Кулың җитмәгән җиргә үрелмә.

Бу сүзләрне ишеткән аучы коралын куйган.

– Киңәшләрең бик әйбәт икән сандугач, гомереңне өзмим, яшә!

Сандугач иң өстәге ботакка очып кунган да сайрап җибәргән:

– Әй аучы! Мин үлемнән курыкмыйм, мин сине алдадым. Минем эчемдә каз йомыркасы кадәр асылташ бар. Аны җиде патшалык байлыгына да сатып алып булмый. Мин бу таш синең кебек каты күңелле кеше кулына эләкмәсен дип курыктым.

Аучы, мылтыгын чыгарып төзәсә дә, сандугачка тидерә алмаган, аңа яфраклар комачаулаган. Аннары ул агачка үрмәли башлаган. Агач ботагы сынып егылып төшкән дә, ыңгыраша-ыңгыраша, сандугачны чакыра икән:

– Сандугач, зинһар, ярдәм ит!

Сандугач очып төшкән, аучы янына кунган да болай дигән:

– Әй аучы! Һәр авыруга дәва бар, ә сиңа юк икән.

– Нишләп? – дип сораган аучы, аптырап.

– Мин сиңа өч нәсыйхәт бирдем, берсе дә барып җитә алмады. Мин бодай бөртеген дә көчкә йотам, ә син бүтәкәмә каз йомыркасы кадәр асылташ сыйганына ышандың. Мин үзем дә аннан кечерәк бит. Мин сиңа эшләгән эшеңә үкенмә дидем. Син мине исән калдырдың, ә мин асылташ турында әйткәч, шуңа үкендең. Буең җитмәгән җиргә үрелмә дидем – сандугач утырган нечкә ботакка төбәп менеп киттең. Юк, мин сиңа ярдәм итә алмыйм, ахмак аучы. Бөтен авырудан дәва бар, ә сиңа – юк.





ЛЕЗГИНСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Охотник и соловей

В одном городе жил охотник. Он никогда не возвращался с охоты без добычи, так как был хорошим стрелком. И жители города очень уважали его.

Однажды охотник не сумел настрелять дичи. «Если я вернусь ни с чем, – подумал он, – все увидят это и перестанут меня уважать. Пойду-ка я дальше, может быть, что-нибудь попадётся, иначе стыдно возвращаться».

Охотник пошёл дальше и вдруг видит: на колосе пшеницы сидит красивый соловей и поёт чудесную песню. Охотник поднял ружьё и прицелился.

Соловей увидел охотника, испугался и, прервав свою песню, сказал дрожащим голосом:

– Настал мой конец. Эй, охотник! Что ты думаешь делать?

– Думаю тебя убить! – ответил охотник.

– Я знаю, что твоя рука верно бьёт в цель, и поэтому убежал из тех мест, где ты охотился. Моё тело слишком мало, моё мясо ни на зубы, ни на язык тебе не попадёт, не убивай меня. Оставь меня резвиться на цветах, петь и радовать сердца людей.

Охотник сказал:

– Эй, соловей! Твои слова хороши, но я тебя хочу убить не для еды. Я всегда возвращаюсь в город с добычей, а вернуться ни с чем для меня позор.

И соловей ответил ему:

– Тогда наберись терпения, я дам тебе три наставления, а потом можешь убить меня.

– Ну, говори, соловей, послушаю твои советы.

И соловей сказал:

– Не верь тому, во что нельзя поверить. Не жалей о том, что сделал. Не протягивай руку туда, куда дотянуться не сможешь.

Услышав эти слова, охотник опустил ружьё. Ему понравились советы соловья, и он сказал:

– Я дарю тебе жизнь.

Соловей взлетел на ветку высокого дерева и сказал:

– Эй, человек! Я обманул тебя. Мне смерть не страшна. У меня в желудке есть драгоценный камень величиной с гусиное яйцо. Семь царей вместе не смогут купить его. Я думал о том, что этот драгоценный камень может попасть в руки такого бессердечного человека, как ты.

Охотник схватился за ружьё и стал целиться, но не мог различить сквозь листья соловья, хотя и слышал его голос. Тогда он бросил ружьё и полез на дерево. Когда он поставил ногу на тонкую ветку, ветка сломалась, охотник свалился на землю и сильно ушибся. Тут он начал стонать и звать соловья:

– Ой, милый соловей, помоги мне!

Соловей прилетел, опустился рядом с охотником и сказал:

– Эй, охотник! От всех бед есть лекарство, но для тебя – нет.

– Почему? – спросил охотник.

– Я дал тебе три наставления, но ни одно из них не пошло тебе впрок. Я с трудом проглатываю пшеничное зерно, а ты поверил, что у меня в желудке драгоценный камень, да ещё с гусиное яйцо. Я тебе сказал: если что-нибудь сделал, не жалей. Ты подарил мне жизнь, а когда я сказал о драгоценном камне, ты пожалел. Забыл ты и третий совет – не протягивай руку туда, куда дотянуться не можешь. Я держусь на тоненьких стебельках колоса, на тоненьких веточках, а ты полез за мной на дерево, чтобы поймать меня. Нет, я тебе не помогу, глупый охотник. От всех бед на свете есть лекарство, а для тебя – нет.



# Нончык патыр

Яшәгән, ди, әби белән бабай. Аларның балалары булмаган, ди. Берзаман бабай әйткән:

– Әйдә, карчык, камырдан булса да бер малай әвәлик әле, – дигән. Карчык камыр баскан, аннан бер малай сыны ясап чүпрәккә төргән дә мичкә тыккан.

Камыр бер көн ята икән мичтә, ике көн... Түзмәгән бабай:

– Карчык, кара әле, безнең мичтәге малай нишли икән? – дип сораган.

Шулвакыт мичтән нечкә генә тавыш ишетелгән:

– Пешереп үтерәсез бит, чыгарыгыз тизрәк!

Әби белән бабай барып карасалар, чынлап та, мичтә бәләкәй генә бер малай ята, ди. Бәләкәй булса да, малай көнләп түгел, сәгатьләп үскән. Унике көн эчендә зур, көчле егет булган. Унөченче көнне әйткән малай:

– Сез мине тәрбияләдегез, үстердегез, хәзер минем чират, – дип, бер саран байга эшкә ялланган бу.

Ун кешелек эшләгән егет байның бөтен эшен кырып-себереп, җиренә җиткереп башкарган. Әби белән бабай, улларының көчен күреп, Нончык[1] патыр дип атаганнар.

Нончык патыр эшли, вакыт үтә бит инде, байның хисаплашасы көне дә килеп җитә. Саран бай, акча түлисе килмәгәч, Нончык патырны юкка чыгарырга исәпли.

Егетне чакыра да әйтә:

– Ерак болындагы сарыкларны куып алып кайт, – ди бу.

Ерак болынга сарык каян килсен, анда ач бүреләр генә бар. Бай шуңа исәп тота да: бүреләр Нончык патырны өзгәләп ташлар да, акчам янга калыр дип уйлый.

Нончык патыр ерак болынга килеп җиткән дә:

– Килегез әле монда! – дип кычкырган. – Хуҗагызны онытып, кая югалдыгыз?

Ач бүреләр, тешләрен шыкырдатып, Нончык патырны уратып алганнар. Менә-менә өзгәләп ташларлар кебек. Нончык уйлап тормаган, бер каенны тамыры-ние белән йолкып алган да бүреләрне ярырга тотынган! Бүреләр шундук, юашланып, койрыкларын кысканнар.

[1] *Нончык* – мари телендә «камыр».



Бүреләрне куып алып килгән Нончык патырны күреп, бай куркудан мич арасына кереп качкан.

– Хуҗа, капкаңны ач, көтүне алып кайттым! – дип кычкырган Нончык.

Бай:

– Сырхаулап торам, үзең генә яп инде, – дип җавап биргән.

Нончык бүреләрне абзарга япкан да печәнлектә ятып йоклаган. Үзе йоклый, гырлавыннан бөтен өй селкенеп тора, ди.

Булмады бит инде, нишләргә? Хуҗа тагын план кора, Нончыкны урманга куа. «Бүреләрдән булмады, аюлар тере җибәрмәс», – дип уйлый.

– Урманга барып, атларымны алып кайт, – ди.

Нончык патырның кулыннан килмәс эш буламы – аюларны өннәреннән куып чыгарып, көтүне авылга таба куа икән бу. Үзе:

– Хуҗагызны ташлап кая йөрисез, – дип кычкыра икән.

Аюларны абзарга япкан да Нончык тагын йокларга яткан. Хуҗа төнне йокысыз уздырган, күрше байлар белән киңәш-табыш иткән. Алары Нончык патырны Шайтан күленә җибәрергә кушканнар. Бай шулай иткән дә. Иртәгесен Нончык патырны:

– Абзам өч ел элек Шайтан күленә киткән иде, һаман кайтканы юк. Шуны чәйгә чакырып кайт әле, команмелна[1] пешертәм, – дип, йомышка җибәргән.

Кыяк үлән белән әйләндереп алынган күлнең тынчыган суы бака тәңкәсе белән капланган. Бака тәңкәсе астындагы су төпсез, ялгыш килеп кергәннәрнең берсен дә кире чыгармый икән. Шуны белгән кешеләр бу күлгә якын да килми, биш чакрымнан әйләнеп узалар, ди.

Нончыкның килеп як-ягына карануы булган, бер карт йөнтәс шайтан килеп чыгып, аны үзе белән су астына өстери дә башлаган. Нончык бирешәме соң инде! Карт шайтанның маңгаена берне биреп алган да, якасыннан күтәреп болай дигән:

– Энекәшең команмелна ашарга чакыра, әйдә, киттек!

Аларның тарткалашып кайтуын тәрәзәдән күреп торган бай:

– Киләсе килмәсә кыстама, җибәр! – дип кычкырган.

Нончык патыр, кайтып җитеп, тиешле акчасын алган да өенә кайтып киткән. Әти-әнисенә эшләп алган акчаларын биргәч, урамга чыккан бу. Ярлы баласының башы эштән чыкмый, урамда теге байның балалары гына уйнап йөри икән. Нончык алар янына барган да:

– Мине дә яныгызга алыгыз әле, – дигән.

– Очып барган укны тешләрең белән тоталсаң алабыз, – дигән байбәтчәләр.

Нончык патыр җәясен киереп атып җибәргән дә зәңгәр болытларны урап төшкән укны тешләре белән тотып та алган.

– Хәзер елганың бу төшендәге бәкедән кереп, әнә теге төштә бозны тишеп чык, аннары алабыз, – дигән бай балалары.

---

[1] *Команмелна* – мари халык ризыгы, катлы коймак.

Нончык уйлап тормаган, йөзеп тә чыккан.

– Хәзер таш тауны җимер инде, – дигән байбәтчәләр, – аннары уйнарсың безнең белән.

Нончык патыр таш тауга бер типкән – тау чайкалып куйган, ике типкән – ташлар таралып төшкән. Җиденче тапкыр типкәндә, тау җимерелгән, Нончык патырның баһадир көче беткән. Бай балалары моны аталарына кайтып әйткәннәр.

Бу хәбәрне ишетеп сөенгән бай, ялчыларына Нончык патырны, кул-аякларын бәйләп, базга ташларга кушкан. Ялчылар Нончык патырны тотып алганнар да базга салганнар.

Ята икән Нончык, бер ай, ике ай... бервакыт чокыр кырыена карга килеп кунган. Нончык каргага ялына икән:

– И карга дус, минем әти-әниемә барып әйтсәнә, улыгыз чокырда ята дисәнә, – ди икән.

Карга күзен дә йоммаган:

– Атаңны да анаңны да чакырмыйм, үлсәң, күзләреңне чокырмын, – дип очып киткән.

Саескан да Нончыкның үтенечен тыңлап тормаган.

Ул арада каз очып бара икән. Нончыкны ишетүгә ул әби белән бабай янына очкан.

– Бабай, әби, Нончыкны явызлар базга салган, ул сезне ярдәмгә чакырды. Үзегез белән бер симез үгез, үткен балта алып барыгыз.

– Мыскыл итмә, каз, – дип елап җибәргәннәр әби белән бабай. – Улыбыз күптән юк инде безнең. Калса, сөякләре генә калгандыр.

– Ул исән, – дигән каз, – ашыгыгыз, хәле бетеп бара инде аның.

Әби белән бабай ашыга-ашыга Нончык патыр янына киткәннәр. Аларның үгез куып баруын күргән карга кычкыра икән:

– Кар-кар, Нончыкка ата-анасы үгез илтә, балта илтә! Ит ашаса, Нончыкка көче кайта!

Моны ишеткән бай тизрәк ялчыларына боерган:

– Барыгыз тизрәк, базны ком белән күмегез, Нончык тончыксын!

Ялчылар килеп җиткәнче, бабай үгезне чокырга ташлап өлгергән. Нончык патыр үгезне ашап та бетергән, көче дә кире кайткан. Чылбырларын өзеп, чокырдан килеп тә чыккан.

Бу хәлләрне күреп торган бай, куркуыннан кая барганын да белми эзләрен ялтыраткан. Чаба торгач, сазлыкка туры килеп, шунда батып калган, ди.

# Нончык-патыр

Жили когда-то в одном селе старик и старуха, а детей у них не было. Говорит однажды старик:

– Давай, старуха, сделаем себе сына из теста. – Старуха согласилась и замесила тесто, вылепила из него человечка и положила на печь.

Лежит человечек из теста на печке день, лежит другой... А на третий день старик не вытерпел и говорит:

– Посмотри-ка, старуха, как там наш сыночек.

И вдруг с печки послышался голосок:

– Жарко здесь! Снимите меня с печи! – Обрадовались старик и старуха, сняли сыночка с печи, а он и впрямь как настоящий мальчик, только очень маленький.

Живёт мальчик в избе у старика и старухи и растёт не по дням, а по часам.

Рос мальчик двенадцать дней, превратился в крепкого парня, на тринадцатый день говорит старику и старухе:

– Вы меня вырастили и выкормили, теперь я буду вас кормить. Пойду наймусь к кому-нибудь в работники.

– Ведь тебе всего двенадцать дней, – сказал старик, – куда тебе работать!

– Чую я в себе богатырскую силу, – отвечает ему мальчик, – справлюсь с любой работой.

Нанялся он в батраки к одному злому и жадному богачу. Богач давал своему батраку столько работы, что и десятерым не справиться, а парень со всем один управлялся.

Прозвали люди сына старика и старухи за его силу Нончык-патыр, что значит «Богатырь из теста».

Нончык-патыр трудится, ни от какой работы не отказывается, а время идёт. И вот подошёл срок расплачиваться хозяину с батраком за работу.

И тогда жадный хозяин, чтобы не платить, задумал погубить Нончык-патыра.

Думал-думал хозяин, как погубить Нончык-патыра, и наконец придумал.

Позвал он его и говорит:

– Сходи на дальние поля и пригони оттуда моих овец.

А на дальнем поле не овцы паслись, бродили там стаи голодных волков. Понадеялся хозяин, что голодные волки сожрут Нончык-патыра.

Пришёл Нончык-патыр на дальнее поле.

– А ну, идите-ка сюда! – крикнул он волкам. – По полю бродите, хозяина забыли!

Окружили его голодные волки, зубами щёлкают, вот-вот разорвут.

Выдернул Нончык-патыр из земли берёзу с корнем и давай волков бить! Заскулили волки, поджали хвосты.

Погнал их Нончык-патыр, как овец, на хозяйский двор. Пригнал и кричит:

– Эй, хозяин, открывай ворота! Я твоих овец пригнал!

Выглянул хозяин в окошко, увидел волков, затрясся от страху и забился в дальний угол, за печку.

– Заболел я, не могу выйти! – кричит хозяин из-за печки. – Открой сам ворота и загони овец в хлев.

Загнал Нончык-патыр волков в хлев и улёгся спать на сеновале.

Спит Нончык-патыр, храпит на весь дом. А хозяину не до сна.

«Ну и работник у меня! – думает хозяин. – Даже волки ему нипочём. Как же мне его извести?»

И придумал хозяин послать Нончык-патыра в лес к медведям. «Уж медведи-то, – решил он, – не отпустят Нончык-патыра живым».

– Сходи в лес, пригони оттуда моих лошадей! – приказывает хозяин.

Пришёл Нончык-патыр в лес, поднял медведей из их берлог и погнал на хозяйский двор. Гонит да ещё покрикивает:

– А ну, идите домой! Хозяина своего забыли!

Увидел хозяин, что Нончык-патыр медведей гонит, убежал в избу, заперся на все запоры-засовы и кричит:

– Сам загоняй лошадей в хлев!

Загнал Нончык-патыр медведей в хлев и пошёл спать.

Крепко спал в эту ночь Нончык-патыр, а хозяину не до сна. Позвал он соседей-богачей, стал у них совета просить. Соседи присоветовали послать Нончык-патыра к Чёртову озеру: пусть его черти утащат.

Повеселел хозяин и говорит Нончык-патыру:

– Года три назад ушёл мой брат жить в Чёртово озеро да с тех пор ни разу ко мне в гости не наведывался. Поди-ка разыщи его и позови ко мне на команмелна[1].

Пришёл Нончык-патыр на Чёртово озеро.

Заросло озеро чёрной осокой, разлилось гнилой водой среди болота, затянулось мелкой ряской, а под ряской колышется бездонная трясина.

Это озеро люди обходили за версту, а по ночам и за все десять.

Выскочил из воды старый лохматый чёрт, схватил Нончык-патыра, потянул в

---

[1] *Команмелна* – слоёные блины, марийское национальное мучное блюдо.

трясину. А Нончык-патыр не поддаётся. Стукнул он чёрта по лбу кулаком, встряхнул за шиворот, как котёнка, и сказал:

– Брат тебя на команмелна зовёт. А ну, собирайся, пойдём в гости!

И поволок чёрта в деревню.

Увидел хозяин, что Нончык-патыр возвращается жив-невредим, да ещё тащит за собой лохматого чёрта, замахал руками, закричал дурным голосом:

– Не хочет, видно, братец в гости идти. Не держи его! Пусть он в своё озеро возвращается! – Отпустил Нончык-патыр чёрта и сказал:

– Ну, хозяин, кончился срок моей работы – теперь плати, что полагается.

Делать нечего, пришлось жадному богачу расплачиваться с работником.

Расплатиться-то расплатился, а зло затаил.

Вернулся Нончык-патыр в родной дом к отцу-матери, отдал им заработанные деньги, а сам пошёл гулять на улицу. Играли на улице дети хозяина-богача, беднякам-то не до игры – работать надо.

Подошёл к ним Нончык-патыр и попросил, чтобы приняли ребята его в свою игру.

– Поймай летящую стрелу зубами – тогда примем! – отвечают они.

Выпустил Нончык-патыр стрелу из лука прямо в синее небо. Унеслась стрела за облака, а как стала падать вниз, то поймал её Нончык-патыр зубами.

– Теперь, – говорят ему хозяйские дети, – нырни в эту прорубь, отплыви на середину реки и разломай лёд – тогда примем тебя в нашу игру!

Нырнул Нончык-патыр в прорубь, проплыл до середины реки, разбил головой толстый лёд и вышел наружу.

– А теперь разбей каменную гору – тогда примем тебя в нашу игру!

Подошёл Нончык-патыр к каменной горе, пнул гору ногой – качнулась каменная гора, пнул в другой раз – посыпались с горы камни. Семь раз пнул – рассыпалась гора в мелкие камешки, но ушла от Нончык-патыра его богатырская сила. Рассказали тогда дети своему отцу: нет уже у Нончык-патыра его богатырской силы.

Обрадовался хозяин и приказал своим слугам вырыть глубокую яму, а потом схватить Нончык-патыра, связать его крепко-накрепко и бросить в яму.

Одни слуги побежали яму копать, другие набросились на Нончык-патыра, связали ему крепкими ремнями руки-ноги и кинули в яму.

Лежит Нончык-патыр в глубокой яме день, два, месяц, смотрит в ясное небо.

Прилетела ворона, села на край ямы.

Говорит Нончык-патыр вороне:

– Ворона, ворона, слетай к моему отцу, к моей матери! Скажи им, что связали мне руки-ноги крепкими ремнями и бросили в яму, чтобы я погиб от голода и жажды.

Каркнула ворона в ответ:

– Не стану я звать твоего отца, твою мать! Умирай скорее – выклюю тебе глаза!

Улетела ворона, прилетела сорока. Она тоже не стала помогать.

Летел мимо белый гусь.

– Эй, белый гусь! – крикнул Нончык-патыр. – Лети к моему отцу, к моей матери, скажи им, что связали мне руки-ноги крепкими ремнями и бросили в глубокую яму. Хочет богач-хозяин, чтобы я погиб от голода и жажды. Уже недолго жить мне осталось! Пусть идут скорее, пусть приведут жирного быка, пусть принесут острый топор!

Поднялся гусь высоко в небо, полетел к старикам.

– Эй, дедушка! Эй, бабушка! Злые люди бросили вашего сына в глубокую яму. Зовёт он вас на помощь. Велит привести жирного быка и принести острый топор!

Заплакали старик со старухой и говорят:

– Не смейся над нами, гусь! Нашего сына нет в живых, погубили его.

– Он жив, – ответил гусь, – только спешите, уже недолго осталось ему жить.

Поверили старик со старухой гусю, пригнали к глубокой яме, где томился Нончык-патыр, быка, принесли острый топор.

Увидела старика со старухой ворона, закричала:

– Кар-кар! Идут отец и мать, гонят быка, несут топор. Если съест Нончык-патыр быка – вернётся к нему его богатырская сила и разрубит он топором свои крепкие путы!

Испугался хозяин, приказал слугам:

– Засыпьте яму песком, завалите камнями, пусть Нончык-патыр задохнётся.

А старик уже столкнул в яму быка. Съел Нончык-патыр быка, и вернулась к нему его богатырская сила.

Стали слуги заваливать яму песком да камнями, а старик уже кинул в яму топор.

Разрубил Нончык-патыр все путы, поднялся на ноги, вытолкнул песок с камнями и вышел из ямы.

Как увидел Нончык-патыра жадный хозяин, перепугался, не знает, что делать, где спрятаться.

Побежал богач, куда глаза глядят. Попалось ему на пути болото, и потонул он в том болоте.



# Йолдызчы

Яшәгән, ди, бер ир белән хатын. Тук та булмаганнар, ач та тормаганнар, ди. Ир бик тыйнак кеше булган, күп һөнәрләр белгән. Дөнья мәшәкате кырык яшендә үк аның чәч-сакалларына чал сипкән, ир үз яшеннән күпкә картрак күренә икән.

Көннәрдән бер көнне хатын мунчага киткән. Барса, мунчада ыгы-зыгы, ди. Нәрсә булган дисәләр, мунчага сарай йолдызчысының хатыны килә икән, мунча хуҗалары шуны каршы алырга әзерләнәләр, ди. Хуҗа хатыны, монда ярамый, тегендә ярамый дип, юынырга килгән кешеләрне әрле-бирле куалый, ди.

Менә музыка тавышына бер көтү яраннары белән йолдызчы хатыны килеп керә. Хуҗабикәнең күбрәк түләмәсме дип аның каршында биеп йөрүе гаҗәп түгел.

Ә безнең һөнәрче хатыны бик үртәлә моңа. Ничек кирәк алай юынып кайта да иренә әйтә бу:

– Теләсәң нишлә, сарай йолдызчысы хатыны буласым килә!

– Туктале, хатын, – ди ир, – мин бит яза да белмим, ничек итеп сарай йолдызчысы була алыйм ди. Ходай ипи-тоздан аермасын диген.

– Сарай йолдызчысы булмасаң, синең белән яшәмим! – дип кырт кисә хатын.

Нишләсен, хатынын ярата, инде нишлим икән дип баш вата башлый. Кәһвәханәгә кереп, каһвә эчеп утырганда, моның башында уе барлыгын күреп, бер иптәше килә:

– Ни булды сиңа? – дип сорый ул.

Иптәше теге мунча хуҗасының да дусты икән, моны тыңлап тора да:

– Алай борчылма әле, нәрсә дә булса уйлап табарбыз, – дип китеп бара.

Мунча хуҗасы белән киңәшәләр болар.

– Ул кеше килсен дә мунча ишеге каршына урнашсын. Алдына күн, кәгазь, кара белән каләм салсын да язып-сызып утырсын. Калганын үзебез оештырырбыз.

Иптәше килеп әйткәч, бу кешенең куркудан куллары калтырый башлый. Ул бит язу түгел, каләмне ничек тотарга икәнен дә белми! Ни генә булмасын, мунча хуҗасы әйткәнчә эшли бу. Мунчага килгән һәркем аны гыйлем иясе дип кабул итә.



Нәкъ шушы көнне мунчага сарай йолдызчысы хатыны килә. Ул юынган арада, кыйммәтле балдагын, урлап, почмактагы чүп савытына ташлыйлар. Безнең ялган «йолдызчы» бу хакта белә бит инде.

Ярар. Сарай йолдызчысы хатыны юына, киенә. Берзаман балдагы югалганны күреп ала бит бу. Эзлиләр – таба алмыйлар. Шул вакытта хуҗабикә әйтә:

– Ханым әфәнде, мунча каршында хуҗа[1] утыра. Аннан сорап карыйк әле. Белсә, ул гына белер, – ди.

Безнең күрәзәче, кәгазьгә сызгалап-бозгалап ала да:

– Ханым әфәнде, балдагыгыз чүп савытына төшкән, – ди.

Хуҗабикә, хезмәтчеләрен чакырып, чүп савытын актарып чыгарга боера. Чынлап та, балдак табыла бит. Сарай йолдызчысы хатыны, хуҗага кыйммәтле бүләкләр биреп, өенә кайта. Хатынына бу гына аз, аның барыбер сарай йолдызчысы хатыны буласы килә!

Берничә көннән шаһ хатынының балдагы югала. Аны бер хезмәтче кыз урлаган була. Эзлиләр балдакны, эзлиләр – таба алмыйлар. Шуннан теге йолдызчы хатыны теге кешене исенә төшерә дә:

– Минем балдак югалган иде, бер хуҗа шунда ук табып та бирде. Бик гыйлемле кеше, бәлки, шуннан сорап карарсыз, – ди.

Солтан шунда ук мунчага чапкыннар җибәрә. Ә теге кеше, хатыныннан куркып, көннәрен шунда үткәрә икән. Сарайга алып китәләр моны.

Шаһинә, аны күрүгә:

– Әй, хуҗа, балдагымны тапмасаң, башың белән саубуллаш! Иртәнгә кадәр вакыт сиңа, – ди.

Хуҗаны аерым бүлмәгә урнаштыралар. Хуҗа куркудан калтырый, белми бит инде ул балдакның кая икәнен! Карак кыз да бар бит әле. «Булмый бу, ярдәм сорыйм», – дип, хуҗа янына килә дә хәлне сөйләп бирә.

– Балдак миндә, зинһар, коткара күр, – дип, хуҗаның аягына егыла бу.

Хуҗа эченнән генә: «И Ходам, бүген дә коткардың бит!» – дип уйлый да кызга әйтә:

– Кызым, балдагыңны казга йоттыр. Кара аны, беркем дә күрмәсен, сизмәсен. Балдакны йоткан казның аягын сындырып куй. Бар, курыкма.

Кыз шулай эшли дә.

Таң ату белән, шаһ хуҗаны чакырта.

– И шаһым-солтаным, төне буе йокламадым, бактым, һәр багуымда кошлар чыкты. Сарайда булган бөтен кошларны бакчага чыгарт әле, күркәсе, казы, тавыгы – берсе дә калмасын, – ди.

Бөтен кош-кортны бакчага чыгаралар. Алдан хуҗа бара, үзе сызгалый-бозгалый, аның артыннан яраннары белән шаһ атлый, ди. Аксак казны күреп алгач, хуҗа әйтә:

---

[1] *Хуҗа* – «гыйлемле кеше» мәгънәсендә.

– Балдак менә шушы каз эчендә булырга тиеш, – ди.

Казны тотып алып чалалар, бүтәкәсеннән теге балдак килеп чыга. Гаҗәпләнүдән аһ итәләр инде.

Бакчадан чыгып барганда, шаһ чикерткә тотып ала.

– Йә, хуҗа, әйт әле, кулымда нәрсә? – ди ул.

Хуҗаның куркудан йөрәге табан астына төшеп китә.

– Шаһым-солтаным, сезгә ялганлап булмый, – ди ул, кызарып. Аннары үз-үзенә: – Бер сикердең, ике сикердең – котылдың, өченчесендә тотылдың, чикерткә! – ди.

Шаһ учын ачып җибәрсә, анда, чынлап та, чикерткә ята икән. Солтан, гаҗәпләнеп:

– Шулкадәр зирәклек булса да булыр икән кешедә, – ди һәм шул ук мизгелдә хуҗаны үзенең йолдызчысы итә, бик күп бүләкләр бирә.

Хуҗа хатынының да теләге тормышка аша.



# Звездочёт

Жили когда-то муж да жена. Муж был человек тихий, скромный, знал разные ремёсла, работал не покладая рук, и жили они так себе понемногу – ни шатко ни валко. Однако время и заботы посеребрили его волосы и бороду так, что он в свои сорок лет выглядел глубоким стариком. В один из дней жена его собралась в баню. Пришла туда, а там необыкновенная суетня. Что такое? Оказывается, сейчас сюда приедет мыться жена придворного звездочёта.

Хозяйка бани разгоняет моющихся женщин в разные стороны.

– Здесь нельзя, тут нельзя, – говорит она.

И вот под музыку и пение прибывает в баню жена придворного звездочёта с целой свитой женщин. Само собой понятно, что хозяйка бани, в надежде сорвать побольше денег, не знает куда только усадить её и оказывает ей разные почести.

Жена этого человека всем этим была крайне обижена. Тем не менее она, честь честью, помылась в бане, а затем пришла домой и вечером заявляет своему мужу:

– Вот что, муженёк, либо стань придворным звездочётом, либо меня оставь.

– Помилуй, жена, – отвечает он, – я ведь и писать-то не умею, куда же мне на должность придворного звездочёта. Были бы хлеб да соль.

А жена пристаёт:

– Нет, муж, как хочешь, только стань придворным звездочётом, иначе я не буду жить с тобой.

Однако женщина так красива, что бедняга не хочет от неё отказываться и начинает искать какой-нибудь выход. Он отправляется в кофейню, берёт чашку кофе и погружается в думы. В это время к нему подходит один из его друзей.

– О чём ты задумался? – спрашивает он, и тот рассказывает ему что и как.

А приятель этот как раз был дружком хозяйки бани.

– Ты не волнуйся, я что-нибудь придумаю, – утешает он его и сразу же отправляется к своей милой.

Когда он рассказал ей обо всём, она и говорит:

– Пусть тот человек придёт в такой-то день к бане, сядет напротив, разложит

перед собой кожу, на ней – бумагу, перо, чернильницу и другие вещи, а затем пусть начинает чертить и писать, будто он гадатель. Мы его дело устроим.

Как только она это сказала, приятель идёт и сообщает тому человеку. А бедняга не то что писать, и пера-то в руке держать не умеет. Да нечего делать, он поступает так, как велела хозяйка бани. Как бы то ни было, все, кто входит и выходит из бани, принимают его за учёного человека – подлинного ходжу.

В тот день опять приезжает в баню жена придворного звездочёта. А банщица, как раньше подучила хозяйка бани, во время мытья похищает у неё дорогой перстень. Хозяйка берёт перстень, зарывает его в мусоре в углу, а сама говорит об этом нашему гадателю.

Короче говоря, жена придворного звездочёта вскоре замечает, что у неё пропал перстень.

– Ах! – вскрикивает она.

Все находящиеся в бане волнуются, а хозяйка спокойно замечает:

– Ханым-эфенди, напротив двери в баню сидит ходжа. Пусть погадает, он очень хорошо раскрывает всякие тайны.

Не будем затягивать! Наш гадатель, поцарапав по бумаге, сообщает:

– Ханым-эфенди, перстень в углу, среди мусора.

Хозяйка делает вид, что ей ничего не известно, приказав служанкам искать перстень в мусоре. Ну, известное дело – перстень находится! Ходже дают дорогие подарки; он, радостный, идёт домой, но жена ничего не хочет, кроме должности звездочёта.

Прошло сколько-то дней после этого, и вдруг во дворце у султан-ханым пропадает перстень. А украла его одна из невольниц. Ищут его и там и сям – не находят.

А как раз в тот день приходит во дворец к султанше жена придворного звездочёта. Услыхав, что у султанши пропал перстень, она говорит:

– У меня тоже как-то раз пропал перстень, но один ходжа сразу же указал, где он. Это очень знающий человек, прикажите его привести. – И указывает, где его можно найти.

Султан тут же посылает весть хозяйке бани.

А наш бедняга так боялся своей жены, что все дни проводил у бани.

Вдруг приходят дворцовые люди и забирают его. Рассказ наш сократим, а то, пожалуй, в беду попадём! Султанша приказывает:

– Эй, ходжа, найди-ка мой перстень. Срок – до утра. Не разыщешь – голову с плеч долой!

И ходжу запирают в отдельную комнату.

Наступает ночь. Невольница, укравшая перстень, думает: «Вот теперь я пропала!» И сон не смыкает её глаз. «Будь что будет, пойду попрошу у ходжи помощи». Тихо-тихо входит она в комнату ходжи. А ходжа трясся от страха сильнее, чем не-

вольница. «О ужас, не наступило ли уже утро?» – думает он. А в это время невольница припадает к его ногам и рукам.

– Прости, о ходжа, перстень у меня. Если я попадусь, это будет мой последний день. Моя жизнь зависит от тебя, – просит и молит она его.

Ходжа думает про себя: «Аллах и сегодня послал мне удачу!», а ей говорит:

– Так-так, доченька, чего на свете не бывает! Ты не волнуйся, мы что-нибудь придумаем. – Потом, помедлив немного, добавляет: – Слушай, доченька, дай проглотить перстень гусю, да только так, чтобы никто не видел и не слышал, и надломи ему лапку. Иди, не бойся.

Девушка уходит и делает так, как он сказал.

Лишь только наступило утро, султан присылает за ходжой.

– О шах, всю ночь я гадал; бросал песок, и мне привиделись птицы. Прикажи выпустить в сад всех, сколько ни есть во дворе, кур, петухов, гусей, индюков и других птиц, – говорит ходжа.

Султан тотчас же приказал выпустить всех птиц в сад.

Итак, ходжа впереди, а падишах и множество людей сзади – выходят в сад; ходжа держит в руке перо и всё время чертит и пишет что-то на бумаге. Заметив хромого гуся, он говорит:

– О шах, вот этого гуся прикажите поймать и зарезать: у него в желудке перстень.

И вот гуся того хватают, режут, из желудка его выпадает перстень, и все замирают от удивления.

А потом султан, прогуливаясь по саду, поймал кузнечика.

– Ну-ка, ходжа, что у меня в руке? Узнай-ка! – спрашивает он, и у ходжи от испуга перехватило дыхание.

– О шах, вам лгать нельзя, – отвечает тот, покраснев и съёжившись, и, собираясь открыть свои проделки, шепчет: – Эх, кузнечик, раз прыгнешь, два прыгнешь – на третий попадёшься!

Султан разжимает руку, и там оказывается кузнечик. Все захлопали в ладоши, а ходжа сам себе удивился. «Когда Аллах помогает, так уж помогает!»

Султану всё это очень понравилось.

– И бывает же столько мудрости! – говорит он, тотчас делает ходжу своим придворным звездочётом, жалует разными подарками, а у жены его исполняется заветная мечта.

# Тегүче, аю, шайтан һәм Вирява

Яшәгән, ди, Шкамрав исемле тегүче. Тормышы авыр булган, начар тексә дә, әйбәт тексә дә, моны:

– Кулың коргыры, – дип сүгәләр икән.

Шкамрав: «Булмый болай. Яхшы эшләсәң дә, начар эшләсәң дә орышалар. Китим мин колагым әр ишетмәслек җиргә», – дигән дә авылдан чыгып киткән.

Бари икән бу, бара икән, кара урманга килеп җиткән. Аю очраган моңа. Аю:

– Шкамрав, кая киттең әле болай? – дип сорый, ди.

– Тормыштан туеп китеп барам. Начар тексәм дә, яхшы эшләсәм дә, әрдән башым чыкмый, «кулың коргыры» дигән сүздән артыгын ишеткәнем юк. Күзем күргән якка, колагым әр ишетмәс җир эзләп чыгып киттем.

Аю әйтә моңа:

– Минем тормыш та синекеннән әйбәт түгел. Мужиклар терлекләрен минем белән куркыта, хатыннар балаларын «еласаң, аю алып китәр» дип йоклата. Мине дә үзеңә иярт!

– Ярар, әйдә, бергә китик, – ди тегүче.

Икәүләп китәләр болар. Баралар икән, шайтанны очраталар.

– Кая барасыз? – дип сорый шайтан.

– Күзебез күргән якка, колагыбыз әр ишетмәс җир эзләп чыгып киттек, – дип, болар шайтанга үз хәлләрен сөйләп бирәләр.

– Минем хәлләр дә сезнекеннән әйбәтрәк түгел. Ирләр мине әйтеп сүгенә, хатыннар мине әрли, балалар бер-берсен мине кыстырып үртәшәләр. Ияртегез мине дә үзегез белән, – ди шайтан.

Тегүче, аю, шайтан бергә китәләр. Баралар, баралар, ди, урман эченә үк керәләр болар. Күрәләр: бер өй тора. Үзе буш. Болар шунда яши башлыйлар.

Көннәрдән бер көнне алар буза[1] кайнатырга булалар.

[1] *Буза* – эчемлек.

– Бузага колмак кирәк, колмак каян алабыз? – дип сорый тегүче.

– Колмакмы? – ди шайтан. – Әнә елга аръягындагы тегермән ишеге артында бер капчык колмак тора, хәзер алып киләм.

– Буза кайнатырга кисмәк тә юк...

– Кисмәкне мин алып киләм, – ди аю, – карт имән төбендә яздан хатыннар калдырган кисмәк каплап куелган.

Ярар, шайтан – колмак, аю кисмәк алып килгәннәр. Буза кайнатканнар, базга төшереп куйганнар. Берничә көннән соң тегүче базга төшеп караса, кисмәкнең бөкесе ачылган, бузаны кемдер эчеп караган, ди.

Тегүче кайткан да:

– Безнең бузаны кемдер урлаган бит, – дигән.

Уйлашканнар да базны чиратлашып сакларга булганнар. Беренче төнне аю киткән. Базга төшеп кисмәк артына яшеренгән дә көтә башлаган. Төн уртасы җиткәндә, тавыш купкан. Әллә чанада, әллә кыңгыраулы арбада килеп туктаган кебек тавыш, ди, бу. Ат та, арба да түгел, үз кисмәгенә утырган Вирява[1] килә икән. Кисәү агачы белән юлын ача, килесап белән кисмәген куа, себеркесе белән артыннан себереп бара, табагачы белән табасын кыйный, ди. Тавышы туй атларыннан бер дә ким түгел, ди.

Килеп туктаган да бу, комсызланып, кисмәктән буза эчәргә тотынган. Кисмәк артыннан килеп чыккан аю:

– Син, кортка, ник безнең бузаны урлыйсың? – дигән.

Виряваның исендә дә юк, туктарга уйлап та карамый. Аюга ачуы килгән моның, шалт берне килесап белән аюның маңгаена! Аю Вирявага сикергән икән, Вирява аңа тагын берне орган, себеркесе белән күзенә ком тутырган, кисәве белән тарткан, табасы белән тавыш чыгарган да китеп барган.

Аю өйләренә әйләнеп кайта, үзе ыңгыраша, ди.

– Кемне күрдең? – дип сорыйлар моннан.

– Күрмәдем, – ди аю.

– Ник ыңгырашасың соң?

– Баскычтан базга егылып төштем, көчкә исән калдым, – ди аю.

Икенче көнне шайтан китә. Барысы да алдагы төндәгечә була: Вирява, тагын да катырак ачуланып, кисәве белән шайтанның койрык очын өзә. Шайтан кайткач, тегүче белән аю сорыйлар моннан:

– Кемне күрдең?

– Кемне күрәсең анда?

– Ник койрыгың канлы?

– Ишеккә кыстым.

Өченче төнне бузаны сакларга Шкамрав китә. Үзе белән тимер аршынын, балалайкасын ала да кисмәк артына кача бу.

---

[1] *Вирява* – урман иясе.



Төн уртасында Вирява килеп җитә. Кисәве белән юл чистарта, килесап белән кисмәгән куа, себеркесе белән эзен югалта, табагач белән табасын кыйный. «Әһә, менә кем эчеп ята икән безнең бузаны!» – дип уйлый тегүче.

Вирява бөкене тартып ала да буза чөмерергә тотына. Тегүче балалайкада уйнап җырлый башлый:

Эч әйдә, эч әле,
Төбенә үк төш әле,
Кисмәк төбендә акча
Алганны көтеп ята.

Вирява шатланып тагын да күбрәк эчә – шартларлык хәлгә килә. Шкамравка шул гына кирәк тә. Килеп тә чыга, тимер аршыны белән Виряваны яра да башлый. Вирява бүре кебек улый, ябалак кебек өрә, ахырында ялына башлый:

– Шкамрав, җибәр генә, ни дисәң, шуны эшлим.

– Ни эшли беләсең соң син? – ди Шкамрав.

– Кызымны кияүгә бирәм! Бирнәгә яңа йорт салам, терлек тулы сарай, алтын-көмеш бирәм, – ди Вирява.

– Ялганласаң? – ди тегүче.

– Ышанмасаң, менә сиңа, кызыма бирнәгә дип саклаган тылсымлы яулык, битеңне шуның белән сыпырсаң, бөтен теләгең тормышка ашар. – Шулай ди дә Вирява очып китә.

Иртән Шкамрав өенә кайта. Моны шайтан белән аю йокламый көтә бит инде. Сораштыра башлыйлар.

– Виряваны күрдем, кызын миңа бирәм диде, бирнәсе дә шәп, – дип мактана бу, тылсымлы яулык турында да ычкындыра.

Аю белән шайтанның күзләре яна башлый.

– Без дә сугыштык бит Вирява белән, карап карарбыз, кем өйләнер икән Вирява кызына!

Уйлыйлар да болар, бер фикергә киләләр. Икәү өйдә кала, ә берәү урамга чыгып тегеләрне куркытырга тиеш була. Кем катырак куркыта – Вирява кызы шуңа.

Аю эченнән генә: «Мин аларны шундый итеп куркытырмын, монда юлны онытырлар», – дип сөенә. Шайтан да үз чиратында: «Вирява кызы миңа эләгәчәк икән», – дип шатланып тора.

Тегүче нишләсен, теләсә дә, теләмәсә дә ризалашырга туры килә.

Иң беренче булып аю китә, тегүче белән шайтан өйдә калалар. Аю куаклар артына кача да үкерергә тотына. Үкерә-үкерә дә агачларны тамырлары белән йолкырга керешә. Бөтен урман чытырдый башлый. Шайтан куркып калтырый, Шкамрав аңа:

– Аю гына бит ул, ник куркасың, – ди.

Ул арада аю өй янына килеп җитә дә, балаларны куркыткан шикелле:

– Аю килә, аю, өзеп атканчы качыгыз, – дип үкерә.

Шкамрав белән шайтан аңа:

– Күпме шауларга була инде, шуннан да куркып торырга без бала-чага түгел бит, – дип җавап бирәләр.

Куркытырга шайтан китә, тегүче белән аю өйдә калалар.

Шайтан биек агач башына менә дә боларның өйләре өстенә өрә башлый. Өрә-өрә шундый җил чыга ки, наратлар ыңгыраша, имәннәр селкенә, усаклар бии, өйнең түбәсе очып китәрлек булып калтырый башлый. Аю, куркып, Шкамравка әйтә:

– Давыл бигрәк котыра, өй җимерелгәнче качыйк, булмаса.

Тегүче көлә генә:

– Шайтан куркыта шулай итеп, курыкма, – ди.

Шайтан өй янына ук очып килә дә сабыйларны куркыткан кебек кычкыра:

– Карагыз-карагыз, шайтан оча!

Тегүче белән аю аңа:

– Җитәр инде, без бит сине беләбез!

Ярар, тегүче чираты җитә бит инде. Шкамрав төн уртасы җиткәнен генә көтә дә, табагач, таба ала, таягы белән таба кага-кага өйгә якынлаша. Аю белән шайтан уянып китсәләр, ишетәләр: әллә арбада, әллә чанада кемдер чаба, шалтырый, дөберди, кыңгыраулар чыңлата. Курка бит инде болар.

– Вирява түгелме бу? – ди аю.

– Шулай, ахры, – ди шайтан, үзе калтырый.

Тегүче тәрәзә янына килеп җитә, үзе табасына кага, таякларын бәрә, тавышын үзгәртеп:

– Чыгыгыз тизрәк, бу мин – Вирява, кисмәктә очам, килесабым – чыбыркы, табагачым – дуга, табам – кыңгырау! Кисәү белән юл ачам, себерке белән эземне себерәм, аю белән шайтанны көтәм, аюның сөякләрен саныйм, шайтанның койрыгын өзәм!

Аю белән шайтан өйдән очып та чыгалар, чабарга да тотыналар, аяк асларында кайрылар гына шартлап кала. Артларына борылып карарга да куркалар хәтта.

Үзе генә калгач, Шкамрав тылсымлы яулыкны битенә каплый. Яулыкны алуы була, алдында өр-яңа өй пәйда була. Күрә: тәрәзә төбендә бер кашык су белән йотарлык чибәр кыз чигү чигеп утыра – Вирява кызы. Өстәлдә алтын-көмеш өелеп ята. Өй тирәли яңа койма тотылган, ишегалды тулы терлек-туар.

Шулай итеп, Шкамрав белән Вирява кызы туй итәләр, әле хәзер дә бик бәхетле яшиләр, ди.



# Портной, медведь, чёрт и Вирява

В одном селе жил портной Шкамрав. Шил он плохо, и постоянно все его бранили. Не раз ему говорили:

– У-у! Чтоб у тебя руки отсохли, как ты плохо шьёшь!

Даже когда Шкамраву и удавалось что-нибудь хорошо сшить, его тоже бранили. Другие портные завидовали ему и говорили:

– У-у! Как ты хорошо сшил, чтоб у тебя руки отсохли!

И думает Шкамрав про себя: «Трудно здесь жить. Плохо сошью – ругают, хорошо – тоже ругают. Уйду куда глаза глядят, где уши худого не слышат».

Ушёл Шкамрав из села. Шёл, шёл и пришёл в большой дремучий лес. Вот идёт он по лесу и встречает медведя. Медведь спрашивает портного:

– Ты куда это, Шкамрав, милый мой, собрался?

– Иду куда глаза глядят, где уши худого не слышат.

– Что так?

– Житьё моё никуда не годится: плохо сошью – ругают, хорошо сошью – тоже ругают, говорят: «Чтоб твои руки отсохли, как хорошо сшил!» Вот я и надумал уйти отсюда.

Медведь говорит портному:

– Моё житьё тоже неважное: мужики мною скотину пугают; как рассердятся, говорят: «У! Медведь тебя задери!» Бабы мной ребятишек стращают, говорят: «Смотри, не плачь, а то медведь тебя съест». Пойду и я с тобой туда, куда глаза глядят, где уши худого не слышат.

– Что ж, – говорит портной, – пойдём. Пошли они дальше вдвоём. Идёт навстречу им чёрт и спрашивает:

– Вы куда это собрались?

– Идём, – говорят, – туда, куда глаза глядят, где уши худого не слышат.

– Что так?

– Да так и так, житьё наше плохое! – И рассказали чёрту про свои обиды. Чёрт говорит им:

– И моя жизнь не лучше вашей: мужики ругаются – меня поминают, бабы доброго слова обо мне не молвят, ребятишки мной тоже друг друга пугают. Возьмите и меня с собой.

– Что ж, пойдём.

Пошли. Шли они, шли, зашли в самую глубь леса. Стоит в лесной чаще избушка. Вошли они, видят – никто в ней не живёт. Поселились они в этой избушке.

И вот как-то надумали они позу[1] варить.

– Чтобы позу варить, солод нужен. Где же мы солоду возьмём? – удивился портной.

– Солоду нет? – отвечает чёрт. – Это не беда. Сейчас добуду. На реке стоит мельница, помольцев сейчас нет никого, а за дверью мешок с солодом стоит, слетаю сейчас – принесу!

– Да и корчаги у нас нет, где солод заваривать!

– А корчагу я принесу, – говорит медведь. – Неподалёку в лесу стоит старый дуб, под дубом весной бабы брагу варят. Там и теперь опрокинутая корчага стоит.

Слетал чёрт за солодом, медведь корчагу приволок. Стали позу варить.

Попробовал портной да и говорит:

– Надо бы медку для крепости подбавить! – Медведь говорит:

– Ну, это уж по моей части. Неподалёку здесь пчельник, пойду принесу мёду.

Принёс медведь мёду, нашли хмельку в соседних кустах, и поза вышла на славу. Убрали её приятели в погреб.

Пошёл через денёк портной в погреб за позой, смотрит – затычка у бочки вынута, кто-то уже пробовал позу.

Пришёл портной в избушку и говорит:

– Братцы, а ведь позу нашу кто-то ворует!

– Кто же бы это мог быть?

– Придётся нам покараулить.

Сговорились они по очереди караулить свой погреб. На первую ночь пошёл медведь. Залез медведь с вечера в погреб, спрятался за бочку и ждёт, что будет.

Около полуночи вдруг послышался шум. Медведю показалось, что кто-то подъехал не то на телеге, не то на санях с колокольчиками.

Притаился медведь за бочонком, чуть дышит. А это подъехала Вирява[2] в ступе. Пест у ней – кнут, ухват – дуга, сковородка – колокольчик. Едет – кочергой путь расчищает, пестом ступу погоняет, помелом след заметает, сковородником в сковороду бьёт. И такой шум-звон от неё, словно свадебный поезд идёт.

Подъехала Вирява к погребу, бросилась скорее к бочке позу пить, пьёт-захлёбывается. Медведь выскочил из-за бочки да как рявкнет:

---

[1] *Поза* – мордовский национальный напиток.
[2] *Вирява* – лесная ведьма.

– Ты что, старая, нашу позу воруешь? – А Вирява уж во вкус вошла, не может оторваться от позы. Рассердилась она на медведя, что помешал он ей, да как хватит его пестом по лбу! Медведь хотел было кинуться на Виряву, да куда там! Она его пестом оглушила, помелом глаза засорила, кочергой под себя загребла да ещё сковородкой звон подняла.

А сама напилась позы и уехала. Приходит медведь в избушку и стонет.

– Кого видел? – спрашивают его портной с чёртом.

– Никого я не видел! – бурчит тот.

– Что ж ты стонешь?

– С лестницы в погреб сорвался, насилу жив остался!

Ладно. На следующую ночь пошёл чёрт сторожить.

И повторилось всё, что было с медведем. Вирява рассердилась ещё пуще – не только побила чёрта, ещё кончик хвоста ему кочергой отшибла.

Наутро пришёл чёрт домой сердитый да ворчливый. Спрашивают его портной с медведем:

– Кого видел?

– Кого там увидишь! – проворчал он в ответ, а сам хвост зализывает.

– Что это у тебя хвост в крови?

– Дверью нечаянно прищемил.

На третью ночь собрался караулить позу Шкамрав.

Взял он с собой балалайку, аршин свой железный и спрятался.

В самую полночь едет-шумит Вирява: кочергой путь расчищает, пестом ступу погоняет, помелом след заметает, сковородником в сковороду бьёт: «Эге, вот кто нашу позу пьёт!» – думает портной. Притаился, стал смотреть, что будет.

А Вирява вынула затычку, припала к позе и пьёт. Тут портной ударил по струнам, заиграл на балалайке и запел:

Пей-ка, попей-ка,
На дне-то копейка!
Если с донышка попьёшь –
Злата, серебра найдёшь!

Обрадовалась Вирява. Пьёт она, пьёт, от жадности надувается – до самого дна добирается. Этого-то Шкамрав и дожидался. Снял он с себя красный кушак, скрутил Виряве руки и давай её железным аршином бить. Уж он бил её, бил, стегал-стегал – мечется Вирява, волком воет, филином кричит и взмолилась, наконец:

– Шкамрав, миленький, отпусти ты меня! Я для тебя всё, что захочешь, сделаю.

– Ага, – говорит портной, – давно бы так! Ну-ка, что ты можешь для меня сделать?

– Я за тебя дочку свою выдам, красавицу! В приданое избу новую поставлю, скотины полон двор дам, отсыплю семь мер серебра, семь мер золота!

– А не обманешь, старая? – спрашивает портной.

– Если не веришь, то на вот платочек мой волшебный, который я дочке в приданое берегу: как только накроешь им лицо себе и утрёшься – станешь сам молодцом и все твои желания сбудутся.

– Ну, ладно, – согласился портной и развязал Виряве руки.

Приходит под утро Шкамрав в избушку свою, видит – чёрт с медведем не спят, его поджидают.

– Ну, кого ты там видел? – спрашивают.

– Видел, – говорит, – Виряву.

– Чем она тебя наградила?

– Да чем? Дочь свою, красавицу, за меня просватала! В приданое даёт новую избу, скотины полный двор, семь мер серебра и семь мер золота.

Чёрт с медведем ушам своим не верят, а Шкамрав продолжает:

– Вот и платочек дала свой волшебный: как только накрою им лицо да утрусь – все мои желания сбудутся.

Тут уж чёрт с медведем признались:

– Мы ведь тоже с Вирявой дрались! Посмотрим ещё, кому придётся жениться-то. Это мы ещё поспорим!

– Как же мы спорить будем? – спрашивает портной.

– Давайте так спорить, – говорит медведь. – Двое будут по очереди дома оставаться, а третий нас пугать станет. Кто сильнее всех сумеет напугать других, тот и женится на дочке Вирявы, тому и платочек волшебный достанется!

Говорит так медведь, а сам думает: «Я их так испугаю, что убегут они и дорогу сюда позабудут». А чёрт тоже доволен. Думает он: «Ну, пусть себе только останутся, я на них такого страха нагоню, что век не забудут».

Нечего делать портному – хочешь не хочешь, надо соглашаться.

Первым пошёл медведь пугать, а портной и чёрт дома остались.

Вот зашёл медведь за кусты и давай реветь. Ревел-ревел, затем принялся деревца молодые с корнем вырывать. Треск по всему лесу пошёл. Чёрт струсил и хотел бежать, а Шкамрав говорит:

– Не бойся, это медведь.

А медведь подошёл к самой избушке да как заревёт, словно ребят пугает:

– Вот медведь идёт, медведь! Задерёт вас медведь, бегите!

Шкамрав с чёртом кричат ему из избы:

– Ну, довольно тебе кричать да шуметь, ведь мы не ребятишки!

Так медведю и не удалось их испугать. Пошёл чёрт пугать, а портной с медведем дома остались.

Залез чёрт на высокое дерево и давай оттуда дуть на избушку. Такой поднялся ветер, что сосны застонали, дубы затрещали, осины заплясали, а на избушке вот-вот крыша обвалится и окна вон вылетят.

Струсил медведь, говорит он портному:

– Надо нам бежать, а то, чего доброго, буря опрокинет избушку и нас задавит. – А портной только смеётся.

– Это, – говорит, – чёрт нас так пугает, не бойся!

Видит чёрт – не боятся портной и медведь бури, подлетел к самому оконцу, да как крикнет не своим голосом, точно бабы на ребятишек:

– Смотрите, смотрите: чёрт, чёрт летит!

А портной с медведем кричат ему из избушки:

– Ну, довольно тебе! Всё равно не боимся – знаем, кто ты такой!

Вернулся чёрт к товарищам – никого не испугал.

Пришла очередь портному пугать медведя да чёрта. Дождался он ночи, взял с собой сковородник, сковороду, сделал из двух палок колотушку и тихонько вышел.

В полночь слышат чёрт с медведем: кто-то к избушке подъехал – не то на санях, не то на телеге, стучит, гремит и в колокольчик звенит. Испугались они. Медведь шепчет чёрту:

– Кто это? Уж не Вирява ли?

– Должно быть, она! – говорит чёрт, а сам трясётся.

А портной подошёл к оконцу, да как брякнет изо всех сил в колотушку, да как звякнет в сковороду, как крикнет не своим голосом:

– Выходите, выходите скорей! Это я, Вирява, в ступе еду! Пест у меня – кнут, ухват – дуга, сковорода – колокольчик! Кочергой путь расчищаю, помелом след заметаю, медведя с чёртом поджидаю, хочу медведю кости помять, чёрту хвост оторвать!

Испугались медведь с чёртом не на шутку. Выскочили они из избы и бросились бежать, только хворост под ними трещит. Бегут, бегут – назад не оглядываются. Так и убежали.

Остался Шкамрав один, накинул себе на лицо платочек волшебный, утёрся, и встала перед ним новая изба. В избе под окошечком сидит красавица – дочка Вирявы и вышивает. На лавке стоят семь мер серебра, семь мер золота. Кругом дома двор новый огорожен. Полон двор скотины.

Поженились Шкамрав с Вирявиной дочкой и стали жить да поживать и добра наживать.



# Ипи-тоз бәһасе

Яшәгән, ди, бер ярлы кеше. Аның бер улы булган.

Көннәрдән бер көнне ул үзенең улына:

– Минем фәлән җирдәге дустыма барып кайтсаңчы. Аның миңа бурычы бар иде, дөньяныкын дөньялыкта бетерергә кирәк, шул бурычны алып кайт. Юлың ерак, бервакытта да үзең генә утырып ашама, ипи-тозыңны бүлешергә иптәш тап.

Ярар, егет чыгып киткән. Озак баргандырмы, юкмы, бу бер чишмә буена килеп җиткән. Чишмә янында яп-ябык бер карт утыра икән. Егет биштәрендәге әйберләрен чыгарып тезгән дә картка:

– Әй, бабай, минем ипи-тозымны бүлешсәңче. Аштан беребез дә өстен түгел.

Карт, егет белән тәгам җыеп, аңа рәхмәт әйтеп, урыныннан кузгалган. Калган юлны бергә узганнар. Басу капкасына җиткәндә, карт юкка чыккан. Егет, як-ягына әйләнеп караса, беркемне дә күрмәгән. Әтисенең дустына ул үзе генә киткән.

Егетне ачык йөз белән каршы алганнар, бик әйбәтләп кунак киткәннәр. Әтисенә тиешлесен алгач, егет кайтыр юлга кузгалган. Караса, басу капкасы янында теге карт басып тора икән.

– Бабай, син кичә кинәт кенә кайда юкка чыктың? – дип сорый икән егет. – Мин барган җирдә икебезгә дә урын җитәр иде.

– Син хаклы, егет, мин дә аларда булдым.

– Нишләп мин сине анда күрмәдем соң? – дип гаҗәпләнгән егет.

– Мин кеше түгел, – дип җавап биргән карт. – Мин – Әҗәл. Мин әлеге йортка хуҗаны алып китәргә дип килдем. Мин аны иртәрәк тә алып киткән булыр идем, аның «Бурычымны түләгәнче җанымны ала күрмә, зинһар» дип Аллага ялваруларына күрә тими тордым.

Егет моны ишетеп бик хәсрәтләнгән. Вакыты җиткән булгач, ул нишли алсын инде?

Ял итеп, ашап алыр вакыт җиткән. Егет белән карт хәзинәдә булганыннан авыз иткәннәр. Егет карттан:

– Минем җанымны алырга кайчан киләчәксең? – дип сорый икән.



– Егет, сиңа бу сорауны бирмәсәң яхшырак булыр, үләсе көнеңне белеп торганда, башка нәрсә турында уйлый да алмассың.

– Очрашканбыз икән, әйт инде, кайчан киләчәксең?

– Син өйләнеп, кәләшең янына кергән көнне.

Вакытлар узган. Егет, картның әйткәнен исендә тотып, бик озак вакытлар өйләнмичә йөргән. Ахырында, туганнарының туктаусыз кыставына түзә алмыйча, Әҗәл сүзенә кул селтәп, өйләнергә булган.

Менә туй көне килеп җиткән. Туйлар узып, кияү белән кәләш икесе генә калгач, теге ябык карт килеп кергән.

– Йә, егет, мин үземә тиешлесен алырга килдем.

– Әтием белән сөйләшеп алырга гына рөхсәт итче, – ди егет.

Карт риза булган. Егет, әтисе янына кереп, башыннан узганнарны сөйләп биргән. Әтисе әйткән:

– Күрәм, син минем әйткәннәремне үтәмәгәнсең икән...

– Юк, әти, барысын да син әйткәнчә эшләдем, үзем генә тәгам җыярга утырмадым. Ә бу карт миңа ике тапкыр очрады, икесендә дә ипи-тозымны аның белән бүлештем.

– Алай булгач, сора, ипи-тозны ничек бәһаләр микән ул?

Егет әйләнеп кергән дә Әҗәлгә шушы сорауны биргән.

Карт үзе җавап бирә алмагач, үлеләр иленә, Барастыр[1] белән киңәшергә кайтып киткән.

Әҗәл белән Барастыр җиде көн, җиде төн уйлашканнар да, кәләше белән озын бәхетле гомер кичерсен өчен, егеткә тимәскә булганнар.



[1] *Барастыр* – осетин мифологиясендә үлеләр дөньясы патшасы.

# Цена хлеба-соли

Жил бедняк со своим сыном. Однажды он позвал сына и говорит ему:

– Сходи к моему другу, пока я жив, и скажи ему, чтобы он вернул мне долг, и долг тот принеси с собой. Дорога у тебя дальняя, потому смотри, по дороге ли, в доме ли, но без товарища нигде не ешь хлеба-соли.

Приготовил бедняк своему сыну на дорогу поесть, и тот ушёл. Кто знает, сколько шёл, но добрался он до родника.

У самого родника старик худой-прехудой сидит. Сын бедняка тоже остановился у родника поесть, достал из сумки всё, что у него было, и говорит старику:

– Не побрезгай моим хлебом-солью. Солёная еда для нас всех одинакова.

Старик поблагодарил сына бедняка и поел с ним, потом вместе пошли дальше. Кто знает, сколько они шли, но к вечеру добрались до того селения, куда шёл сын бедняка. У самой околицы худой старик вдруг исчез. Сын бедняка удивился, но что ему оставалось делать? И отправился он один к отцовскому другу.

С радостью встретил его хозяин дома, хорошо угостил, вернул долг, а хозяйка приготовила юноше на дорогу вкусную еду. На другой день сын бедняка пошёл обратно. Недалеко от селения опять повстречался с этим худым стариком.

– Добрый дедушка, почему ты вчера исчез, не пошёл со мной в селение? В доме, где я был, хорошо приняли бы и тебя.

– Ты прав, юноша, но я тоже был у них в гостях.

– Как же я не видел тебя? – удивился юноша.

– Я не человек, – ответил худой старик. – Я – Смерть, и пошёл к хозяину того дома, чтобы взять его жизнь. Я бы давно взял, но он всё молился Богу: «Не лишай меня жизни, пока я должник», – вот потому-то я до сих пор и не трогал его.

Юноша очень опечалился смертью отцовского друга, но что он мог поделать?

Пришло время для еды. Сын бедняка достал, что у него было, поел и попил со стариком, а потом спрашивает его:

– А когда ты придёшь за моей жизнью?

– Было бы лучше, юноша, если бы ты не спрашивал меня: нехорошо знать день своей смерти, всё время будешь думать о нём.

– Раз мы встретились, то скажи: когда придёшь за моей жизнью?

– В тот день, когда женишься и войдёшь к своей невесте.

Настало время жениться сыну бедняка. Все родственники говорили ему, чтобы он женился, но юноша отказывался. Когда же ему надоели постоянные упрёки, то он решил уступить и женился. Как только невесту ввели в дом и молодые остались одни, появился старик и напоминает сыну бедняка:

– Ну, приятель, я пришёл за своим.

– Позволь мне ещё с отцом поговорить, – просит сын бедняка.

Старик согласился, юноша пошёл к отцу и рассказал всё, что было.

Бедняк говорит своему сыну:

– Я вижу, что ты не выполнил моего наказа.

– Нет, отец, всё, что ты говорил, выполнено: никогда я один не садился за еду. А с тем стариком встретился дважды и каждый раз угощал своим хлебом-солью.

– Тогда иди и спроси его, во что ценит он хлеб-соль?

Юноша вернулся в комнату и спросил, как велел отец.

Старик не мог ответить и вернулся в страну мёртвых – спросить Барастыра[1], как быть. Семь дней и семь ночей судили-рядили Смерть с Барастыром, а потом порешили наделить юношу и его жену счастьем и долгой жизнью.



[1] *Барастыр* – владыка загробного мира в осетинской мифологии.

# Үлмәс Кощей

Борын-борын заманда бер патша яшәгән, ди. Моның үсеп буйга җиткән өч улы булган. Матур гына көн итеп ятканда, боларның әниләрен Үлмәс Кощей урлап киткән.

Өлкән угыл әтисеннән әнисен эзләргә рөхсәт итүен сораган. Патша бу эшкә хәер-фатиха биргән. Әмма егет әнисен эзләргә киткән җиреннән кире әйләнеп кайтмаган.

Уртанчы угыл да, көтеп-көтеп тә абыйсы кайтмагач, әтисенең ризалыгын алып, әнисен эзләргә киткән. Шул китүеннән ул хәбәрсез югалган. Билгеле бер вакыттан соң патша янына кече улы Иван килгән.

– Атакаем, әниемне эзләргә рөхсәт бир миңа, – дигән ул.

– Олы абыең белән уртанчы абыең да әйләнеп кайтмадылар. Инде кече улымны да югалтсам... мин моны күтәрә алмаячакмын, сагыштан үләрмен. Җибәрмим, беркая да бармыйсың, – дип җавап биргән патша.

Ә кече малайның үз туксаны туксан, ди.

– Рөхсәт бирсәң дә барам, бирмәсәң дә барам, – дип үҗәтләнгән ул.

Патша ризалашырга мәҗбүр булган.

Иван, күңеленә хуш килердәй ат сайларга дип, абзарга чыгып киткән. Әмма ышанычлы, үзе теләгән атны таба алмаган. Инде нишләргә, кая барырга, кемнән ярдәм сорарга? Егет шундый уйлар белән шәһәр буйлап атлаган. Шулвакыт моның каршында бер карчык пәйда булган һәм:

– Саумы, патша улы Иван! Ник борыныңны салындырдың? – дип сораган.

– Кит моннан, җен карчыгы! Колеңне күккә очырам бит хәзер, – дип җавап биргән Иван.

Карчык бер тыкрыкка кереп киткән, аннан янә егет каршына килеп баскан һәм әйткән:

– Исәнме, патша улы Иван! Нәрсә борыныңны салындырдың?

Иван: «Бу нинди карчык соң? Бәлки, аның миңа ярдәме тияр», – дип уйлаган һәм болай дигән:

– Әй әби, юлда үземә ярдәмчем булырдай атны таба алмыйм.



– Әй тилекәй, каян эзләргә кирәклеген үзең дә белмисең, миннән дә сорамыйсың. Атла минем арттан. – Карчык аны таулы урынга алып килгән һәм бер урынга төртеп күрсәтеп болай дигән: – Казы менә бу урынны!

Иван карчык күрсәткән урынны казый башлаган икән, көрәге чуен ишеккә тиеп киткән. Игътибар беләнрәк караса, ишек унике йозакка бикләнгән, ди. Иван, йозакларны ватып, ишекне ачкан, һәм алар әби белән икәүләп җир астына төшеп киткәннәр. Монда егет унике кат чылбыр белән богауланган бер пәһлеван ат күргән. Ат, күрәсең, аяк тавышларын ишеткән булгандыр, Иванны күрүгә кешнәп җибәргән, тибенә башлаган һәм чылбырларын өзгән.

Патша улы Иван хәрби киемнәр кигән, яхшы итеп коралланган, атка йөгән белән ияр кидергән. Карчыкка күп итеп акча биргән. Аннан:

– Сау бул, әби! Миңа фатихаңны бир, – дип, атына атланган.

Шулай итеп, Иван үз юлына, карчык үз юлына китеп барганнар. Иван бик озак барган. Ниһаять, бер тау итәгенә барып җиткән. Менеп җитә алмастай биек һәм текә тау булган бу. Караса, тау кырыенда абыйлары әрле-бирле йөри, ди. Болар исәнләшкәннәр, бер-берләренең хәлләрен сорашканнар да юлларын бергәләп дәвам иткәннәр. Берзаман егетләр чуен таш янына килеп җиткәннәр. Таш бик авыр, йөз илле пот, ди. Ташка «Кем дә кем бу ташны тау башына ыргыта, шул кешегә тауга юл ачыла» дип язылган икән. Абыйлары күтәреп караган – ташны селкетә дә алмаганнар. Чират Иванга җиткән. Ул ташны мизгел эчендә күтәреп алган да тау башына атып бәргән. Күз ачып йомган арада, тау итәгеннән тау башына баскыч сузылган. Шуннан Иван атын бер читкә илтеп бәйләп куйган да абыйлары янына килгән. Чәнти бармагын тишеп, аннан бер стаканга кан агызып алып, аны абыйларына биргән һәм болай дигән:

– Мине стакандагы кан кара төскә кергәнче көтегез. Әгәр ул вакытта да кайтмасам, үлгән булырмын.

Шулай итеп, ул баскыч буйлап тау башына менеп киткән. Андагы ямь-яшел урманнарга, кошлар сайравына, аланнарында кызарып пешкән җиләкләрнең күплегенә исе китеп, озак йөргән Иван. Менә ул бик зур бер йорт янына килеп чыккан. Монда Үлмәс Кощей урлап алып кайткан патша кызы яши икән. Йорт биек койма белән әйләндереп алынган. Иван, койма тирәсендә күпме генә йөрсә дә, керергә ишек таба алмаган. Шунда аны тәрәзәдән патша кызы күреп алган һәм:

– Әй, егет, коймада бер ярык бар. Чәнти бармагың белән шул ярыктагы төймәгә бас. Ишек ачылыр, – дип кычкырган.

Егет, кыз ничек кушса, шулай эшләгән. Йортка килеп кергән бу. Кыз аны бик яхшы каршы алган: ашаткан-эчерткән, нишләп йөрүе турында сорашкан. Иван әнисен эзләп килүе турында сөйләп биргән. Шунда кыз көрсенеп куйган һәм әйткән:

– Мин сине аңлыйм. Шулай да бик авыр эшкә алынгансың. Кощей үтерәчәк сине. Ул бик көчле һәм үлемсез. Кощей минем яныма бик еш килә... Аның кылычы гына да биш йөз пот. Күтәрә алырсыңмы икән син аны?

Патша улы Иван кылычны күтәреп кенә калмаган, югарыга чөеп тә җибәргән.

Егет белән кыз бер-берләрен бик ошатканнар, өйләнешергә вәгъдә бирешкәннәр. Аннан егет, кызны калдырып торып, юлын янә дәвам иткән. Бара-бара, ул икенче бер йорт янына килеп чыккан. Бу йорт та нәкъ тегесе кебек биек койма белән әйләндереп алынган, ди. Хәзер инде ул ишекне ничек ачарга кирәклеген белә. Чәнти бармагы белән ярыктагы төймәгә басуы булган, ишек ачылып та киткән. Йорт эченә килеп керсә, каршында әнисе басып тора, ди. Алар кочаклашып күрешкәннәр, елашканнар. Бик сагынышкан булганнар бит инде. Бераздан әнисе аңа көчен сынап карарга кушкан. Егет бу сынауны да үткән – мең ярым пот авырлыктагы шарны эһ тә итмичә һавага чөйгән. Сәгатькә карасалар, Үлмәс Кощейның кайтыр вакыты җиткән икән. Әнисе малаен чак яшереп өлгергән, Кощей кайтып кергән һәм болай дип сораган:

– Фу-у! Кеше исе килә. Синең янда кемдер бармы әллә?

– Кит аннан, Алла сакласын. Үзең бит яңа гына кеше аулап кайттың, шуңа борыныңнан кеше исе китмәгәндер, – дигән Иванның әнисе, ә үзе, ягымлы сүзләр әйтә-әйтә, Кощейга сырпаланган. – Синең үлемең кайда яшерелгән икән, Кощей, әйтсәнә?

– Минем үлемем моннан бик еракта, диңгез аръягында яшерелгән. Ул урында имән үсеп утыра. Имән төбендә әрҗә тора, әрҗәдә куян утыра, куян эчендә – үрдәк, үрдәк эчендә – йомырка. Минем үлемем менә шул йомырка сарысында.

Кощей шулай дигән дә китеп барган. Бу сүзләрне ишетеп торган Иван, әнисенең ризалыгын алып, шунда ук теге имән янына юл тоткан. Йокламый, ашамый, эчми бара икән, бара икән бу, моның каршына Бүре баласы килеп чыккан. Иван кылычына ябышкан. Шулчак ана Бүре пәйда булган.

– Тимә балама. Әгәр миңа яхшылык эшләсәң, барыр юлыңда ярдәмчең булырмын, – дигән ул.

– Ярый, – дигән Иван һәм юлын дәвам иткән, Бүрегә тимәгән. Бара-бара бик озын юл үтеп, агач башында каркылдап утырган Карганы күргән бу. Ашыйсы да килгән бит инде моның. «Менә бит тәмле ризык», – дип уйлаган Иван һәм мылтыгын кулына алган. Шунда Карга телгә килгән һәм әйткән:

– Атма мине, Иван, мин әле сиңа кирәк булырмын.

Патша улы Иван Каргага да тимәгән, юлын дәвам иткән. Берзаман ул диңгез буена килеп җиткән. Су өстендә балыклар сикерешеп уйный, ди. Иван, ризык таптым дип, шатлыгыннан нишләргә белмәгән. Бер балыкны шунда ук эләктереп алган. Әмма сөенече озакка бармаган, судан ана Чуртан башын чыгарган.

– Җибәр минем баламны, авыр хәлдә калганда, мин сиңа ярдәм итәрмен, – дигән ул.

Иван балыкны да җибәргән.

Егет аптырап калган, имән янына бару өчен диңгезне кичәргә кирәк икән. Шунда теге Чуртан диңгезгә аркылы яткан. Иван Чуртанның сүзләрен исенә төшергән: «Авыр хәлгә калганда, мин сиңа ярдәм итәрмен». Ул эшнең нәрсәдә икәнен аңлап

алган да «күпер» өстеннән диңгезнең аргы ягына чыккан. Имән, имән төбендәге әрҗә дә бик тиз табылган. Тик барысы да син уйлаганча гына бармый шул. Әрҗәне ачып җибәрүе булган, аннан куян сикереп чыккан да күз ачып йомган арада юкка да чыккан. Шунда аңа ана Бүре ярдәмгә килгән. Мизгел эчендә куянны тотып китергән. Инде булды гына дигәндә, куян эчендәге үрдәк очып чыгып киткән. Иван да аптырап калмаган, үрдәккә төбәп атып җибәргән. Ләкин күпме генә тырышса да тидерә алмаган. Шулай аптырап утырганда, аңа Карга дусты ярдәмгә килгән. Ул томшыгы белән үрдәкне эләктереп алган да Иванга китереп биргән. Хәзер инде йомырканы гына кулга төшерәсе калган. «Монысы инде бик җиңел эш», – дип уйлаган егет. Йомырканы тиз генә эләктергән дә диңгезгә киткән. Тик иртәрәк шатланган шул. Юыйм дип суга тыгуы булган, йомырка су төбенә төшкән дә киткән. Инде нишләргә? Йомырканы ничек алырга? Иван алай уйлаган, болай уйлаган, бер фикергә килә алмаган. Кинәт, диңгез дулкыннарына күмелә-күмелә, яр кырыена Чуртан килеп чыккан. Йомырканы Иванга тапшырган да диңгезгә аркылы яткан. Иван, янә шул «күпер» аша диңгезне кичеп, әнисе янына әйләнеп кайткан. Өйгә килеп керсә, әнисе, дер калтырап, Кощейның кайтуын көтеп утыра, ди. Малаен ничек кирәк алай яшерергә өлгергән бу. Ул арада Кощей да кайтып кергән һәм:

– Фу-у! Кеше исе килә! Монда кеше бармы әллә? – дип иснәнә башлаган.

– Юк, Үлмәсем. Бер кеше дә юк, – дигән Иванның әнисе.

– Минем нигәдер кәефем юк, – дигән Кощей һәм киерелеп иснәп куйган.

Шулчак качкан җиреннән патша улы Иван килеп чыккан. Учында күкәй, ди, моның.

– Кәефең булмауның сәбәбе – үлемең якынлашуда. Синең үлемең минем кулда! – дигән ул.

Үлмәс Кощей шунда ук эшнең нәрсәдә икәнен аңлап алган һәм патша улы Иванның аягына баш орган:

– Вата күрмә күкәйне, Иван. Мин гомер буе синең дустың булырмын.

Иван аның сүзен тыңлап та тормаган, күкәйне шунда ук җиргә бәргән. Үлмәс Кощей мизгел эчендә җан тәслим кылган.

Малай белән ана шунда ук кайтыр юлга чыкканнар. Юл уңаеннан, Иванның көләшен дә үзләре белән алганнар. Менә алар тау башына килеп җиткәннәр. Шунда патша кызы Иванга Үлмәс Кощей йортында туй күлмәгенең, бриллиант кашлы йөзек һәм тегелеп бетмәгән башмагының онытылып калганлыгы турында әйткән. Иван тау астында үзен көтеп калган абыйларына кычкырган да әнисе белән кызны бау белән тау астына төшереп җибәргән. Үзе, аз гына көтәргә кушып, Үлмәс Кощей йортына юнәлгән. Әйләнеп килсә, абыйларыннан җилләр искән, таудан төшә торган бау киселгән, ди. Ә абыйлары бу вакытта әниләре белән кызны, Иван турында әтигә берни әйтмәгез, югыйсә үтерәбез дип куркытып, патша йортына алып кайтып киткәннәр. Хатыны белән малайларының исән-сау кайтуларына патша сөенеп бетә алмаган. Тик кече улы Иван гына исеннән чыкмый икән.

Инде Иванга килик. Ул аптырап йөргән-йөргән дә бер таш өстенә килеп утырган. Нишләргә белмәгәннән никах балдагын бер кулыннан икенче кулына күчереп йөртә башлаган. Шулай эшләве булган, аның каршына унике яшь егет килеп баскан.

– Ни боерасың? – дигәннәр алар егеткә.

– Мине бу таудан төшерегез!

Егетләр кушылган эшне шунда ук җиренә җиткереп үтәгәннәр. Иван балдакны бармагына киюгә, егетләр янә юкка чыкканнар, ә егет шат күңел белән үзләре яшәгән шәһәргә юнәлгән. Ләкин туры өенә кайтмаган, бер әбидә тукталган. Әби сөйләшергә ярата торган кеше икән, егеткә шәһәрдәге барлык яңалыкларны сөйләгән. Патша хатынын Үлмәс Кощей урлавы, ике малаеның аналарын коткарулары, үзләре белән икенче бер патшаның кызын ияртеп алып кайтулары, кече малайлары Иванның анасын эзләргә киткән җиреннән юкка чыгуы, патшаның моңа бик борчылуы, олы малайларының ияртеп алып кайткан кызга өйләнергә теләве, ләкин патша кызының риза булмавы, ниндидер балдак таптыруы яисә нәкъ шундый балдак ясый алган кешегә генә кияүгә чыгачагы турында бәян иткән. Иван, боларны ишетү белән:

– Әби, патша йортына хәзер үк бар да әйт, балдакны үзем ясап китерәм, диген. Бер дә курыкма, мин сиңа аны үзем ясап бирермен, – дигән.

Әби курка-курка гына патша йортына киткән. Килеп кергән дә:

– Патша галиҗәнаплары! Кыз сораган балдакны мин ясыйм, – дигән.

– Яса, әби, яса. Ясый алсаң, бик шат булырбыз. Ә инде булдыра алмасаң, мин синең башыңны кистерермен, – дигән патша.

Бу сүзләрдән әбинең коты алынган, балдакны ясый белми бит инде бу. Елыйелый кайтып кергән өенә. Булган хәлләр турында Иванга сөйләп биргән. Егетнең исе дә китмәгән, берни булмагандай йокларга яткан. Әби ачыргалана-ачыргалана елаган. Син генә мине үлемгә дучар иттең, дип елый-елый, үзе дә йокыга киткән.

Таң аткан. Иван әбине уяткан да кулына балдак тоттырган.

– Менә сиңа балдак, патшага илтеп бир, ләкин бер алтыннан артыгын алма, – дигән ул. – Мин ясаганны да белгертмә, «үзем ясадым» диген, – дип тә өстәгән.

Балдакны кәләш бик ошаткан.

– Бу – нәкъ мин теләгән балдак, – дигән ул.

Патша да бик шатланган. Әбигә өеннән бер табак алтын алып чыгып биргән. Әби табактан бер алтын алган да калганнарын алып кереп китүен сораган.

Патша әбидән:

– Нигә алай аз аласың? – дип сораган.

– Миңа артыгы кирәкми, патша галиҗәнаплары. Кирәк булса, син бит миңа болай да бирәсең, – дигән әби һәм килгән юлыннан кайтып киткән.

Күпмедер вакыттан соң шәһәрдә яшь кәләш ниндидер никах күлмәге таптыра, таба алмасалар, үзе теләгәнне тегеп бирүләрен сорый икән дигән сүз таралган. Шул сүзне ишетүгә, карчык кызга янә ул сораган күлмәкне китереп биргән. Аннан соң те-

гелеп бетмәгән башмаклар китергән. Аларын да үзем тектем, дигән һәм бер алтыннан артык алтын алмаган.

Менә патшаның олы улының өйләнер көне килеп җиткән. Патша улы Иван карчыкка янә бер гозерен белдергән: «Кәләшне никахлашу урынына алып килүгә, миңа әйтерсең», – дигән.

Әби әйткән вакытка Иван, үзенең затлы патша киемнәрен киеп, урамга чыккан. Әби, моны күреп, куркуыннан шунда ук патша улы Иванның аягына егылган.

– Патша атакаем, кичер мине. Мин бит сиңа, ачуланып, дорфа сүзләр әйттем, – дигән.

– Аллаһ кичерсен, – дигән егет.

Шуннан ул чиркәүгә, никахлашу урынына киткән. Бу вакытта әле кияү егете килеп җитмәгән булган. Иван кәләш янына барып баскан. Аларга поп никах укыган.

Сарайга кайтып барганда, боларның каршына кияү егете килеп чыга. Ул кәләшен Иван белән бергә күреп ала да, оятыннан нишләргә белмичә, алдын-артын карамый кача.

Патша Иван белән кәләшне бик шатланып каршы ала. Туй мәшәкатьләре беткәч, ул олы малайларын сөргенгә сөрдерә, ә варисы итеп кече малае Иванны калдыра.



# Кощей Бессмертный

В некотором царстве, в некотором государстве жил-был царь; у этого царя было три сына, все они были на возрасте. Только мать их вдруг унёс Кощей Бессмертный. Старший сын просит у отца благословенье искать мать. Отец благословил; он уехал и без вести пропал. Средний сын пождал-пождал, тоже выпросился у отца, уехал, – и тот без вести пропал. Малый сын, Иван-царевич, говорит отцу: «Батюшка! Благословляй меня искать матушку». Он не отпускает, говорит: «Тех нет братьев, да и ты уедешь: я с кручины умру!» – «Нет, батюшка, благословишь – поеду, и не благословишь – поеду». Отец благословил.

Иван-царевич пошёл выбирать себе коня: на которого руку положит, тот и падёт. Идёт Иван-царевич доро́гой по городу, повесил голову. Ниоткуда взялась старуха, спрашивает: «Что, Иван-царевич, повесил голову?» – «Уйди, старуха! На руку положу, другой пришлёпну – мокренько будет». Старуха побежала другим переулком, идёт опять навстречу, говорит: «Здравствуй, Иван-царевич! Что повесил голову?» Он и думает: «Что же старуха меня спрашивает? Не поможет ли мне она?» И говорит ей: «Вот, бабушка, не могу найти себе доброго коня». – «Дурашка, мучишься, а старухе не кучишься! – отвечает старуха. – Пойдём со мной». Привела его к горе, указала место: «Копай здесь». Иван-царевич разрыл землю и увидел чугунную доску на двенадцати замках; замки он тотчас же сорвал и двери отворил, вошёл под землю: тут прикован на двенадцати цепях богатырский конь; он, видно, услышал ездока по себе, заржал, забился, все двенадцать цепей порвал. Иван-царевич надел на себя богатырские доспехи, надел на коня узду, черкасское седло, дал старухе денег и сказал: «Благословляй и прощай, бабушка!» Сам сел и поехал.

Долго ездил, наконец доехал до горы; пребольшущая гора, крутая, взъехать на неё никак нельзя. Тут и братья его ездят возле горы. Поздоровались, поехали вместе: доезжают до чугунного камня пудов в полтораста, на камне надпись: «Кто этот камень бросит на́ гору, тому и ход будет». Старшие братья не могли поднять камень, а Иван-царевич с одного маху забросил на́ гору – и тотчас в горе показалась лестница. Он оставил коня, наточил из мизинца в стакан крови, подаёт братьям и говорит:

– Ежели в стакане кровь почернеет, не ждите меня, значит, я умер! – Простился и пошёл. Зашел на́ гору, чего он не насмотрелся! Всяки тут леса, всяки ягоды, всяки птицы!

Долго шёл Иван-царевич, дошёл до дому: огромный дом! В нём жила царская дочь, утащенная Кощеем Бессмертным. Иван-царевич кругом ограды ходит, а дверей не видит. Царская дочь увидела человека, вышла на балкон, кричит ему:

– Тут, смотри, у ограды есть щель, потронь её мизинцем, и будут двери. – Так и сделалось. Иван-царевич вошёл в дом. Девица его приняла, напоила-накормила и расспросила. Он ей рассказал, что пошёл доставать мать от Кощея Бессмертного. Девица говорит ему на это:

– Нелегко тебе придётся, Иван-царевич! Он ведь бессмертный – убьёт тебя. Ко мне он часто ездит... вон у него меч в пятьсот пудов, поднимешь ли его? Тогда ступай!

Иван-царевич не только поднял меч, ещё бросил кверху, сам пошёл дальше.

Приходит к другому дому; двери знает, как искать; вошёл в дом, а тут его мать. Обнялись, поплакали. Он и здесь испытал свои силы, бросил какой-то шарик в полторы тысячи пудов. Время приходит быть Кощею Бессмертному; мать спрятала его. Вдруг Кощей Бессмертный входит в дом и говорит:

– Фу-фу! Русской костки слыхом не слыхать, видом не видать, а русская костка сама на двор пришла! Кто у тебя был? Не сын ли?

– Что ты, Бог с тобой! Сам летал по Руси, нахватался русского духу, тебе и мерещится, – ответила мать Ивана-царевича. А сама поближе с ласковыми словами к Кощею Бессмертному, выспрашивает то, другое и говорит:

– Где же у тебя смерть, Кощей Бессмертный?

– У меня смерть, – говорит он, – в таком-то месте: там стоит дуб, под дубом – ящик, в ящике – заяц, в зайце – утка, в утке – яйцо, в яйце – моя смерть.

Сказал это Кощей Бессмертный, побыл немного и улетел. Пришло время – Иван-царевич благословился у матери, отправился по смерть Кощея Бессмертного. Идёт доро́гой много время, не пивал, не едал; хочет есть до смерти и думает: кто бы на это время попался! Вдруг – волчонок; он хочет его убить. Выскакивает из норы волчиха и говорит:

– Не тронь моего детища, я тебе пригожусь.

– Быть так!

Иван-царевич отпустил волчонка; идёт дальше, видит ворону. «Постой, – думает, – здесь я закушу»! Зарядил ружьё, хочет стрелять, ворона и говорит:

– Не тронь меня, я тебе пригожусь.

Иван-царевич подумал и отпустил ворону.

Идёт дальше, доходит до моря, остановился на берегу. В это время вдруг выпал на берег щучонок, Иван его схватил, есть хочет смертно – думает: «Вот теперь

поем!» Ниоткуда взялась щука, говорит: «Не тронь, Иван-царевич, моего детища, я тебе пригожусь».

Он и щучонка отпустил.

Как пройти море? Сидит на берегу да думает: щука ровно знала его думу, легла поперёк моря. Иван-царевич прошёл по ней, как по́ мосту; доходит до дуба, где была смерть Кощея Бессмертного, достал ящик, отворил – заяц выскочил и побежал. Где тут удержать зайца! Испугался Иван-царевич, что отпустил зайца, призадумался, а волк, которого не убил он, кинулся за зайцем, поймал и несёт к Ивану-царевичу. Он обрадовался, схватил зайца, распорол его и как-то оробел: утка спорхнула и полетела. Он пострелял, пострелял – мимо! Задумался опять. Ниоткуда взялась ворона с воронятами и ступай за уткой, поймала утку, принесла Ивану-царевичу. Царевич обрадовался, достал яйцо, пошёл, доходит до моря, стал мыть яичко, да и уронил в воду. Как достать из моря? Безмерна глубь! Закручинился опять царевич.

Вдруг море встрепенулось – и щука принесла ему яйцо, потом легла поперёк моря. Иван-царевич прошёл по ней и отправился к матери: приходит, поздоровались, и она его опять спрятала. В то время прилетел Кощей Бессмертный и говорит:

– Фу-фу! Русской костки слыхом не слыхать, видом не видать, а здесь Русью несёт!

– Что ты, Кощей? У меня никого нет, – отвечала мать Ивана-царевича. Кощей опять и говорит:

– Я что-то занемог!

А Иван-царевич пожимал яичко: Кощея Бессмертного от того коробило. Наконец Иван-царевич вышел, показывает яйцо и говорит:

– Вот, Кощей Бессмертный, твоя смерть!

Тот на коленки против него и говорит:

– Не бей меня, Иван-царевич, станем жить дружно; нам весь мир будет покорён.

Иван-царевич не обольстился его словами, раздавил яичко – и Кощей Бессмертный умер.

Взяли они, Иван-царевич с матерью, что было нужно, пошли на родиму сторону; по пути зашли за девицей, доходят до горы, где братья Ивана-царевича ждут. Девица говорит:

– Иван-царевич! Воротись ко мне в дом, я забыла подвенечное платье, брильянтовый перстень и нешитые башмаки.

Между тем он спустил мать и царскую дочь, с коей они условились дома обвенчаться; братья приняли их, да взяли спуск и перерезали, чтобы Ивану-царевичу нельзя было спуститься, мать и девицу как-то угрозами уговорили, чтобы дома про Ивана-царевича не сказывали. Прибыли в своё царство; отец обрадовался детям и жене, только печалился об одном Иване-царевиче.

А Иван-царевич воротился в дом своей невесты, взял обручальный перстень, подвенечное платье и нешитые башмаки; приходит на́ гору, метнул с руки на́ руку перстень. Явилось двенадцать молодцов, спрашивают:

– Что прикажете?

– Перенесите меня вот с этой горы.

Молодцы тотчас его спустили. Иван-царевич надел перстень – их не стало, пошёл в своё царство, приходит в тот город, где жил его отец и братья, остановился у одной старушки и спрашивает:

– Что, бабушка, нового в вашем царстве?

– Да чего, дитятко! Вот наша царица была в плену у Кощея Бессмертного; её искали три сына, двое нашли и воротились, а третьего, Ивана-царевича, нет, и не знают, где. Царь кручинится об нём. А эти царевичи с матерью привезли каку-то царску дочь, большак жениться на ней хочет, да она посылает наперёд куда-то за обручальным перстнем или велит сделать такое же кольцо, какое ей надо; давно уже клич, да никто не выискивается.

– Ступай, бабушка, скажи царю, что ты сделаешь; а я пособлю, – говорит Иван-царевич.

Старуха в кою пору собралась, побежала к царю и говорит:

– Ваше царско величество! Обручальный перстень я сделаю.

– Сделай, сделай, бабушка! Мы таким людям рады, – говорит царь, – а если не сделаешь, то голову на плаху.

Старуха перепугалась, пришла домой, заставляет Ивана-царевича делать перстень, а Иван-царевич спит, мало думает, перстень готов. Он шутит над старухой, а старуха трясётся вся, плачет, ругает его:

– Вот ты, – говорит, – сам-то в стороне, а меня, дуру, подвёл под смерть.

Плакала, плакала старуха и уснула. Иван-царевич встал поутру рано, будит старуху:

– Вставай, бабушка, да ступай понеси перстень, да смотри: больше одного червонца за него не бери. Если спросят, кто сделал перстень, скажи: сама, на меня не сказывай!

Старуха обрадовалась, снесла перстень, невесте понравился:

– Такой, – говорит, – и надо!

Вынесла ей полно блюдо золота; она взяла один только червонец. Царь говорит:

– Что, бабушка, мало берёшь?

– На что мне много-то, ваше царско величество! После понадобятся – ты же мне дашь. – Пробаяла это старуха и ушла.

Прошло там сколько времени – вести носятся, что невеста посылает жениха за подвенечным платьем или велит сшить такое же, какое ей надо. Старуха и тут успела (Иван-царевич помог), снесла подвенечное платье. После снесла нешитые баш-

маки, а червонцев брала по одному и сказывала, что эти вещи сама делает. Слышат люди: у царя в такой-то день свадьба; дождались и того дня. А Иван-царевич старухе заказал:

– Смотри, бабушка, как невесту привезут под венец, ты скажи мне. – Старуха время не пропустила. Иван-царевич тотчас оделся в царское платье, выходит:

– Вот, бабушка, я какой!

Старуха в ноги ему.

– Батюшка, прости, я тебя ругала!

– Бог простит.

Приходит в церковь. Брата его ещё не было. Он встал в ряд с невестой: их обвенчали и повели во дворец. На дороге попадается навстречу жених, большой брат, увидал, что невесту ведут с Иваном-царевичем, со стыдом повернул обратно. Отец обрадовался Ивану-царевичу, узнал о лукавстве братьев и, как отпировали свадьбу, больших сыновей разослал в ссылку, а Ивана-царевича сделал наследником.



# Алтын балта

Борын-борын заманда бер карт яшәгән, ди. Бик ярлы карт булган, ди, бу! Аның тимер балтадан башка бер әйбере дә булмаган, ди. Якын кешесе дә юк икән моның. Карт көн саен урманга бара, анда әзрәк утын кисә һәм шул утынны күтәреп өенә алып кайта торган булган.

Алып кайткан утынның бер өлешен кышка калдырган. Икенче өлешен кәҗә сөте белән арыш ипиенә алыштырган, ди, карт. Ул шулай ачлы-туклы көн күргән, ди.

– Әле дә балтам бар, югыйсә ачка үләр идем, – дип кабатлый икән бу.

Беркөнне иртә таңнан торып, карт урманга утынга киткән, ди. Әмма басманың уртасына җиткәч, көчле давыл чыккан да басманы чалшайткан һәм картның аркасындагы утыны белән балтасы суга төшеп киткән, ди.

Көч-хәл белән басмадан чыккач, карт:

– Харап булдым, харап булдым. Инде нишләрмен, каян балта алырмын, нәрсә ашап яшәрмен, – дип, ахылдап, бик озак җирдә елап яткан.

Аның елау тавышын елгада йөзеп йөрүче бер балык ишетеп, бик кызганган, ди.

Озак та үтмәгән, яр буенда елап ятучы картка ул алтын балта китергән дә:

– Мә, бабай, елама, сиңа алтын балта китердем, – дип әйткән, ди.

Карт балтаны тотып та карамаган:

– Бик матур балта икән дә, минеке түгел шул бу, – дигән ачынып.

Балык йөзеп киткән дә икенче балта алып килгән, ди. Монысы көмеш балта икән. Карт монысын тотып караган да тагын:

– Бик матур балта икән дә, минеке түгел шул бу, – дип, бик каты уфтанган, ди.

Балык өченче балта артыннан киткән. Монысы тимер балта икән. Карт үзенең балтасын шундук таныган, ди, һәм, куанып:

– Менә монысы минем балтам! – дип кычкырып ук җибәргән һәм балыкка зур рәхмәтләр укыган.

Балык аңа:

– Син, бабай, бик тугры кеше икәнсең. Алдамадың, – дип, картны мактаган, ди. Аннары: – Бу балталарның өчесе дә сиңа булсын, – дип әйткән дә суга чумып юкка чыккан.



Карт исә, өч балтаны күтәреп, шатлана-куана, авылына кайтып киткән, ди. Юлда үзе белән булган хәлне, елгадагы балыкның аңа өч балта бүләк итүен, очраган бер кешегә һич тә яшермичә сөйләп кайткан, ди.

Картның сүзләрен күршесе дә ишеткән, ди. Ул бик саран, бик көнче, бик алдакчы кеше булган. Картка аны-моны әйтмичә, иртәгесен, балтасын алып, басма янына киткән. Басмадан елга уртасына җиткәч, балтасын юри суга төшереп җибәргән, ди. Ә үзе кычкырып-кычкырып еларга тотынган, ди.

Балык моның тавышын ишетеп, аңа да алтын балта китергән, ди.

– Балтаң шушымы? – дип сораган, ди, балык әлеге алдакчыдан.

– Шушы, шушы. Нәкъ үзе, – дип калтыранып җавап биргән, ди, ул балыкка.

Балык шушы сүзләрне ишеткән дә алтын балтаны алдакчыга бирмичә суда югалган.

Яр буенда бик озак елап-үкереп ятса да, алдакчының янына килүче булмаган, ди. Әнә шулай ул алтын балтадан гына түгел, үзенең балтасыннан да колак каккан, ди.



СИРИЙСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Золотой топор

Давным-давно жил-был старик. Он был одиноким и очень бедным. Кроме железного топора, у него ничего не было. Каждый день он ходил в лес за дровами. Часть дров оставлял на зиму, остальное продавал на базаре, а на вырученные деньги покупал козье молоко и ржаной хлеб. Так и жил впроголодь.

– Хорошо, что у меня топор есть. А то помер бы с голоду, – повторял он.

Однажды утром рано пошёл за дровами. Вдруг откуда ни возьмись поднялся ветер, старик потерял равновесие на мосту и уронил топор в речку.

Старик еле-еле добрался на другую сторону речки и долго плакал, приговаривая:

– О горе мне! Как я проживу без топора?!

Одна рыбка услышала, как старик плачет, пожалела его и принесла золотой топор. Приплыла к старику и говорит: «Не плачь, старик, я тебе топор принесла. Не простой, а золотой!» Старик даже не дотронулся до топора, только с горечью сказал: «Красивый топор, да не мой». Рыбка уплыла обратно и достала другой, на этот раз серебряный, топор. Старик посмотрел и говорит: «Хороший топор, но не мой».

В следующий раз рыбка принесла ему железный топор. Старик узнал свой старый топор и очень обрадовался: «Вот это мой топор! – воскликнул он. – Огромное спасибо тебе, рыбка». Рыбка ему в ответ: «Старик, вижу, ты очень честный человек. За это я дам тебе все три топора».

Старик взял их, и, радостный, пошёл домой. По дороге всем, кто встречался на его пути, он рассказывал о том, что с ним случилось.

Об этом услышал и сосед старика. Он был очень жадным и завистливым человеком. На следующее утро он взял свой топор и пошёл к речке. Стоя на мосту, нарочно уронил свой топор в воду. А сам сидит и громко-громко рыдает. На шум приплыла та самая рыбка и принесла ему золотой топор. «Это твой топор?» – спрашивает рыбка. «Да, это мой топор, точно мой», – ответил он.

Услышав ответ, рыбка разозлилась на лгуна и, забрав топор, уплыла обратно.

Сосед старика долго лежал на берегу и плакал, к нему никто так и не подошёл. Вот так лгун остался без топора.

Много захочешь, последнее потеряешь.

# Падишаһ һәм Ходай бүләкләре

Бервакыт Әпәнде падишаһ белән сөйләшә икән. Падишаһның теленнән:
– Ни телисең, шуны сора! – дигән сүз ычкынган.
Хакимнең мондый киң күңеллелегенә гаҗәпләнеп, Әпәнде:
– Сүзең хак икән, бер капчык алтын бүләк ит, солтаным! Хатыным, балаларым белән һич кайгысыз яшәрлек булсын, – дип җавап биргән Әпәнде.

Ни әйткәнен аңлап алган падишаһ, бер капчык алтын бирергә кушканда, сиздермичә генә казначыга күз кысып алган.

– Баш өсте, падишаһым, – дип, казначы чыгып киткән.

Авыр, зур капчыкны күтәреп, Әпәнде шатланып өенә кайтып кергән.

– Хатын, шатлан! – дип кычкырган ул, – бүгеннән безнең казаннан да, кашыктан да май тамып торыр, көненә ун күлмәк алыштырсаң да, унар төрле сөрмә-иннек алсаң да, унар тапкыр мунчага барсаң да – барысына да акча бирәм! Әйдә, бу алтынны бергәләп саныйк әле, үзем генә очына чыга алмам!

Әпәнде капчыкны ачып селеккән икән, ни күзе белән күрсен, җирдә алтын урынына вак ташлар гына ята, ди.

– Нәрсә инде бу? – дип сораган хатыны. – Бу ташларны кем бирде, ник алып кайттыгыз?

– Падишаһ, минем үтенечемне канәгатьләндереп, бер капчык алтын бирергә вәгъдә иткән иде. Бу – шул капчык. Бер капчык таш күтәреп йөрергә ахмак түгел бит инде мин! – дип ярсыган Әпәнде.

– Сезгә капчыгы белән алтын бүләк итәргә падишаһ та ахмак түгел шул! – дигән хатыны. – Падишаһтан түгел, Ходайдан сорарга кирәк!

– Дөрес сөйлисең, хатын, – дигән Әпәнде һәм, тәһарәтләнеп, кыйблага карап тезләнгән дә Аллага ялвара башлаган:

– И Ходаем, үз байлыкларыңнан бер капчык алтын җибәрсәң иде!

Кич тә җиткән, караңгы төшкән, ярты төн узган, Әпәнде һаман Ходайга ялваруында булган, ә капчык белән алтын төшми дә төшми икән.



«Бәлки, Аллаһы Тәгалә мине ишетми торгандыр? Бәлки, катырак кычкырыргадыр?» дип уйлаган Әпәнде һәм кычкырып-кычкырып Ходайга ялварырга тотынган.

Әпәнденең тавышына җиденче төшен күреп ята торган күршесе уянган. «Нәрсә инде бу?» – дип сукрана-сукрана өй түбәсенә менеп караса, Алладан алтын сорап ялваручы Әпәндене күреп алган. Торган-торган да, тәмам сабырлыгы бетеп, дивардан кирпеч кубарып алып Әпәндегә ыргыткан.

Үзе янына нәрсәдер килеп төшкәнен күргән Әпәнде, сөенеп:

– Хатын, лампа алып кил, Ходай безгә алтын җибәрде! – дип кычкырган.

Барып карасалар, бер кисәк янган кирпеч ята, ди. «Ярый әле Ходай башыма бәрмәгән бу кирпеч белән!» – дип уйлаган Әпәнде һәм:

– Ходай белән падишаһ бер сүздә икән! – дигән.



# Дары падишаха и Бога

Однажды Афанди случайно угодил падишаху.

– Проси у меня всё, что хочешь! – сорвалось с языка падишаха.

Поразмыслив о необычайной милости властелина, Афанди сказал:

– Раз Вы хотите сделать мне подарок, то подарите мешок золота, чтобы остаток своей жизни я мог прожить безбедно с женой и детьми!

Но падишах уже опомнился и потому, приказав казначею выдать Афанди запечатанный мешок, чуть заметно подмигнул.

Сказав: «Повинуюсь, господин», казначей вышел. Получив увесистый мешок, Афанди, радостный, понёс его домой.

– Ликуй, жена, – сказал он. – Теперь у нас и котёл жирный, и ложка жирная; если хочешь, одевайся каждый день по десять раз в разные платья, покупай себе десять сортов усьмы и сурьмы, пудры и кармина, ходи хоть по десять раз в день в баню, – на всё я тебе дам денег. А пока подойди сюда, и давай посчитаем это золото вместе, один я не справлюсь со счётом!

Афанди отрезал ножом печать на мешке, опрокинул его, но вместо золота посыпались мелкие камешки.

Ошеломлённый Афанди посмотрел на небо, потом на землю и, опустив голову, глубоко задумался.

– Что всё это значит? – спросила встревоженная жена. – Кто дал Вам эти камни, и зачем Вы их принесли?

– Это значит, падишах исполнил мою просьбу, подарил мне мешок золота. А я нёс его сюда. Ведь не дурак же я, чтобы приносить мешок с камнями! – ответил, негодуя, Афанди.

– И падишах не дурак, чтоб давать Вам мешок золота, – сказала укоризненно жена. – Вы не у падишаха просите золота, а у Бога!

– Это ты верно говоришь, жена!

После омовения, обратив лицо к Мекке, Афанди опустился на колени и воздел руки: «О Боже, о Всемогущий, пошли мне из твоей сокровенной казны мешок золота!»

Наступил вечер, прошло время последней вечерней молитвы, наступила полночь, а Афанди всё продолжал молиться, но золото из сокровенной казны не появлялось.

«Может быть, я тихо молюсь, и Бог не услышал мою молитву? Может быть, надо молиться громче?» – подумал Афанди и стал выкрикивать слова своей молитвы во всю силу голоса.

Спавший сном праведника сосед пробудился от дикого крика Афанди и, бормоча: «Что это такое?», полез на крышу своего дома. Оттуда он увидел Афанди, громко просящего у Бога золота. Сосед постоял немного, понаблюдал за Афанди, но не вытерпел и, отколупнув от стены полкирпича, бросил его в Афанди.

Услыхав звук чего-то упавшего неподалёку, Афанди радостно воскликнул:

– Жена! Неси скорее светильник, Бог послал нам золота из своей сокровенной казны!

Жена принесла светильник, Афанди увидел обломок жжёного кирпича и, подумав: «Хорошо ещё, что Бог не угодил мне этим кирпичом в голову!», обратился к жене:

– Теперь ясно, – Бог с падишахом заодно!



# Ак Елан

Бер хан бар иде. Ул беркөн төш күрде. Иртәгесен йортка яр салды[1]:

– Кем дә кем, алдыма килеп, төшемдә ни күргәнемне әйтсә, аңа йөз алтын бирәм. Әгәр дә алдыма килеп, күргән төшемне әйтә алмаса, башын кисәм.

Янә ул заманда бер бик ярлы, фәкыйрь ир бар иде. Ул ирнең хатыны, иренә дошман булып, һәрдаим аны үтерү нияте белән йөри иде. Шушы хатын, әлеге сүзне ишетеп, хан каршына килде һәм әйтте:

– Патшакаем, төшеңне минем ирем юрый ала, әмма әйтми, – диде.

Хан, хатын сүзенә ышанып, шунда ук кеше җибәреп, ул байгышны чакыртты. Мескенчәк юлда бу хәлгә зар елап, Тәңрегә тилмереп вә аннан ярдәм сорап, җаныннан өмет өзеп килгәндә, аңа Ак Елан очрады. Елан сәлам бирде. Бу фәкыйрь җавап бирде.

Елан сорады:

– Әй, адәм, кая барасың вә каян киләсең, вә ни өчен елыйсың?

Бу фәкыйрь хәл-әхвәлен сөйләп бирде:

– Ханыбыз бер төш күргән. Кем дә кем төшемне юрый, шуңа йөз алтын бирәм, юрый алмаса, башын кисәм, дип әйткән.

Елан әйтте:

– Теләсәң барырсың, теләмәсәң бармассың.

Ир әйтте:

– Минем хатыным бар, ул миңа дошман. Һәркайчан мине үтерү нияте белән йөри. Бу хәбәрне ишеткәч, хан янына барып әйткән: «Синең күргән төшеңне минем ирем белә, белсә дә әйтми» дип. Ханның кеше җибәреп мине алдыруының сәбәбе шул, – диде.

Бу сүзне ишетеп, Ак Елан әйтте:

– Әгәр мин аның төшен сиңа әйтсәм, син үлемнән котыласың, ул йөз алтынны миңа китереп бирерсеңме? – диде.

Фәкыйрь әйтте:

– Алтын белән көмештән җан яхшы. Әгәр үлемнән котылсам, берсе дә кирәкмәс, һәммәсен китереп бирермен, – диде.

---

[1] *Яр салу* – хәбәр итү.

Елан әйтте:

– Барып керүең белән хан синнән сорар: «Әй, гариб[1], мин төшемдә ни күрдем?» – дип. Син җавабыңда: «Төшеңдә бүре күрдең», – дип әйт. Аннан соң ул сиңа йөз алтын бирер, син аны һич тә хыянәтсез миңа китереп бир, – диде.

Бу сүзне әйткәч, Ак Елан белән ир хушлаштылар. Елан – үз юлына, фәкыйрь хан янына китте. Менә ул хан йортына килеп җитте. Өенә керде, сәлам бирде. Хан да сәлам бирде. Аннан:

– Әй, гариб, мин төшемдә ни күрдем, әйт?! – диде.

Гариб:

– Син бүре күрдең, – дип әйтте.

Хан шунда ук йөз алтын бирде. Гариб, патша сараеннан чыгып, Ак Еланга бармыйча, туры өенә качып кайтты. Аннан соң ул алтынга бик күп елкы, хайваннар һәм мал сатып алды. Бай булды. Көн күрүе яхшырды.

Бер вакыттан соң хан янә бер төш күрде. Тагын гарибне чакыртты. «Әгәр тапса, йөз алтын бирәм, тапмаса, башын кисәм», – диде.

Бу гариб электә бик ярлы иде, бай булды. Хәзер җаны элеккедән дә татлы иде. Бик каты елады. Ахырда чарасызлыктан: «Барам!» – диде. Торды да юлга чыкты. Юлда бик зар елап, җаныннан өмет өзеп килгәндә, баягы Ак Еланга тап булды. Гариб сәлам бирде. Елан:

– Әй, гариб, кая барасың һәм ни өчен елыйсың? – диде.

Гариб әйтте:

– Хан тагын төш күргән, «белсә, йөз алтын бирермен, белмәсә, башын кисәрмен» дип, мине төшен юрамакка чакыртты. Инде башымның китүе шулдыр.

Елан әйтте:

– Мин беләм, ләкин сиңа әйтмим. Син теге вакытта миңа ялганладың, алтынны бирми алдап качып киттең.

Гариб:

– Бу төшнең мәгънәсен әйтсәң, мине бу үлемнән коткарсаң, монысын гына түгел, алдагы алтынны да китереп бирермен, – дип ант эчте.

Елан әйтте:

– Бу юлы алдама. Башка вакытта да кирәк булырмын. Инде ханга барып сәлам бир дә: «Син төлке күрдең», – дип әйт. Аннан, йөз алтынны алып, кире миңа кайт.

Гариб, бу сүзне ишетеп, шат булып, хан янына килде. Сәлам бирде. Хан сорады:

– Мин төшемдә ни күрдем, әйт?! – дип.

Гариб әйтте:

– Син төлке күрдең, – диде.

Хан йөз алтын бирде. Гариб Ак Еланга бармый тагын өенә качып кайтты. Элеккедән дә бай булды, уйнады, көлде. Байлыгына горурланып, тәкәбберләнеп йөрде.

---

[1] *Гариб* – ярлы, йорт-җирсез кеше.



Баягы хан янә бер төш күрде. Янә әлеге гарибне дәштерде. «Тапса, йөз алтын бирәм, тапмаса, башын кисәм!» – диде. Ир, бу сүзне ишеткәч, тагын да катырак елый башлады: «Ак Еланны алдадым, бу вафасыз дөньяда кала торган мал өчен бит», – диде. Авырлык белән юлга чыкты. Җанынннан өмет өзеп килгәндә, каршысында янә Ак Елан пәйда булды. Моны күреп әйтте:

– Ялганчы гариб, ике үлемнән котылдың, өченчесендә – тотылдың.

Гариб әйтте:

– Әй Ак Елан, мине ике үлемнән азат кылдың, мин синең кадереңне белми ул яман эшләрне эшләдем, инде тәүбәгә килдем. Бу үлемнән азат итеп, аталык мәрхәмәтен, аналык шәфкатен кылсаңчы. Әүвәл – Алла каршында, икенче үзең каршыңда кыямәт көнне мәхшәрдә миңа ялганчылык атын кушма. Дөнья эшен дөньяда бетерим һәм сиңа бирәчәк алтыннарның барчасын тапшырып китим.

Ак Елан бу сүзне хуш күрде, әйтте:

– Бар, ханның өенә кер, сәлам бир. Ул синнән сораса: «Ни күрдем?» – дип, син әйт: «Төшеңдә куй күрдең», – диген. Ул сиңа йөз алтын бирер. Син аны алып килеп миңа бир.

Аннан соң ир Ак Елан белән саубуллашып китте. Патша сараена җитте. Өй эченә кереп сәлам бирде. Хан:

– Әй, гариб, мин төшемдә ни күрдем? – диде.

Гариб әйтте:

– Син куй күрдең, – диде.

Хан йөз алтын бирде. Ир, аны алып, Ак Еланга килде. Сәлам бирештеләр. Ир әйтте:

– Синең хәер-догаңда сау-сәламәт кайттым. Җаным михнәт чикмәде. Кабул ит, менә бездәге әманәт алтының һәм өемдәге ике йөз алтынны да сиңа китереп бирәм. Мин борынгы ике йөз алтынны да сиңа бирергә ихлас күңелем белән ният кылган идем, белмим, ничек бирә алмадым. Хәзер дә акылсызлыгыма хәйран каламын.

Моңа каршы Ак Елан:

– Егет, мин сиңа моның ни өчен шулай килеп чыкканлыгын әйтим, син яхшы тыңла: әүвәл хан бүре күрде. Ул заманда һәм ханның, һәм ил-йортның бүре булган вакыты иде. Бүре яхшылык белми. Шуңа күрә син дә, вәгъдәңдә торып, алтынны миңа бирмәдең. Аннан соң хан төлке күрде. Ул вакытта ил-йорт төлкедәй алдакчы булды. Шуның өчен син дә миңа ялган сүзләр әйтеп алдадың. Соңгысында хан төшендә куй күрде һәм золымлыгын ташлады, гадел булды, йорт та тугры булды. Хан залим булса, ил-йорт тәртипсез, угры, үтерүче булыр. Хан гадел булса, йорт тугры, инсафлы, суфи булыр. Синдә гаеп юк, гаеп ханда. Хан, төшендә бу өч хайванны күреп, тәүбәгә килде. Син дә миңа алтын китердең. Ил-йорт яман булганда, син дә яман булдың; яхшы булганда, син дә яхшы булдың, һәрвакыт ил-йорт белән бергә булдың. Алтыннарың үзеңә хәләл булсын! – диде дә күз алдыннан югалды.

# Белый Змей

В давние времена был один хан. Лёг он однажды спать и увидел сон. А наутро повелел объявить всей своей стране: «Кто явится ко мне во дворец и расскажет, о чём был мой сон, получит сто золотых монет. А кто явится, но сна не угадает – лишится головы».

В то же самое время, в том же самом городе жил один бедный джигит. Жена у него была такая злющая, что даже самой себе вредила. А уж мужу и подавно. Каждый день думала она, как бы сделать так, чтобы джигита извести.

Услышав ханские слова, побежала она быстрее во дворец и так хану сказала:

– Послушай, хан! Знает мой муж, что ты видел во сне, но к тебе во дворец он не придёт, тебе об этом не скажет.

Поверил хан злой обманщице, рассердился, и тут же послал своих слуг, чтобы передали бедняку ханский приказ – немедленно во дворец явиться. Не хотел джигит идти, да что поделаешь – когда хан зовёт, бедняку трудно отказаться. Вот идёт он, плачет слезами солёными, с ясным солнцем, с зелёной травой, с синим небом прощается. Никакой надежды у него нет. Тут встречается ему Белый Змей. Поздоровался Змей и спрашивает:

– Эй, бедняк, куда идёшь ты и откуда, и почему ты плачешь?

Рассказал бедняк о ханском указе:

– Наш хан увидел какой-то сон. И теперь, если найдётся такой смельчак, что явится во дворец и расскажет ему, о чём был тот сон, получит сто золотых монет. А если явится, но сна не угадает – головы лишится.

Змей снова спрашивает:

– Значит, если не хочешь, можно во дворец не идти?

Вздохнул джигит и объяснил, в чём дело:

– Есть у меня, – говорит, – жена. Не жена, а настоящий враг. Ходит она и думает, как сделать так, чтобы я пропал. Услышала жена слова хана, скорее к нему побежала и сказала, мол, знает мой муж, что видел ты во сне, но к тебе во дворец он не придёт, тебе об этом не скажет. Хан, конечно, тогда прислал ко мне своих слуг с приказом – велел к нему явиться.

– Что ж, – говорит Белый Змей, – если спасу я тебя от смерти, если скажу тебе, что видел хан во сне, отдашь ты мне сто золотых монет, которыми наградит тебя хан?

Отвечает бедняк:

– Хоть и говорят, что богатство дороже отца с матерью, а жизнь всё равно дороже любого богатства. Если спасёшь меня от смерти, ничего мне больше не надо, я за это всё, что у меня есть, тебе отдам.

Змей тогда научил джигита:

– Как войдёшь ты к хану, он тебя сразу спросит, что он видел во сне. Ответь ему: «Волка ты видел во сне, мой хан». Потом хан даст тебе сто золотых монет – скорее ко мне с ними иди, никуда не сворачивай.

Выслушал джигит, всё запомнил и, радостный, во дворец пошёл. Не успел войти, а хан уже спрашивает его грозным голосом:

– Ну, бедняк, говори, что я видел во сне?!

– Волка ты видел во сне, мой хан, – отвечает бедняк.

Удивился хан. Тут же велел отсыпать джигиту сто монет и отпустил его с миром. Вышел бедняк из дворца и, вместо того чтобы к Змею идти, скорей-скорей, тайком прибежал он к себе домой. Словно сами ноги его принесли. А потом купил бедняк на эти сто золотых монет хороший дом, лошадей, коров, овец, много всякого добра и утвари домашней. Был беднее бедного, теперь сделался богачом. И раньше любил он жизнь, а теперь ещё милее она ему стала. Жил он и радовался.

Да только прошло немного времени, и снова хан увидел сон. И снова прислал слуг за нашим джигитом. Так решил великий хан: «Если сможет бедняк и на этот раз рассказать, о чём сон, снова получит сто золотых монет. А если нет – велю ему голову отрубить».

А джигиту теперь ещё жальче с жизнью расставаться, да что поделаешь – ханского приказа нельзя не выполнить. Снова идёт он, плачет слезами солёными, с ясным солнцем, с зелёной травой, с синим небом прощается. Теперь уж точно никакой надежды у него не осталось. И тут навстречу ему тот же самый Белый Змей. Поздоровался джигит. Поздоровался и Змей, а потом спрашивает:

– Эй, бедняк, куда на этот раз ты идёшь, почему снова плачешь?

Опустил голову бедняк, говорит Змею:

– Снова наш хан увидел сон. Снова прислал за мной слуг со словами: «Если сможешь рассказать, о чём сон, получишь сто золотых монет. А если нет – голову тебе отрубят». Видно, пришёл мой час – на этот раз лишусь я бедной своей головы.

Отвечает Змей:

– Я знаю, о чём ханский сон, но тебе не скажу. Ты меня уже однажды обманул – сбежал с моим золотом.

Поклялся тогда джигит, что на этот раз не обманет Змея.

– Если и на этот раз меня выручишь, – говорит, – если расскажешь ханский сон,

если от верной смерти спасёшь, то принесу я тебе и те монеты, что в прошлый раз должен был дать.

– Что ж, прощу тебя. Но если и на этот раз хочешь меня обмануть, подумай: может быть, ещё раз придётся помощи моей искать, – предупредил Белый Змей. И рассказал:

– Как войдёшь к хану, сразу же спросит, что он видел во сне. Ответь так:

«Лисицу ты видел во сне, мой хан». Потом хан даст тебе сто золотых монет. На этот раз ко мне с ними иди – торопись, никуда не сворачивай.

Поблагодарил джигит Змея и во дворец поспешил. Только вошёл, спрашивает его хан:

– Ну, бедняк, скажи-ка мне, что я видел во сне?!

– Лисицу ты видел во сне, мой хан, – отвечает бедняк.

Тут же получил джигит сто золотых монет. Вышел он из дворца, но к Змею не пошёл. Скорей-скорей, тайком, тёмными кривыми улочками прибежал к себе домой. Теперь он ещё богаче сделался – не жизнь, а сплошное удовольствие. Спал на пуховой перине, радовался и смеялся бывший бедняк.

Да только не оставил его в покое хан, не дал сполна насладиться жизнью богатой. Прошло ещё немного времени, и ещё один сон увидел. И снова призвал к себе нашего джигита. Опять решил великий хан: «Если сможет бедняк и на этот раз рассказать, что видел я во сне, получит сто золотых монет. А если нет – велю ему голову отрубить».

Услышал бедняк ханский приказ, и заплакал так горько, как никогда ещё не плакал. Вспомнил он Белого Змея, и стыдно ему стало. Стал он сам себя укорять: «Обманул я благородного Белого Змея. И ради чего?! Ради золота, которое останется в этом бренном мире, когда душа моя к Аллаху пойдёт!» Но делать нечего. Как ни горько у него было на душе, как ни тяжело ему было, а пошёл он снова в ханский дворец. Идёт, с ясным солнцем, с зелёной травой, с синим небом прощается. Ниоткуда не ждёт он теперь спасения. Совсем надежду потерял. И тут снова встречается ему Белый Змей. Вместо приветствия кричит он джигиту:

– Эй, обманщик, бедняк-обманщик, два раза от смерти спасался, в третий – попался!

Вздохнул бедняк и ответил на это Змею:

– Эх, Белый Змей, два раза выручил ты меня, два раза спас мою бедную голову. Дважды, вместо благодарности, я тебя обманул. Но теперь я всё понял. Хочу, чтобы душа моя, когда придёт ей время, предстала перед Аллахом чистой и честной. Не называй же меня обманщиком. Будь великодушен, как отец, добр, как мать – спаси и на этот раз. Я верну всё твоё золото – и то, что раньше не принёс, и то, что сегодня получу, если ты простишь меня и расскажешь мне, что видел хан во сне.

Понравились Белому Змею такие слова.

– Что ж, – сказал он, – поверю ещё раз. Как спросит тебя хан, что он видел во

сне, ответь ему так: «Ты видел во сне овцу, великий хан». Потом хан даст сто золотых монет. Ну а потом ты и сам знаешь, что делать.

И пошёл джигит дальше. Пришёл во дворец. Спрашивает его хан:

– Скажи, бедняк, что я видел во сне?

– Ты видел во сне овцу, великий хан, – ответил бедняк.

Велел хан отсыпать ему сто золотых монет. Взял джигит эти деньги, вернулся к Белому Змею и отдал ему со словами:

– Благодаря тебе, снова вернулся я живой и здоровый. Никаких трудностей на пути не встретил. Вот сто монет. Прости за то, что обманул тебя два раза. Сам понять не могу – как такое могло случиться? Ведь когда я тебе обещал, то говорил искренне, так и собирался поступить. Не знаю, что на меня нашло?.. Сейчас схожу и принесу остальные монеты.

Покачал головой Белый Змей и ответил:

– Слушай меня внимательно, джигит. Расскажу я тебе, о чём на самом деле были ханские сны. Помнишь, увидел великий хан волка в первом сне? Это означает, что волчье было время – и сам хан, и слуги его, и вся страна словно волки друг другу были. Волк добра не знает. Поэтому и не принёс ты мне монеты – забрал себе, как свою добычу. Во втором сне увидел великий хан лисицу. Значит, лисье время стояло на дворе. И сам хан, и слуги его, и вся страна лживы и коварны были, словно лисы. Вот и ты меня обманул. В третьем сне увидел хан овцу – и раскаялся. Пришло время доброты и справедливости. Стал хан справедливым – и страна стала честной и праведной. И ты поступил по совести.

Все три раза ты поступал заодно со своей страной, поэтому нет на тебе вины. Страна была неправедной, и ты был таким. Стала страна честной, и ты честным стал. Поэтому простил я тебя. А золото мне не нужно, себе его возьми, – сказал Белый Змей и исчез, словно растворился в воздухе.



# Келуглан

Келуглан чәчсез булып дөньяга килгән. Әнисе улын һәр кич йоклаткан чакта: «Таз улым, тазкай улым, акыллы булганга чәчләре коелган зирәк улым», – дип сөяр икән. Бөтен авыл халкы таз малайның һәр очрак өчен әйтә алган фикерләреннән бик тәэсирләнер икән. Бер авыр хәлдә калсалар: «Хмм, моны хәл итә алачак бердәнбер кеше Келуглан» – диярләр, ди.

Беркөнне авылның сөрәнчесе кичке сәгатьләрдә сарайдан килгән бер хәбәрне игълан итәр өчен юлга чыккан. Барабанының тавышы сарган дүрт якка даң-доң китерә. Даң-доң: «Ишетмәдек димәгез, әй, җәмәгать, тыңлагыз! Патшабыз кызын кияүгә бирү өчен егетләр арасында бер ярыш үткәрә!» – даң-доң, даң-доң... Шулчак карт анасы янына йөгереп килгән Келуглан: «И сөекле әнием! Хәзерлә әйберләремне, киемнәремне, мин дә ярышта катнашыйм», – дия. Нәрсә дисәң дә, әнисенең күңеле бик разый түгел бу эшкә. Ни әйтсен? «Улым, син таз бит, патша кызы сине ошатмас», – дисенме? Бөтен уйларын эченә яшереп, дәшми кала Келугланның әнисе. Келугланның теләкләре анасының күңеленә борчу сала. Иртәгесе көнне безнең Келуглан иртәннән үк юлга чыга.

Патшаның сараена барса, ни күрсен? Сарай халык белән, шәһәр байлары белән тулы, ди. Барысы да ярышта катнаша. Патшаның кызы шулкадәр чибәр, шулкадәр гүзәлдер ки, бер күрүдә гашыйк булып тиле-дивана булган, ди, Келуглан. Патша гүрдән чыккан тавышы белән игълан итә: «Сезләрдән өч сорау сорармын. Җавап бирә алучыга кызымны бирәм!» Кемнәрдер ярышта атка менү, кылыч тоту, сөңге уйнату кебек уеннар була дип уйлаганнар. Шуңа сораулар бирәм дигәч, барысы да бик гаҗәпләнгәннәр! Келуглан исә бернәрсәгә дә борчылмаган.

Патша сорый икән: «Күк йөзендә ничә йолдыз бар?» Озакка сузылган тынлыктан соң, патша, беркем дә җавап бирмәячәгенә ышанып, Келуглан янына килеп: «Син әйт, тазбаш!» – ди. Келуглан гафил күренүенә карамастан, тиз генә җавабын да бирә: «Сезнең башыгызда ничә бөртек чәч бар, күк йөзендә шуның кадәр йолдыз бардыр, сез аларның санын яхшырак белерсез». Патша вәзирләренә карый. Вәзирләрнең күңелләренә бу җавап хуш килә. «Дөрес, патшам, дөрес», – диләр. Патша кызы да бу зирәк кешегә соклана. Патшаның исә эчтән генә ачуы килә. Бу

таз егетне кызына өйләндерергә теләми. Тагын бер сорау бирергә була: «Әйт, тыңлап карыйк әле, дөньяның үзәге кайда?» Келугланга бу сорау тагын да ансат, имеш. Йөзендә шаян бер елмаю белән: «Аякларымның астындадыр, ышанмасагыз, үлчәп карагыз!» – ди. Вәзирләрне бер мизгелгә курку биләп ала. Патша үлчәргә кушса нишләрсең? Барысы да җавапны беравыздан раслыйлар: «Дөрес, патшам, аякларының астындадыр». Патшаның эре яңаклары кызарып-бүртенеп чыга, патша кызы исә Келугланның һәр авыр сорауның да җавабын белүенә шатлана.

Патша биргән сүзеннән кайтмаячагын белгәнгә, иң авыр сорауны бирергә кирәклеген аңлый. Шулкадәр бер явыз нияткә килә ки, шатлыгыннан елмаюын тыя алмый. Үзе мыекларын бора-бора дәвам итә: «Ярый, ике сорауны белдең. Карап карыйк әле, менә монысын белә алырсыңмы икән? Ике бармагың белән дөньяны ничек кирегә әйләндерә аласың?» Патша болай мөмкин булмаганын белгәнгә күрә, гаять рәхәт бер рәвештә әйләнә-тулгана башлый. Вәзирләр бер-берләренә карашып калалар. Келуглан исә чәчсез башын кашый. Келугланның, кояш белән бергә көзгедә чагылган яктылык күзенә кергәнгә, менә дигән бер фикер башына килә. Тиз-тиз барып, халык арасында торган бер ханымнан көзгесен сорый. Патшаның каршысына килеп, «Сезнең рөхсәт белән» дип, патшаның башы өстендә ике бармагы белән тотып: «Карагыз, дөнья сезнең өчен хәзер кирегә әйләнә». Вәзирләрдән һәм халыктан искиткеч бер алкыш куба, патша кызы да бик шатлана, дулкынлана. Патша өченче сорауга да дөрес җавап тапкан Келугланга кызын бирергә мәҗбүр була.

Туйга чакырып, авылдагы әнисенә хәбәр биргәндә, әнисе: «Таз улым, зирәк улым, патша кызын да алдың бит!» – дип сөенә-сөенә туйга барырга юлга кузгалган, имеш. Келуглан һәм патша кызы яхшылап туй итеп, өйләнешеп бәхетле яшәгәннәр, ди.



# Кельоглан

Кельоглан родился плешивым. Мама его очень любила, и каждый раз перед сном напевала ему: «Мальчик мой, плешивый мальчик, из-за мудрости плешивым стал».

Мальчик был умным не по годам. Люди, когда не знали что делать, говорили: «Это может решить только Кельоглан».

Однажды в деревню приехали гонцы падишаха. Под звуки барабана они провозгласили: «Слушайте, слушайте, не говорите, что не слышали! Падишах устраивает соревнования, победитель получит в жёны дочь падишаха!»

Кельоглан услышал об этом и тут же прибежал домой: «Мама, мама! – говорит. – Я поеду в город, тоже буду участвовать в соревнованиях».

Мать не хочет отпускать, но и сказать не может: «Ты же плешивый, вряд ли понравишься дочери падишаха». Она промолчала, собрала вещи и проводила сына в город.

Приехал Кельоглан и увидел: на соревнования собрались все городские баи. Дочь падишаха была очень красивой, и Кельоглан влюбился в неё с первого взгляда. В этот момент падишах объявляет: «Я задам вам три вопроса, кто сможет ответить, тот станет моим зятем!»

Некоторые удивились: они думали, что будут конные скачки, метания копья, поэтому приехали в доспехах. Но не тут-то было! Только Кельоглан был спокоен.

Падишах задаёт первый вопрос: «Сколько звёзд на небе?» Никто не может ответить. После длительной тишины падишах, уверенный, что никто не ответит, подошёл к Кельоглану и говорит: «Скажи ты, плешивый!» Кельоглан отвечает: «Сколько волос на Вашей голове, столько и звёзд на небе, Вам виднее». Падишах смотрит на везиров, которым ответ понравился, и они подтверждают: «Правильно, Ваше высочество». Дочь падишаха восхищается мудростью юноши, а падишах злится: ему не хочется выдавать свою дочь за плешивого. Он задаёт второй вопрос: «Скажика, где находится центр Земли?» Кельоглан, улыбнувшись, с лёгкостью отвечает: «Под моими ногами. Если не верите, можете измерить». Везиры испугались: что они будут делать, если падишах прикажет измерить, поэтому в один голос сказа-

ли: «Правильно, Ваше высочество, под его ногами». Дочь падишаха обрадовалась за парня, а падишах покраснел. Ведь он знает, что обратного пути нет и что если Кельоглан отгадает последнюю загадку, дочь придётся выдать именно за него. И задаёт последний, самый трудный, вопрос: «Хорошо, ты ответил на два вопроса. А теперь скажи, можешь ли двумя пальцами заставить мир вертеться в обратном направлении?» Прекрасно понимая, что такое невозможно сделать, падишах стоит и радуется. Везиры переглядываются между собой.

Кельоглан думает да плешивую голову почёсывает. Солнечный зайчик падал ему прямо в глаз, может, поэтому его осенила гениальная мысль! Он попросил у одной женщины зеркало, подошёл к падишаху, поднял зеркало над его головой и сказал: «Смотрите, Ваше величество, мир вертится для вас в обратном направлении», – а сам двумя пальцами держит и поворачивает зеркало. Никто не мог додуматься до такого, все долго-долго хлопали юноше. Дочь падишаха была рада и очень волновалась. Падишах был вынужден объявить о свадьбе Кельоглана и дочери.

Мать Кельоглана, услышав радостную весть, сразу отправилась во дворец, напевая: «Мальчик мой, плешивый мальчик, всех ты обыграл, зятем падишаха стал!»

Кельоглан и дочь падишаха сыграли свадьбу и жили долго и счастливо.



# Кечкенә булса да, төш кенә

Берзаман авылга чабаннар йөгерешеп кайталар.Кайталар да:

– Күршеләр, ярдәм итә күрегез! – дип кычкырырга тотыналар. – Көтүебезгә бүре ияләште, көн саен бер сарыкның башына җитә! Капкын куеп карадык, эләкмәде явыз. Баз да казыган идек, сизгән каһәр, төшмәде. Сагалап торып үтермәкче булган идек, үтертмәде, бик көчле, бик җитез булып чыкты, ә зурлыгы – андыйны безнең беркайчан да күргәнебез юк иде әле. Әйдәгез, барып үтерик шуны! – диләр.

Авыл кешеләре башларын гына чайкыйлар.

– Чабаннар хәтле чабаннар да үтерә алмагач, безгәме соң аны җиңү! – диләр.

Ә Ярты колак[1] бу вакыт дувал өстендә чәчен үреп утыра икән. Шуңа күрә ул барысын да ишетеп тора. Шуннан бу нәзек тавышы белән көтүчеләргә:

– Әй, абзыйлар! Көтүегезне саклашырга мине дә алыгыз әле. Мин бүредән курыкмыйм, – дип кычкыра.

Чабаннар Ярtыга карыйлар да көләргә тотыналар:

– Сиңа бүре белән түгел, чебен белән көрәшергә кирәк, – диләр.

Ләкин малай аның саен даулый:

– Атны чабышта сына, егетне сугышта сына. Сез мине эштә сынап карагыз! – ди.

Чабаннар көтүләре янына кайтып китәләр, ә Ярты юлга әзерләнә башлый.

Тавыкның нечкә генә бер сөяген табып алып – җәя, кара куак чәнечкеләреннән ук ясый, ә сөңге итеп иске без ала.

Аннары карчыктан:

– Әни, миңа юлга тәбикмәк пешереп бир әле, – дип үтенә. – Мин явыз бүре белән сугышырга китәм, – ди.

Әнисенең аны шундый куркыныч җиргә бер дә җибәрәсе килми, ләкин Ярты бик ялына-ялвара торгач, җибәрергә була. Карчык улына тәбикмәк кенә түгел, сөт, май,

---

[1] *Ярты колак* – төрекмән әкиятләре герое, дөя колагының яртысы кадәр генә зурлыктагы малай.

йомырка салып тәмләтелгән камырдан катлама-катлама кабартма пешереп, аны каймак белән майлап бирә.

– Саклана күр, улым, син бит безнең бердәнберебез, йөрәк парәбез, шуны онытма. Сине югалтсак, без хәсрәттән үләрбез.

Ярты колак кабартманы йөзем яфрагына төреп әнисенә баш ия дә, үзенең күңелле җырын җырлый-җырлый, юл буйлап китеп бара:

Кечкенә дә, төш кенә,
Юллар ерак.
Дөя үтмәс җир була,
Аннан тычкан үтә ала.

Бүре эзен эзләп, ул комнар арасында бик озак йөри. Берзаман бу аның өстенә үк килеп чыга. Бүре саксауллар арасында шундый каты гырылдап йоклый, ди, аның тавышыннан агач яфраклары селкенә икән. Тик малай югалып калмый. Ул, шыпырт кына үрмәләп, бүренең янына ук килә дә, җәясен тартып, укларын бер-бер артлы җанварга атып бетерә.

Чәнечкедән ясаган уклар бүрегә зыян китерә алмыйлар, шулай да берсе борынына килеп тигәч, бүре уяна.

Ярты сикереп торып баса, сөңгесе белән кизәнеп, бүрегә:

– Әҗәлең килде, бәдбәхет! Мин – пәһлеван, чүлләр патшасы! Бирелергә боерам сиңа! – дип кычкыра.

Ләкин бүренең бирелергә исендә дә юк. Ул үлән арасыннан гайрәтле пәһлеванны хәтта күрми дә. Озынборын безелдидер дип кенә уйлый. Әмма Яртының биленә бәйләгән кабартмадан килгән тәмле ис бүрене сагаерга мәҗбүр итә. Җанвар аягүрә торып баса һәм, селәгәен агызып, авызын сөер итеп ача да бер кабуда тәмле кабартманы, ә кабартма белән бергә гайрәтле пәһлеванны да йотып җибәрә.

Ай-яй авыр була Яртыга бүре корсагында! Куркудан еларга җитешә бу, тик вакытында тыелып кала.

– Егет кешегә елап тору ярыймы соң! – дигән карарга килә малай. – Пәһлеван булган кеше бүре эченнән генә түгел, җир астыннан да чыгарга тиеш!

Ул, бар көчен җыеп, бүренең авызына якынрак килә, шуннан торыпниләр булганын күрмәкче була.

Ә бүре, йокысы туйгач, авызын зур ачып бер исни, аннан соң селкенгәләп ала да таныш сукмак буйлап көтүгә таба китә. Берәрсенең якынрак килүен сагалап, бүре әрем арасына кереп поса. Аннары арада бер симез сарыкны күзли дә, биек үләнгә яшеренеп, шуңа таба шуышып китә. Шундый сак шуыша инде менә, корсагы астында ком да кыштырдамый.

Әмма Ярты колак барын да күреп тора.

Бүре табышның өстенә сикерергә генә дигәндә, аның авызыннан:

– Әй, чабаннар, сарыкларыгызны саклагыз! Бүрене куыгыз!– дигән тавыш ишетелә.



Көтүчеләр дә, сикерешеп торып:

– Бүрене куыгыз! – дип тавыш күтәрәләр һәм этләрен ычкындырып, күсәкләр тотып, ерткыч җанвар артыннан ташланалар.

Бүре элдертә генә. Этләр аның артыннан чабалар. Алар артыннан көтүчеләр йөгерә, ә Ярты колак кычкыруын белә:

– Бирегә! Минем арттан калмагыз! Бу бүре саксауллар арасында яши. Үтерегез аны! – ди.

Бүре мең бәла белән качып котыла. Ул, этләр белән күсәктән дә бигрәк, үзенең эчендә кычкырган нәрсәдән курка. Аның гомердә дә мондый хәлгә төшкәне булмый.

Бүре шактый вакыт оясында ята. Тик ачлык аңа тынгы бирми. Ул төне буе күз дә йома алмый, ә иртәгесен, таң алдыннан, кояш чыккалаганчы һәм көтүчеләр уянгалаганчы дип, янә ауга китә.

Бу юлы да кире килә бит. Көтүгә якынлашуы гына була, тагын нәрсәдер моның авызыннан:

– Әй, чабаннар! Бүре килде! Көтүне саклагыз! – дип кычкыра.

Чабаннар тагын бүрене куып җибәрәләр.

Бүренең бәхетсез көннәре башлана. Ул көндезен дә, төнен дә көтү янына якын бара алмый. Оста күзәтче, далада көтү янында утырмыйча, үзеңнең эчеңдә утырсын әле, барырсың! Ярты колактан котылыр өчен бүре ниләр генә эшләми: сикерү дисеңме, җиргә ятып тәгәрәү дисеңме, ярсып-ярсып корсагының йонын йолку дисеңме, тик явыз күзәтче китми генә бит, ә Ярты:

– И бүреләрнең хакиме! Шул туймас корсагыңны ертмый торып миннән җаның тынмас синең! – дип, бүредән көлә.

Чабаннар чүл бүресенең кайда качып ятканын белеп алалар да, халыкны җыеп, аны ауларга китәләр.

Куәтле ташкындай, аучылар ком чүле буйлап йөгерәләр. Куа килгәнне ишетеп, бүре сызарга чамалый. Ул җан-фәрманга чаба, сусыз арык тармакларына поса, ләкин этләр аны кузгата. Ул барханнарга ышыклана, комга күмелә, тик кая гына бармасын, барыбер табалар. Бүре хәлдән тая, ләкин ул хәйләкәр була: тота да бер ташландык коега сикерә һәм шул кое төбенә чөмәшә. Чабаннар, аның эзеннән язып, өйләренә кайтып китмәкче булалар. Ләкин Ярты колак йокламый, адымнар ераклаша башлаганны ишетүе була, бүре авызыннан:

– Әй, күршеләр, кая киттегез?! Ул явыз биредә ята! Ул кое төбенә төшеп яшеренде! – дип кычкырып җибәрә.

Кешеләр кое янына киләләр дә бүрене тотып үтерәләр. Бу – чүлдәге иң зур бүре булган икән.

Карт чабан бүренең тиресен тунагач, бүре эченнән Ярты колак килеп чыга.

Бар кеше хәйран кала. Ә Ярты колак:

– Сау гынамы, абзый! Күрдеңме инде, сүземдә тордым бит! – ди.

Чабан аңа:

– Дөрес әйтәсең, олан, сүзеңдә тордың, – дип җавап кайтара. Аннары, авыл халкына таба борылып: – Бу егет көне-төне безнең малларны саклаган һәм ул безне явыз ерткычтан коткарды. Бүләк итеп үзенә иң көр биш тәкәне бирергә кирәк! – ди.

Шул кичне Ярты колак әтисенең өенә иң көр биш тәкәне куып кайта, ә үзе һаман күңелле җырын җырлый икән:

Кечкенә дә, төш кенә,
Кечкенә генә тычкан
Бар җиргә үтеп керә!

Карт белән карчык улларының кайтып килүен, өстәвенә тагы шуның чаклы бүләк алып кайтуын күреп, әйтеп бетергесез куаналар.

Без дә куаныйк!



# Мал, да удал

Прибежали в аул пастухи-чабаны и давай кричать:

– Помогите, соседи! Повадился ходить в стадо степной волк – каждый день по барашку уносит! Мы ставили капканы, но он не пошёл в капкан, потому что хитёр. Мы рыли ямы, но в яму он не попал, потому что умён. Мы все вместе ходили в засаду, но не убили волка, потому что он очень силён и ловок, а такого большого мы никогда не видали. Пойдёмте убьём его!

Покачали головами дехкане:

– Нам ли идти на волка, если чабаны и те не могут с ним справиться?

Развели руками и разошлись.

А Ярты-гулок[1] всё слыхал. Как раз в это время он сидел на стене-дувале и заплетал свои тугие косички.

– Эй, чабаны! – звонко крикнул Ярты пастухам. – Возьмите меня охранять стадо. Я волка не испугаюсь.

Чабаны глянули на Ярты-гулока и принялись хохотать:

– С мухой тебе сражаться, а не со страшным зверем!

Но мальчик не унимался:

– Конь виден на скачках, а джигит-молодец – в бою. Испытайте меня на деле!

Чабаны ушли к своему стаду, а Ярты стал собираться в дорогу.

Он согнул себе лук из тонкой куриной кости, сделал стрелы из острых колючек тёрна, а вместо копья взял старое шило. Потом он стал просить старуху:

– Испеки мне, мать, чурек на дорогу. Я иду сражаться со страшным волком.

Мать не хотела отпускать сына в такую опасную дорогу, но Ярты-гулок так её просил, так приставал, что она уступила. Она испекла сыну не простой хлеб-чурек, а сдобную слоёную лепёшку и помазала её сверху каймаком (сметаной).

– Будь, сынок, осторожен и помни, что ты у нас один, как сердце в груди. Без тебя мы умрём от горя. – Так сказала старуха сыну на прощание.

Ярты-гулок завернул лепёшку в лист винограда, поклонился матери и зашагал

[1] *Ярты-гулок* – персонаж туркменских сказок, мальчик размером с пол-уха верблюда.

по дороге, напевая весёлую песню. Он очень долго бродил по пескам, разыскивая следы волка, и, наконец, увидел его в зарослях саксаула. Волк спал и храпел так громко, что листья на деревьях дрожали. Но мальчик не испугался. Он подкрался к волку, натянул свой лук и одну за другой спустил в зверя все свои стрелы.

Стрелы-колючки не могли навредить волку, но одна стрела угодила ему прямо в нос, и волк проснулся.

Ярты-гулок вскочил на ноги, замахнулся на волка своим острым копьём-шилом и закричал:

– Пришёл твой последний час! Я – могучий пехлеван[1] и владыка пустынь – приказываю тебе сдаться!

Но волк и не подумал сдаваться. Он даже не заметил в траве могучего пехлевана. Ему показалось, что это просто пищит комар. Но запах сдобной лепёшки, которую Ярты привязал к своему поясу, заставил волка насторожиться. Зверь поднялся на ноги, ощетинил шерсть, разинул пасть, облизнулся и одним духом проглотил сдобную лепёшку, а вместе с ней и могучего пехлевана.

Ой, плохо пришлось Ярты в волчьем брюхе! Чуть не заплакал малыш от испуга, но вовремя спохватился.

– Плакать молодцу не к лицу! – решил мальчишка. – Настоящий пехлеван не то что из брюха, из-под земли выйдет на свободу!

Он собрал все свои силы и стал пробираться поближе к волчьей пасти, чтобы видеть, что будет дальше.

А волк выспался, зевнул, отряхнулся и знакомой тропой побежал к стаду. Скоро он увидел овец. Он притаился в кустах полыни и стал выжидать, чтобы добыча сама подошла поближе. Потом он наметил себе самую жирную овечку и пополз к ней, хоронясь в высокой траве. Он полз так тихо, что даже песок не шуршал у него под брюхом.

Но Ярты-гулок всё видел.

Когда волк хотел уже прыгнуть и схватить добычу, из волчьей пасти раздался громкий крик:

– Эй, чабаны, берегите баранов! Гоните волка!

Пастухи вскочили и тоже закричали:

– Гоните волка!

Они спустили собак и с палками бросились за зверем.

Волк побежал. Собаки за ним. За собаками пастухи. И Ярты-гулок всё кричал и кричал:

– Сюда! За мной! Этот волк живёт в зарослях саксаула! Убейте его!

Насилу волк унёс ноги. Он не так испугался собак и палок, как того, что кто-то в нём сидит и кричит. Такого с ним ещё никогда не бывало!

---

[1] *Пехлеван* – богатырь.

Волк долго отлёживался в своём логовище. Но голод не давал ему покоя. Он не мог заснуть всю ночь, а под утро, пока ещё не взошло солнце и пастухи ещё крепко спали, серый снова пошёл на охоту.

На этот раз волку тоже не повезло. Когда он подошёл к стаду, кто-то опять закричал у него из пасти:

– Эй, чабаны! Волк здесь! Берегите стадо!

И пастухи опять прогнали зверя.

Для волка настали чёрные дни. Ни днём ни ночью он не мог подойти к стаду. Попробуй-ка подойди, если зоркий сторож сидит не в степи у стада, а в твоём собственном брюхе! Что только ни делал волк, чтобы избавиться от Ярты-гулока: он прыгал и катался по земле, он рвал в бешенстве шерсть на своём брюхе, но дерзкий сторож не уходил и смеялся над ним:

– О, премудрейший из волков! Разорви скорей своё ненасытное брюхо, вот тогда я тебя оставлю в покое!

Пастухи-чабаны узнали, где хоронится степной волк, и повели народ в облаву на зверя. Как могучий горный поток, помчались охотники по пескам пустыни. Волк услышал погоню и побежал. Он бежал изо всех сил, он прятался в руслах сухих арыков, но его поднимали собаки. Он хоронился за барханами, зарывался в песок, но везде его настигала погоня. Волк обессилел, но он был хитёр: он прыгнул в заброшенный колодец и притаился на дне. Чабаны потеряли след зверя и повернули к дому. Но Ярты-гулок не дремал: как только он услыхал, что топот погони стал удаляться, он крикнул из пасти волка:

– Эй, соседи, куда вы?! Разбойник здесь! Он прячется на дне колодца!

Люди повернули к колодцу, нашли волка и убили его. Это был самый большой волк во всей пустыне.

Старый чабан снял с него шкуру, и Ярты-гулок выскочил из волка.

Все очень удивились, а мальчик сказал:

– Здравствуй, чабан! Теперь ты видишь, что я сдержал своё слово!

Чабан ответил:

– Верно, ты сдержал своё слово, малыш.

Он повернулся к дехканам и прибавил:

– Этот джигит день и ночь охранял наши стада и избавил нас от страшного зверя. Дадим ему в награду пять лучших баранов.

В этот вечер Ярты-гулок гнал к дому своего отца пять самых лучших курдючных баранов и напевал свою весёлую песню:

Я мал, да удал.
Маленький мышонок
всюду проскочит!

Старик и старуха очень обрадовались, когда увидали своего сыночка, да ещё с такой наградой. И мы тоже будем радоваться!

# Кокорикок

Төлке урман буйлап бара икән, каршына әтәч очраган. Кикриге тарак, койрыгы урак, сары күлмәкле, култык астына үрелгән кәрзин дә кыстырып җибәргән – карап кына тормалы инде!

«Их, монда гына тотып ашар идем, кеше йөреп тора. Күрсәләр, җаныңны алырлар. Өйгә хәйләләп чакырыйм әле, анда рәхәтләнеп тамак туйдырырмын».

– Исәнме, әтәчкәй, – ди ул. – Күптән синең белән дуслашасым килеп йөри иде. Мин Куз-Быж – озын койрык. Ә синең исемең ничек?

– Минеке – Кокорикок, – дип җавап бирә әтәч.

– Кокорикок, кая барасың? – дип сорый төлке.

– Базарга, борчак алырга.

– Базардан кайтканда миңа кунакка кер, – ди төлке.

– Ярар, Куз-Быж, керермен, – ди әтәч, ә үзе «синең белән дус булсаң, гомереңнән колак кагарсың» дип уйлый.

– Көтәрмен, – ди төлке, – әй, исемеңне оныттым бит. Кем дидең әле?

– Онытылмасынга язып куйыйм, алайса, – дип, әтәч төлкенең маңгаена «Аю» дип яза да китеп бара.

Төлке кайта да көтә башлый, көтә-көтә көтек була. Әтәч юк бит инде. Иртәгесен бик ачуланып уяна да әтәчне эзләргә чыгып китә. Барганда, моңа бүре очрый: «Болай иртә кая киттең, төлке?» – дип сорый ул. – «Ялганчыны эзлим! Исеме, менә, маңгаема язылган». Бүре карый: төлкенең маңгаена «Аю» дип язылган: «Нигә кирәк ул сиңа?» – дип сорый бүре. – «Өзгәләп ташлыйм!» – «Аюны да өзгәләп ташларлык булгач, мине нишләтмәс бу!» дип уйлаган да, бүре алдын-артын карамый чапкан. Шул арада урман куелыгыннан аю килеп чыккан.

– Төлке, нишләп йөрисең болай иртән иртүк? – дип сораган ул.

– Әй, менә моны эзлим! – дип, маңгаен күрсәткән ул аюга.

– Нигә соң ул сиңа?

– Өзгәләп бетерәм!

Аю ачуланып үкергән, акырган, төлкене койрыгыннан эләктереп алган да куак арасына ташлаган. Төлке каен төбенә бәрелгән. Исенә килгәч, торып өенә титаклаган. Әтәч турында да оныткан.



УДМУРТСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Кокорикок

Идёт рыжая лиса по дороге, а навстречу ей петух. Да такой красавец – хвост серпом, гребень пилой, рубаха на нём жёлтая, а под крылом плетёная корзиночка.

Увидела лиса петуха и подумала: «Эх, съела бы его сейчас, пёрышка бы не оставила. Да боюсь: люди по дороге ходят, увидят – несдобровать мне тогда. Заманю-ка его к себе домой, там с ним разделаюсь без помехи».

– Здравствуй, петушок, – говорит лиса сладким голосом. – Давно мне хочется с тобой подружиться. Меня зовут Кузь-Быж – Длинный хвост. А тебя как?

– А меня Кокорикок, – отвечает петух.

– Далеко ли ты, Кокорикок, собрался?

– Да вот на базар иду, надо бы горох купить.

– Как пойдёшь с базара, так заходи ко мне в гости, – приглашает лиса. – Угощу тебя на славу.

– Ладно, Кузь-Быж, приду, – пообещал петух, а про себя подумал: «С тобой дружить – живым не быть».

– Ну, так я тебя ждать стану, – облизнулась лиса. – Ой, как тебя зовут-то, дружок? Я уж и забыла!

– Давай запишу для памяти. – Петух поднял с дороги уголёк и написал у лисы на лбу: «Медведь».

Ушла лиса, а петух поглядел ей вслед и побежал домой, покуда цел.

Лиса пришла домой, села на лавочку, стала гостя поджидать, в окошко поглядывать. Уже свечерело, а петуха всё нет. Ждала-ждала лиса, так у окошка и заснула.

Утром проснулась голодная и злая-презлая. «Ну, – думает, – обманул меня петух. Теперь я его, как только встречу, на клочки разорву!»

Побежала лиса искать петуха. Бежит она по лесной чаще, а навстречу ей волк:

– Куда это ты, лиса, собралась так рано?

– Да вот ищу обманщика... Тьфу, имя его забыла! Погляди-ка, оно у меня на лбу написано.

Глянул волк, а у лисы на лбу написано: «Медведь».

– А зачем он тебе? – спросил волк.

– Хочу его на клочки разорвать!

Испугался волк. «Уж если она медведя собирается на клочки разорвать, то меня и вовсе целиком проглотит!» – подумал он и убежал без оглядки.

Тут из чащи вылез медведь.

– Здорово, лиса. Ты чего поднялась в такую рань?

– Да вот ищу... Тьфу, имя его забыла! Погляди-ка, оно у меня на лбу написано.

Медведь видит, что у лисы на лбу написано: «Медведь», спрашивает:

– А зачем он тебе?

– Хочу его на клочки разорвать!

Рассердился медведь, заревел, зарычал, схватил лису за длинный хвост и забросил в кусты. Стукнулась лиса о берёзовый пень, едва на ноги поднялась и, охая, заковыляла к себе домой. А про петуха уж и думать забыла.



# Янчык

Яшәгән, ди, булган, ди, бер ир белән хатын, аларның ике үгезләре булган. Берзаман хатын үзенең иренә:

– Сат үгезләрне! Ат сатып алырбыз, кая барасыбыз килсә, шунда барырбыз, – ди икән.

Шуннан ир үгезләрне ашатып эчергән дә алып киткән. Юл буйлап барганда, боларны бер атлы кеше куып җиткән.

– Исәнме!

– Исәнме!

– Үгезләрне кая алып барасың?

– Сатарга.

– Атка алыштыр үгезләреңне!

– Әйдә.

Үгезләрен атка алыштырган да юлын дәвам иткән бу. Бара торгач, моңа сыер җитәкләгән кеше очраган. Исәнләшкәннәр. Теге сорый ди:

– Атыңны кая алып барасың?

– Базарга үгезләр сатарга алып бара идем, атка алыштырдым.

– Атыңны сыерга алыштыр!

– Әйдә.

Алыштырганнар. Киткән ир сыерны җитәкләп. Бара торгач, моңа дуңгыз җитәкләгән кеше очрый.

– Сыерны кая алып барасың? – дип сорый бу кеше.

– Базарга үгезләр сатарга барган идем, атка алыштырдым, ә атны сыерга.

– Сыерыңны дуңгызга алыштыр!

– Әйдә.

Ул бу дуңгызны куалап килгәндә, моңа сарык җитәкләп баручы очрый. Исәнләшәләр болар.

– Дуңгызыңны сарыкка алыштыр! – ди теге кеше.

– Әйдә, – ди бу.

Сарыкны куалап китә. Караса, берәү каз алып бара. Сөйләшеп китәләр.



– Сарыгыңны казга алыштыр! – ди каз иясе. Бу моңа да риза була.

Казны алып, юлын дәвам итә. Караса, берәү әтәч алып бара. Сүзгә керешеп китәләр.

– Казыңны әтәчкә алыштыр! – дигәч, казны әтәчкә алмаштыра.

Әтәчне берәүнең юлдан тапкан буш янчыгына алыштыра.

Крестьян янчыкны яшерә дә базарга юл тота. Шәһәргә килеп җитә – паром белән елга аша чыгарга кирәк, ә аның түләргә акчасы юк.

Паромчылар моңа:

– Шул янчыкны булса да бир, – диләр.

Ә бер читтә олаучылар басып тора икән. Алар, бу янчыкның каян килүен белгәч, тотынганнар көләргә:

– Моның өчен хатының бирә инде сиңа кирәгеңне!

– Ярый үзең исән-сау әйләнеп кайткансың дип шатланыр әле, – ди бу.

Алар кулга кул сугып бәхәсләшәләр. Әгәр хатын шулай дисә, олаучылар атарбасы, камчысы белән унике йөк бирергә булалар. Шунда ук моның хатыны янына бер олаучыны җибәрәләр.

Менә ул хатын янына барып җитә. Исәнләшәләр. Олаучы:

– Ә син картың турында берни дә белмисеңме? – дип сорый.

– Юк, белмим.

– Ул үгезләрен атка алыштырган.

– Яхшы булган, арба кыйммәт түгел, ничек тә тырышырбыз.

– Атны да сыерга алыштырган.

– Тагын да яхшы, сөтебез булыр.

– Сыерны дуңгызга алыштырган.

– Анысы да яхшы, дуңгыз балаларыбыз булыр.

– Дуңгызын сарыкка алыштырган.

– Анысы да яхшы, бәрәннәребез дә йоныбыз да булыр, йон эрләрмен.

– Сарыгын казга алыштырган.

– Анысы да шәп! Мамыгыбыз да, каурыебыз да булыр.

– Казын да әтәчкә алыштырган.

– Бөтенләй яхшы булган, әтәч иртүк кычкырыр, безне эшкә уятыр.

– Әтәчен янчыкка алыштырган.

– Бик тә яхшы: кем булса да – улмы, минме йә балаларыммы акчаны янчыкка җыя барырбыз.

– Ул су аша чыгарган өчен янчыгын да бирде.

– Бирсен, исән-сау әйләнеп кайтуына шатланырга кирәк.

Шулай итеп, олаучылар бу кешегә камчысы-ние белән унике олау йөкне бирергә мәҗбүр булганнар.

# Кошелёчек

Жили себе муж и жена, и была у них пара волов, а у соседей повозка. Вот как подойдёт, бывало, воскресенье или праздник какой-то, и берёт себе кто-нибудь из них волов и повозку и едет в церковь или в гости, а на следующее воскресенье – другой, так между собой и делились.

Вот раз баба и говорит старику, чьи волы были:

– Отведи волов на базар и продай, а мы себе купим лошадей и повозку, будем сами по воскресеньям в церковь и к родичам ездить. Да и то сказать – ведь сосед свою повозку не кормит, а нам приходится кормить.

Накинул старик верёвку волам на рога и повёл. Ведёт по дороге, догоняет его человек на коне.

– Здорово!

– Здорово!

– А куда ты волов ведёшь?

– Продавать.

– Променяй мне волов на коня.

– Давай!

Променял он волов на коня, едет на коне. А тут навстречу ему ведёт человек на ярмарку корову. Поздоровались.

– А куда это ты едешь?

– Вёл я на ярмарку волов продавать, да на коня променял.

– Променяй мне коня на корову.

– Давай!

Поменялись. Ведёт он корову, а тут человек свинью гонит. Поздоровались.

– А куда это ты корову ведёшь?

– Да вёл я на ярмарку волов, да на коня променял, а коня на корову.

– Променяй мне корову на свинью.

– Давай!

Гонит он свинью, а тут человек ведёт овцу. Расспросили друг друга.

– Променяй свинью на овцу.

– Давай!

Гонит уже дед овцу, а тут человек несёт продавать гусыню. Расспросили друг друга.

– Променяй овцу на гусыню.

– Давай!

Прошёл дед немного с гусыней, несёт человек петуха. Разговорились.

– Променяй гусыню на петуха.

– Давай!

Несёт дед петуха, а тут нашёл человек на дороге пустой кошелёчек. Разговорились.

– Вот нашёл я кошелёк, променяй петуха на кошелёчек!

– Давай!

Спрятал дед кошелёк, идёт себе на ярмарку. Подходит к городу – надо переезжать реку на пароме, а ему за перевоз заплатить нечем. Перевозчики ему говорят:

– Дашь хоть этот кошелёк, то перевезём.

Отдал он.

А стоял там чумацкий обоз. Как узнали у него чумаки, за что он выменял кошелёчек, стали над ним смеяться.

– Что тебе, – говорят, – жинка за это сделает?

– Да ничего! Скажет: «Слава Богу, что хоть сам живой воротился».

Вот и побились они об заклад: коли скажет жена так, отдадут ему чумаки все двенадцать гружёных возов да ещё с батогами в придачу. Выбрали одного из обоза и послали к его старухе.

Вот приходит он.

– Здравствуйте!

– А ты про своего старика слыхала?

– Нет, не слыхала.

– Да он волов на коня променял.

– Вот хорошо! Волы недорого стоят, как-нибудь и соберёмся купить.

– Да и коня променял на корову.

– Это ещё лучше: будет у нас молоко.

– Да и корову на свинью променял.

– И то хорошо: будут у нас поросяточки, а то как заговенья или разговенья, всё покупать приходится.

– Да и свинью на овцу променял.

– И то хорошо: будут у нас ягняточки да шёрсточка, будет мне что в спасовку прясть.

– Да и овцу променял на гусыню.

– И то хорошо: будут у нас крашенки и перья.

– Да и гусыню на петуха променял.

– О, это ещё лучше! Будет петушок по утрам петь, нас на работу будить.

– Да и петуха на кошелёк променял.

– И это хорошо. Как кто что заработает – он, или я, или дети, – в кошелёк складывать будем.

– Да он и кошелёк-то за перевоз отдал.

– Ну что ж, слава Богу, что хоть сам живой воротился.

Вот чумакам и нечего делать – отдали они старику все двенадцать возов.



# Зөмрәт белән Кыйммәт

Чокыр янында бер кечкенә генә йорт булган. Анда ир белән хатын яшәгән, икесенең дә берәр кызы булган: берсе – Зөмрәт, берсе – Кыйммәт исемле икән.

Хатын үз кызы Кыйммәтне бик яраткан, ә үги кызы Зөмрәтне күралмаган: орышкан да, кыйнаган да, иртәннән кичкә кадәр эшләткән, бер минут та тик тотмаган.

Ачуы килерлек тә шул, Зөмрәт бик матур, бик акыллы кыз булган, бер сөйләшкән кеше сөйләшеп, бер күргән кеше күреп туймаслык икән. Ә хатынның үз кызы Кыйммәт ялкау, үзсүзле, гаугачыл, ди, көне буе сукранып, сөйләнеп йөрүдән башы чыкмый икән.

Зөмрәт иртән торып чишмәгә барганда, чәчәкләр, башларын иеп, аның белән исәнләшәләр, хәл җыярга утырса, аңа елышалар, сандугачлар килеп әкиятләр сөйлиләр икән. Ә Кыйммәтне яратмаганнар, чөнки кыз аларны таптый, өзә икән. Шуңа күрә, яннарыннан Кыйммәт узып киткәндә, чәчәкләр йомыла, кача, ди.

Хатынның моңа бик тә ачуы килә икән, ул ничек тә Зөмрәтне юкка чыгару турында уйлый башлаган.

Беркөнне ул иренә әйткән:

– Кызың ялкау, тыңлаусыз, теләсәң ни эшләт, монда эзе дә булмасын, – дигән.

Ир аптырап калган, инде нишләргә?

– Урманга илтеп адаштыр, йә мин, йә ул, – дип шарт куйган хатыны.

Шулай итеп, әтисе Зөмрәтне тауларга алып чыгып киткән. Ешкынлыклар буйлап бик озак барганнар алар. Барып җиткәч, әтисе:

– Кызым, син шушында булырсың, мин агач кисәм, – дип, агачлыкка кереп киткән.

Зөмрәт үзе генә калган. Ул арада җил чыккан, кызга әтисенең тук-тук итеп агач кискән тавышы ишетелеп тора, ди.

Кыз бик озак утырган, инде караңгылана башлаган. Кыз, әти ник һаман килми соң дип, балта тавышына барып караса, агач башында эленеп куелган балта җилдә чайкала, үзе «тук-тук» дигән тавыш чыгара, ди.

– И бәхетсез башкайларым! Әтекәем, – дип кычкыра-кычкыра кыз әтисен эзләп



киткән. Йөри-йөри адашкан. Кая барырга белми елый икән мескен. Шулай йөргәндә, бер сукмакка килеп чыга кыз. Бара икән, аңа чәчәкләр нидер пышылдый, кошлар сайрап озата.

Бик озак барган Зөмрәт. Берзаман еракта бер ут күрә дә шуңа турылап китә. Барып караса, кечкенә генә бер өй тора, ишегалдында эт өрә, тәрәзәдән өйдә бер әби утырганы күренә, ди. Зөмрәт, сөенеп, өйгә керә, әби белән исәнләшеп, аңа башыннан үткәннәрне сөйләп бирә. Әби ни җитте әби генә түгел, урман иясе икән.

– Борчылма, кызым, – ди ул, – мин сиңа булышырмын.

– Рәхмәт яусын, – дип җавап бирә Зөмрәт, – сез мине әнием шикелле кабул иттегез. Әйтегез генә, ни эшлисе бар, мин сезгә булышам.

Ул арада өй кырыена сайрар кошлар, очып килеп, кызны мактап җырлый башлаган. Урман иясе аларны аңлап сөенгән, Зөмрәткә, «күзем карасы», «назлыкаем» диеп кенә тора, курчак уйнарга, китаплар карарга рөхсәт итә, әкиятләр сөйли икән. Зөмрәт тә уйнап кына ятмаган, әбинең бөтен йорт-җирен юып ялт иттергән. Бәләкәй генә өй фарфор касә шикелле балкып тора, ди.

Беркөнне карчык пылау пешерергә җыенган:

– Кызым, бар әле, чормадан утын алып төш, – дигән ул.

Өй түбәсе бик биек икән, аннан бөтен җир күренеп тора, ди. Зөмрәт еракта үз өйләрен күреп алган да елап җибәргән.

Күзләре кызарган кызны күреп, әби:

– Нигә елыйсың, балакаем? – дип сораган.

– Үзебезнең өйне күрде-е-е-ем. Әткәемне сагынды-ы-ым, – дип сузган кыз.

Әби аны тынычландырган, пылау ашатып, йокларга яткырган. Иртәгесен әйтә икән:

– Әйберләреңне җый, кызым. Бүген өеңә кайтырсың. Чормада ике сандык бар: берсе – ак, берсе – кызыл. Агына тимә, кызылын ал.

Әби шулай дигән дә, урманга чыгып, арбага ат җиккән. Зөмрәтне атка утыртып, озатып калган.

– Менә сиңа ачкыч, өеңә кайткач, сандыгыңны ачарсың.

Зөмрәт, әбигә рәхмәтләр укып, кайтыр юлга кузгалган. Күз ачып йомганчы кайтып та җиткән. Күтәрелеп караса, капка төбендә әтисе утыра, үзе бик моңсу, ди.

– Әтием, мин кайттым! – дип, Зөмрәт аның кочагына атыла.

Өйгә кереп, сандыкны ачып карасалар, ни күзләре белән күрсеннәр: алтын-көмеш тә асылташлар, кызның бөтен гомеренә җитәрлек, ди.

Моны күргән үги ананың йөрәге яна башлаган. Зөмрәтне тыңлап бетергәч, ул иренә Кыйммәтне урманга илтеп калдырырга кушкан.

Шулай эшләгәннәр дә. Кыйммәт, урманда берүзе генә калгач, бик курыккан, ләкин аңа кошлар да, чәчәкләр дә ярдәмгә килмәгән шул, бары тик урманда ябалак ухылдаганы гына ишетелә, ди.

Кыйммәт тә теге өйгә барып җиткән. Урман иясе булган әби аны да ачык йөз белән каршылаган. Тик Кыйммәт кенә әбигә рәхмәт әйтә белмәгән, гомумән, әнисе

рәхмәт әйтергә өйрәтмәгән. Урман иясе дә, кызга үпкәләп, курчаклар да бирмәгән, әкият тә сөйләмәгән.

Кыйммәт иртәдән кичкә кадәр өйдә тик утыра, өй җыештырмый, әбигә булышмый, ди. Өй эче тузанга баткан, тәрәзәләр пычранып беткән.

Беркөнне әби Кыйммәткә чормадан утын алып төшәргә кушкан. Кыйммәт:

– Үзең алып төш, мин сезгә хезмәтче түгел, – дип җавап биргән.

Шулай да, әби үгетли торгач, менеп киткән кыз. Чормага менгәч, өйләрен күреп алган да елый башлаган.

Әби сорый икән:

– Нигә елыйсың?

– Өебезне күрдем, кайтып китәм мин, – дип аяк тибә икән.

– Ярар, бар соң, – дигән әби. – Чормадагы сандыкны да үзең белән алсаң була. Менә ачкычы, кайтып җиткәч, ачарсың.

Кыйммәт елаудан туктаган, шатланып, өенә җыена башлаган, сандыкны да алып төшкән. Тылсымчы карчык ат-арба җигеп озатмагач, Кыйммәткә сандыкны өстерәп кайтырга туры килгән.

Кыйммәтләрнең этләре кызның кайтуын сизеп өрә икән:

– Һау-һау-һау, Кыйммәт кайта, сандыгына елан тутырып кайта!

Хатын, ачуы килеп, этне таяк белән кыйный башлаган.

– Юкны сөйләмә, кызым өфәк-бәрхет алып кайта!

Кыйммәтнең кайтып килүен күреп, күрше-тирә җыелган, сандыкта ни барын беләселәре килә, ди. Кыйммәт белән әнисе сандык өстенә утырганнар да сандыкка беркемне дә якын китермиләр икән.

Төн уртасында ишекләрне бикләп бетереп, сандыкны ачып карасалар, анда ике олы аждаһа утыра, ди.

– Ай-вай, коткарыгыз! Аждаһа!

Аждаһаларның берсе – Кыйммәтне, икенчесе аның әнисен йотканнар да, тәрәзәдән очып чыкканнар да киткәннәр.

Тавышка йөгереп килгән күршеләре ишекне ватып керсәләр, өйдә беркем дә юк, ди. Явыз үги ана белән аның гаугачыл кызын беркаян да таба алмаганнар. Ә Зөмрәт әтисе белән тынычлап рәхәтләнеп яшәгәннәр, ди.



УЗБЕКСКАЯ НАРОДНАЯ СКАЗКА

# Зумрад и Киммат

На краю оврага стоял маленький домик. Жили в домике четверо: старик со своей дочерью Зумрад и жена старика со своей дочерью Киммат.

Старуха свою родную дочь Киммат любила, а падчерицу Зумрад ненавидела. Бедную Зумрад она и била, и ругала, с утра до вечера работать заставляла, ни минуты покоя ей не давала.

А Зумрад была девочка красивая, приветливая, умная. Увидишь её – сколько ни смотри, не наглядишься; заговоришь с нею – сколько ни говори, не наговоришься.

Киммат была совсем на неё не похожа: ленивая, капризная, неприветливая. Целыми днями она ворчала, сердилась и ссорилась.

Зумрад, бывало, рано утром встанет и бежит к роднику, тюльпаны головки свои склоняют, ей «здравствуй!» говорят. А если Зумрад иногда на траву отдохнуть присядет, и цветы, и соловьи радуются, сказки ей напевают.

Старухину дочь цветы не любили, не ласкали. Киммат обижала их: рвала, ногами топтала. Поэтому, когда Киммат проходила, цветы от неё прятались, лепестки свои закрывали.

Всё это ещё больше злило старуху-мачеху. Стала она думать, как бы ей Зумрад со свету сжить.

Однажды мачеха сказала старику:

– Дочь твоя непослушная, лентяйка, прогнать её надо – не то духу моего здесь не будет.

Растерялся старик и не знает, что ему делать. А старуха не унимается, требует:

– Отвези Зумрад в лес и сделай так, чтобы она заблудилась. Вместе с ней жить я не буду.

Повёл старик Зумрад в горы. Долго шли они горами да ущельями, зашли в такую глушь, где нога человека не ступала.

– Посиди здесь на камне, доченька, – говорит старик, – а я пойду дров нарублю.

– Ладно, батюшка, – отвечает девочка. Пошёл старик дрова рубить.

Зумрад одна осталась.

Вдруг поднялся ветер. Старик повесил топор на большое дерево. Ветер дует – топор покачивается и стучит о дерево: «Тук-тук!»

А Зумрад думает, это отец дрова рубит, сидит.

Долго-долго она сидела, а отец не идёт. Когда ветер успокоился, пошла Зумрад в ту сторону, где топор стучал. Идёт она по долине, цветы собирает и вдруг видит: стоит дерево, на дереве топор висит, а отца нет.

– Ой, несчастная доля моя! Ой, батюшка! – закричала Зумрад.

Пошла Зумрад отца искать. Ходила Зумрад по горам, ходила и окончательно заблудилась.

Страшно ей стало одной в лесу. Куда идти – не знает, плачет Зумрад. Вдруг видит: узенькая тропинка. Пошла по ней Зумрад и слышит – голосистые птички поют. Под ноги посмотрит Зумрад – там цветы разноцветные: и красные, и белые, и жёлтые – головками кивают, что-то шепчут ей.

Вечер наступил, темно стало.

Долго-долго шла Зумрад. Цветы своими головками ей дорогу показывают. А время уже совсем позднее. Наконец заметила Зумрад, что вдали какой-то огонёк мерцает, прислушалась, слышит – собака лает. Пошла Зумрад в ту сторону и скоро подошла к маленькому домику. Заглянула в окно, видит – в домике старуха сидит. Зумрад обрадовалась, зашла в домик, поздоровалась со старухой и рассказала, что с ней случилось.

Обрадовалась старуха, что в дом к ней пришла такая приветливая девочка. А старуха та была добрая лесная волшебница.

– Не печалься, – утешает старуха Зумрад. – Я тебе помогу.

– Благодарю, – отвечает Зумрад. – Вы меня как родная мать приняли. Что вам нужно делать – скажите, я люблю работу, для вас охотно сделаю.

В это время на крышу старухиного домика прилетело много-много птиц. Птицы песни запели и в песнях своих Зумрад хвалили. Волшебница птичий язык понимала и ещё больше радовалась. Она Зумрад ласкала, «миленькая моя, бусинка моя!» называла, куклы играть ей давала, сказки рассказывала, такие интересные книжки показывала, каких нигде больше не найдёшь.

Так прожили они вместе несколько дней. Старуха ласкова была с Зумрад, потому что с её приходом старый домик заблестел, как фарфоровая пиала. Зумрад пол в комнатке подметала, окна мыла.

Однажды старуха собралась плов приготовить и говорит Зумрад:

– Поднимись, доченька, на крышу, достань дров.

– Ладно, бабушка, – отвечает Зумрад и полезла на крышу.

А крыша была высокая, далеко с неё во все четыре стороны видно. Зумрад поглядела по сторонам и увидела крышу своего родного домика.

Сильно забилось сердце у Зумрад, заплакала она.

– О чём плачешь, миленькая? – спрашивает старуха. – Вон вдали мой родной дом виднеется. Я по отцу соскучилась, – отвечает Зумрад и плачет.

Старуха её успокоила, плову наварила, покормила Зумрад, спать уложила, а поутру говорит:

– Собирай свои игрушки, бусинка моя. Сегодня домой поедешь. На крыше у меня два сундука стоят – красный и белый. Ты белый сундук оставь, а красный с собой возьми.

Сказала так старуха и в лес пошла. Зумрад стала своих кукол собирать. Привела старуха буланого коня, запряжённого в арбу, посадила на арбу Зумрад, поставила красный сундук и говорит:

– Вот тебе ключик от сундука, когда домой приедешь, сундук откроешь.

Попрощалась Зумрад со старухой, поблагодарила её и домой отправилась. Не успела она оглянуться, как арба уже перед родным домом остановилась.

Видит Зумрад – перед домиком отец сидит пригорюнившись, о дочке думает.

– Здравствуй, отец! – крикнула Зумрад и бросилась его обнимать.

Так обрадовался старик, что невольно из глаз у него слёзы потекли.

– Миленькая моя!..

Вошли они в дом. Скоро все узнали, что Зумрад домой вернулась. Соседи собрались. Зумрад красный сундук открыла. Все так и ахнули.

В красном сундуке полно всяких дорогих вещей оказалось. На всю жизнь добра для Зумрад хватит.

Увидев это, злая мачеха засуетилась, забеспокоилась. В тот же миг приказала старику отвести Киммат в лес и оставить там.

Старик быстро собрался и отвёл Киммат в лес.

Когда настал вечер, Киммат пришла к дереву, на котором старик повесил топор. Закричала Киммат, заплакала, но ни цветы, ни соловьи – никто её не стал утешать. Одни только совы кричали в тёмном лесу.

В страхе побежала Киммат по лесу и прибежала к домику волшебницы. Старуха её приветливо встретила, успокоила:

– Не печалься, доченька, я тебе помогу.

Но у Киммат не нашлось доброго слова старуху поблагодарить, потому что мать её и добрым словам не учила. Обиделась волшебница, и ни кукол Киммат не дала, ни сказок ей не рассказала.

Сидит Киммат с утра до вечера в домике, бездельничает, ленится, домик не убирает. Грязно стало в домике, окна пылью покрылись.

Однажды старуха говорит Киммат:

– Полезь, доченька милая, на крышу, достань дров.

– Полезайте и сами доставайте, – отвечает Киммат. – Я вам не служанка.

Старуха очень огорчилась, но всё же уговорила Киммат подняться на крышу. Залезла Киммат на крышу, но дров не берёт, сидит и плачет.

Старуха спрашивает:

– Чего ты плачешь?

– Я дом свой увидела. Уйду от вас, – отвечает Киммат и ногами топает.

– Ладно, иди, – говорит колдунья, – и сундук, что стоит на крыше, можешь с собой забрать. Вот тебе ключ. Дома откроешь сундук.

Киммат перестала плакать, обрадовалась, стащила сундук с крыши. Но волшебница арбы ей не дала. Пришлось Киммат тяжёлый сундук на себе тащить.

Почуяла пёстрая собака, что Киммат идёт, подбежала к старухе, лает:

– Гав, гав, гав! – и что-то себе под нос бормочет. Стала старуха прислушиваться, что собака бормочет, и слышит:

– Вот я к маме иду, на спине сундук несу, а в нём змей полно.

Разозлилась старуха, взяла длинную палку и как ударит собаку, ноги ей перебила. А потом с радостью думает: «Моя доченька идёт, шёлк, бархат несёт».

Прибрела наконец Киммат домой. Собрались соседи, хотят посмотреть, что там, в сундуке. А мачеха и Киммат сели на сундук, злятся, не позволяют сундук открывать.

Взяли мачеха с дочкой сундук за ручки и потащили в дом. А в полночь заперли они двери и открыли сундук да как закричат:

– Ой! Спасите! Драконы!

В сундуке два больших дракона сидели. Проглотили драконы старуху с её сварливой дочкой, вылезли через окно и улетели.

А соседи услышали крики и вопли в доме, побежали на помощь, разбили дверь и видят: никого в доме нет.

Так и не нашли нигде злую мачеху и её сварливую дочку. А старик и Зумрад после этого жили мирно и счастливо.



# Үзен үзе һәлак иткән

Бер зур гына кара урманда бик күптәннән бирле ике дус – антилопа белән козгын яшиләр икән. Көн саен иртә белән антилопа, якын-тирәдәге болында ашап йөргән, ә козгын, табыш эзләп, берәр авылга очып китә торган булган.

Шулай бервакыт, антилопа, ялгызы гына калгач, кинәт үзеннән ерак та түгел бер шакалны күргән.

– Исәнме, кадерле дус! Ниһаять, синең белән дә очрашасым бар икән! – дигән шакал.

– Кайдан беләсең син мине, кем буласың син? – дип сораган антилопа, гаҗәпсенеп.

– Синең козгын белән якын дус булуыңны бөтен урман белә, – дип җавап биргән шакал. Шуннан соң ул аягы белән күз яшьләрен сөрткән булып улап куйган: – Ә мин берьялгызым... Үзең белән дуслашырга рөхсәт итсәң иде.

Антилопа, шакалның сүзләренә ышанып:

– Ярый, мин синең белән дуслашырга каршы түгел. Әйдә, киттек икәү бергә, – дигән.

Ул шакалны үзе тора торган җиргә алып килгәч, козгын, аптырашта калып:

– Әйт әле миңа, дустым, юлдашың кем? – дип сораган.

– Бу – бичара шакал... Ул берьялгызы... ул да безнең дустыбыз булсын... – дигән антилопа.

– Ярый, булсын, – дип, аның сүзенә кушылган козгын.

Шуннан соң алар бергә тора башлаганнар.

Шакал белән антилопа еш кына икесе бергә калгалаганнар, андый вакытларда мәкерле шакал антилопаны ничек итеп ашау турында гына уйлый икән.

Бервакыт шакал антилопага:

– Сине шатландырырга уйладым әле мин, кадерле дустым, моннан ерак түгел



генә бер җирдә гаҗәп яхшы бодай уҗымы басуын күрдем. Әйдә тизрәк, киттек, шунда минем сиңа һәрвакыт изгелек теләвемә ышанырсың.

Бәла буласын башына да китермичә, антилопа шакал артыннан чапкан һәм, озак та үтмичә, ямь-яшел куе бодай уҗымын күргән.

– Ах, шакал, нинди яхшы дус син! – дип мактаган аны тиз ышанучан антилопа.

Шул көннән башлап, ул һәр көн басуга йөргән һәм яшь бодай уҗымы белән тукланган.

Эш нәкъ шакал уйлаганча булып чыккан. Басуның хуҗасы уҗымга хайваннар кереп йөрүен сизеп алган да шунда тозак корган. Бичара антилопа, аны күрмичә, элмәккә килеп капкан. Башта ул бик нык курыккан, соңыннан: «Зарар юк, хәзер шакал килеп җитәр дә мине ычкындырыр», – дип, үз-үзен юаткан.

Шулай дип уйлап бетерүгә, шакал да күренгән.

– Кадерле дустым, мин сине зарыгып көттем! – дип кычкырган антилопа. – Тизрәк бу җепне чәйнәп өз, мин тагын иректә булырмын!

Шакал ашыкмыйча гына тозак янына килгән дә, элмәккә күз төшереп:

– Син, антилопа, бүген минем туган көнем икәнлеген исеңнән чыгаргансың, ахры. Андый көнне минем беркайчан да эшләгәнем юк. Бераз сабыр ит, иртәгә мин яңадан монда килермен дә сине азат итәрмен... – дигән.

Шулай дип, ул ашыга-ашыга куаклыкка кереп качкан. Шунда яшеренгән шакал, кәефле генә итеп: «Бары да мин уйлаганча барып чыкты. Хәзер басу хуҗасы килеп җитәр, бу тинтәк антилопаны суяр, ите белән тиресен үзенә алыр, эче-бавыры миңа калыр...» – дип хыялланган.

Нәкъ шул вакытта басу өстеннән козгын очып бара икән. Дустының бәлагә очравын күреп, ул җиргә төшеп кунган һәм:

– Курыкма бер дә! Хәзер мин шакалны эзләп табармын, ул мондый элмәкне минут эчендә чәйнәп өзәр! – дип кычкырган.

– Юкка вакытыңны әрәм итмә, – дигән антилопа кайгылы кыяфәт белән. – Мин аннан ярдәм сорап карадым инде, ләкин ул ярдәм итүдән баш тартты. Хыянәтче шакал минем үлememне көтә!..

Шул арада козгын еракта кеше килгәнен күреп алган. Ул кешенең аркасында зур җәя асылынып тора икән.

– Үлгәнгә сабыш! – дип пышылдаган козгын антилопага. – Минем каркылдавымны ишеткәч, сикереп тор да бөтен көчеңә чап!..

Антилопа сузылып ятуга, кеше үзенең тозагы янына килеп тә җиткән. Үле антилопаны күреп, ул шатлыгыннан кычкырып ук җибәргән:

– Менә кем таптаган икән минем басуымны! Хәзер без бу җанвар тиресенең ниндилеген тикшереп карыйк!

Җәясен җиргә куеп, ул антилопа аягыннан элмәкне ычкындырган.

Пычагын чыгарып, уйлаган планын җиренә җиткерергә торганда гына, кинәт

аның баш түбәсенә козгын килеп кунган. Козгын бу кешенең баш түбәсен чукып алган да якындагы куакка таба очып киткән.

Кулына таяк алып, кеше кош артыннан йөгергән. Козгын тагын бераз арырак киткән дә бодайга төшеп кунган.

– Ах син, әшәке кош!– дип кычкырган әлеге кеше ачу белән. – Тукта әле, син миннән котыла алмассың!

Шул сүзләрен кычкыра-кычкыра, ул, козгынны таяк белән бәреп үтермәкче булып, басу уртасына кереп киткән.

Ләкин козгын кеше ыргыткан таяктан оста гына читкә тайпылган һәм каты итеп каркылдап куйган. Шунда ук антилопа сикереп торган да, бөтен көчен җыеп, ешлыкка кереп югалган.

Кеше, козгын артыннан куып, үз басуыннан ерак киткәнен сизмичә дә калган.

Шакал куаклар арасыннан башын тыгып караса, кешенең әллә кая китүенә бик нык гаҗәпсенгән. Кайда соң антилопа?

Тозак янына якын килгәч, шакал кеше калдырган җәягә барып төртелгән.

«Нишләмәк кирәк, – дип күңелсезләнгән шакал, – антилопаның эчен-бавырын ашап булмады, бүгенгә бу җәянең бавын ашап кына тамак ялгарга туры килә инде, ул бит сеңердән ясалган...»

Шулай уйлаган да бу, ачуланып, казык тешләре белән җәя бавын тешләп тарткан икән, бау өзелеп киткән, ә җәя, күз ачып йомганчы тураеп, бик каты көч белән шакалның башына китереп суккан. Шакал шунда ук җан биргән.

Хыянәтче, алдакчы шакал, башкаларга үлем әзерләп, үзен үзе шулай һәлак иткән.



# Сам себя погубил

В одном большом лесу издавна жили два друга – антилопа и ворон. Каждое утро антилопа паслась на ближнем лугу, а ворон улетал за добычей в какое-нибудь селение. И вот однажды, когда антилопа осталась одна, она вдруг увидела поблизости от себя шакала. Шакал сказал:

– Здравствуй, дорогой друг! Наконец-то я встретился с тобой!

– Откуда ты знаешь меня и кто ты такой? – спросила удивлённая антилопа.

– Весь лес знает о твоей прекрасной дружбе с вороном, – ответил шакал. И, сделав вид, что вытирает лапой слёзы, проскулил:

– Я совсем одинок... Позволь мне стать твоим другом. – Антилопа поверила словам шакала и сказала:

– Хорошо, я согласна быть твоим другом. Пойдём со мной.

Когда она привела шакала к своему жилищу, ворон удивился и спросил:

– Скажи мне, друг, кто твой спутник?

Антилопа ответила:

– Это бедный шакал... Он совсем одинок... Пусть он будет нашим другом...

– Пусть будет, – согласился ворон. И они зажили все вместе.

Часто случалось так, что шакал и антилопа оставались наедине, и тогда коварный шакал всё время думал только о том, как ему съесть антилопу.

И вот однажды он сказал ей:

– Хочу тебя обрадовать, дорогой друг: невдалеке отсюда нашёл я прекрасное поле молодой пшеницы. Поспешим туда, и ты убедишься, что я постоянно думаю о твоём благе.

Не чуя беды, антилопа побежала вслед за шакалом и вскоре увидела густое поле зелёной пшеницы.

– Ах, шакал, ты очень хороший друг! – промолвила доверчивая антилопа.

С этого дня она каждое утро приходила на поле и поедала молодые всходы пшеницы.

Как задумал шакал, так и получилось: хозяин поля увидел, что кто-то поедает его пшеницу, и поставил ловушку. Бедная антилопа не заметила ловушки и попала в

петлю. Сначала она очень испугалась, а потом подумала: «Не беда, сейчас придёт шакал и спасёт меня».

И только она так подумала, как увидела шакала.

– Дорогой друг, как я тебя ждала! – воскликнула антилопа. – Скорее перегрызи эту петлю, и я снова буду свободна!

Шакал не спеша подошёл к ловушке, посмотрел на петлю и сказал:

– Ты, верно, забыла, антилопа, что сегодня день моего рождения. Знай же, что в этот день я никогда не работаю. Потерпи немного: завтра я приду сюда и освобожу тебя...

Так сказав, он проворно убежал в кусты. Спрятавшись там, шакал радовался: «Всё получилось, как я хотел. Сейчас придёт человек, убьёт глупую антилопу, мясо и шкуру возьмёт себе, а потроха достанутся мне...»

В это время над полем пролетал ворон. Увидев в беде друга, он опустился на землю и воскликнул:

– Не бойся! Сейчас я найду шакала, он без труда перегрызёт такую петлю!

– Не трудись понапрасну, – сказала печально антилопа. – Я уже просила его помочь мне, но он не захотел. Коварный шакал ждёт моей смерти!..

И тут ворон увидел, что вдали показался человек. За спиной человека болтался большой лук.

– Притворись мёртвой! – шепнул антилопе ворон. – И как только я каркну, вскакивай и беги со всех ног!..

Едва антилопа успела растянуться, как человек уже был у ловушки. Увидев мёртвую антилопу, он радостно воскликнул:

– Так вот кто топтал моё поле! Сейчас мы посмотрим, что за шкура у этого зверя! – И, положив лук на землю, он снял петлю с ноги антилопы.

Вытащив нож, хозяин поля хотел уже приступить к задуманному делу, как вдруг на голову его опустился ворон. Ворон клюнул человека в темя, отлетел в сторону и сел на ближний куст.

Схватив палку, человек бросился к птице. Но ворон отлетел ещё на несколько шагов и опустился в пшеницу.

– Ах, негодная птица! – закричал сердито человек. – Погоди же, ты от меня не уйдёшь!

И, так воскликнув, он побежал в глубь поля, стараясь подшибить ворона палкой.

Но ворон ловко увернулся от палки человека, снова отлетел в сторону и громко каркнул. Тогда антилопа вскочила и понеслась что есть духу в лесную чащу.

Человек же, гоняясь за вороном, даже не заметил, как оказался вдали от своего поля.

Когда шакал выглянул из-за кустов, он очень удивился: куда делся человек? Почему не видно антилопы?

Подойдя к ловушке, шакал наткнулся на брошенный человеком лук.

«Что ж, – подумал огорчённый шакал, – раз не удалось попробовать потрохов антилопы, придётся сегодня утолить свой голод хоть тетивой этого лука – ведь она сделана из жил...» Подумав так, он злобно рванул клыками тетиву, тетива порвалась, лук мгновенно разогнулся и с такой силой ударил шакала по голове, что тот упал замертво.

Так, готовя гибель другому, подлый притворщик погубил сам себя.



# Бүре

Күптән инде, бик борынгы заманнарда җирдән бик көчле давыл узган. Диңгез һәм елгалар ярларыннан чыккан, таулар җимерелгән, агачлар төбе-тамыры белән кубарылып чыккан. Давыл бик күп бәхетсезлекләр китергән. Җир йөзендәге бөтен тереклек иясе, куркынычсыз урыннар эзләп табып, качып котылганнар. Давылдан бер бүре генә курыкмаган. Кыя өстенә менеп баскан да давыл белән бергә-бер чыккан. Давыл аның тиреләрен ерткалаган, йоннарын йолыккан, барыбер урыныннан кузгата алмаган.

Ниһаять, давыл узган, җил тынган. Берни дә булмаган шикелле ялтырап кояш килеп чыккан, җирдә тынычлык урнашкан.

Җәнлек-җанварлар да акрынлап яшеренгән урыннарыннан чыга башлаганнар. Җыелышып, давыл белән көрәшкән бүре янына килгәннәр.

– Бүре, җил агачларны кубарып ташлаганда, җирне су басканда, кыя-ташлар җимерелгәндә бары бер син генә урыныңнан кузгалмадың...

Канга батып беткән горур бүре еракка төбәлгән карашын алмый гына болай дип җавап биргән:

– Бу җир – минем Ватаным, ни генә булмасын, нинди генә бәхетсезлек сагаламасын, Ватанымны беркайчан да ташлап китмәячәкмен.

Бу сүзләр башка җанварларны уйланырга мәҗбүр иткән. Оятларыннан алар кире өннәренә борылып кайтып киткәннәр.

Яраланып, теткәләнеп беткән, барыбер давылга баш имәгән бүре, урыныннан кузгалмый гына җанварлар артыннан карап калган.

Бүренең башка Ватаны юк...

Ватан бер генә.





# Волк

Давным-давно в незапамятные времена по земле пронёсся страшный ураган, который выкорчевал с корнями деревья. Моря и реки вышли из берегов, обрушились горы. Много бед принёс ураган. Всё живое на земле спасалось бегством, ища прибежище. И только волк не устрашился урагана. Остался один на один с ним. Ураган разодрал на нём шкуру, окровавил его, но не смог сдвинуть с места жилистого волка.

Наконец ветер стих, выглянуло солнце, как ни в чём не бывало на земле вновь воцарилось спокойствие.

Собрались звери все вместе, пришли к волку и сказали:

– Волк, когда ветер выворачивал деревья, суша покрылась водой, рушились скалы и все искали спасения, ты один не сдвинулся с места.

Окровавленный волк гордо сидел, устремив взор вдаль, и ответил им так:

– Земля, на которой стою я, моя родина, и какое бы несчастье ни постигло меня здесь, я не покину её никогда.

Слова эти заставили призадуматься зверей, охваченные чувством стыда, они стали расходиться по своим берлогам.

Остался волк на том же месте израненный, изодранный, глядя вслед уходящим зверям.

У волка не было другой родины...

Родина только одна.



# Кайсы көчлерәк?

Бер патша яшәгән. Бу дөньяда иң көчлесе нәрсә икән дип уйланган ул. Шушы сорауга җавап табар өчен бөтен патшалыкка хәбәр тараткан, дөрес җавап биргән кешегә ярты патшалыгын вәгъдә иткән.

Күпмедер вакыттан патшага төрле катлаудан тугыз кеше килә: тегермәнче, өе янган крәстиян, балыкчы, тимерче, хәрби түрә, сәүдәгәр, тасма телле яучы, көдрә чәчле яшь егет һәм пеләш карт.

Патша аларны өстәл тирәли утырткан да соравын кабатлаган:

– Дөньяда иң көчлесе ни? Җавабыгыз дөрес булсын!

Тегермәнче әйткән:

– Барыннан да бигрәк җил көчле. Ул тегермән ташын әйләндереп кенә калмый, каты исә башласа, тегермән канатларын да сындыра ала.

Өе янган крәстиян килешмәгән.

– Җил исә дә туктый ул, тегермән канатларын да төзәтеп була, – дигән ул. – Барысыннан да көчлерәге – ут. Башкадан калса да, уттан калмый, минем бөтен йорт-җирем яным бетте.

Балыкчы үз чиратында крәстиян белән килешмәгән.

– Ут чыга да бетә ул. Су барыннан да көчлерәк. Язгы ташу вакытларында суның юлындагы бөтен нәрсәне агызып киткәнен күргәнегез юкмыни соң? Ярсый-ярсый да үз урынына кайта. Ярсыганда яман!

Балыкчыга тимерче каршы чыккан:

– Су язын гына көчле. Җәйге корылыкта су кибә, кышын бозга әйләнә. Барыннан да көчлерәге, һичшиксез, тимер. Тимер балта меңьеллык имәннәрне чабып аудара, тимер чакматаш кремнийдан ут чыгара, тимер туп дистә чакрымнарга ата, тимер кылычтан узган беркемнең дә исән калганы юк.

Кылыч һәм туплар турында ишетеп, хәрби түрә сикереп торган.

– Тимер күгәрә бит ул! Хәрбиләр барыннан да көчле, батыр сугышчылар теләсә нинди көчле коралланган дошман армиясен тар-мар итәргә сәләтле.

Бөдрә чәчле егет хәрби түрәгә каршы чыккан:



– Бер генә батыр да, ничек кенә көчле һәм кыю булмасын, чибәр кызларга каршы тора алмый. Чибәр кыз хәтта патшаны да әсир итә ала.

Сәүдәгәр егет сүзләренә көлгән генә.

– Матур кызларны акчага да сатып алып була. Барыннан да көчлерәге акча! Акчасы булса, ахмак та барин була, акчасы булмаса, барин ахмакка әйләнә. Акча булса, атакай ике тапкыр никахлаштыра. Акча төрмә ишекләрен дә ача, акча юлбасарларны да оҗмахка кертә. Акчасыз патша да яши алмый! – дип, кесәсендәге акча янчыгын чыгарып селкегән ул.

Яучы чираты җиткән. Тасма тел яучының теле телгә йокмас, сүз эзләп кесәгә кермәс. Шулайдыр да шул, алар бит ахмакка да әйбәт кыз табарга, иң күрексез булган кызга да әйбәт кияү таба белергә тиеш. Чынлап та, яучы үз телен мактый башлаган:

– Дөрес, акчага бар нәрсәне сатып алып була. Тик шунысы бар: акча бөтен кешедә дә юк бит. Иң көчлесе – тел! Юкка гына тел сөяксез димиләр. Ул акны – кара, караны ак итә. Иң кыю егетнең дә, иң матур кызның да башын әйләндерә. Тел белән алыпсатар алыпсатарны алдый, ялагайлар түрәләрнең күңелен нечкәртә, патшалар тулы бер халыкны буйсындырып тора. Телдән чыккан сүз күтәрә дә, үтерә дә!

Моңарчы бер сүз дәшми утырган зирәк аксакалга сүз биргәннәр.

– Синеңчә кайсы хаклы? – дип сораган аннан патша. – Кайсы көчлерәк?

– Миңа калса, дөньядагы иң көчле нәрсә – хак сүз. Хак сүз җил кебек әче, ут кебек кайнар, ташу суы шикелле көчле, кылыч кебек үткер. Хак сүз тимердән каты, ул батырларга көч бирә, өметсезләргә ышаныч өсти. Хак сүзне җиңәм дип, алыпсатар соңгы акчаларын түгә, тасма тел еландай боргалана. Хак сүз тутыкмый, картаймый, суда батмый, җирдә череми, ул мәңге яши. Хак сүздән башка халыкны берләштереп, үз артыңнан ияртеп булмый. Минем сүзем хак! Әгәр, падишаһым, синең сүзең дә хак икән, син миңа ярты патшалыгыңны бирергә тиеш!

Зирәк аксакал әйткән дә бит, патшаның теле генә тасма тел яучыныкы шикелле сөяксез булып чыккан. Ул картка ярты патшалыгын бирү түгел, якасыннан тотып куып чыгарырга боерган.

Аксакалның хак сүзе халыкка таралган. Ачуы кабарган халык патшаны тәхетеннән куып төшергән һәм океан уртасындагы кеше яшәми торган утрауга сөргән. Уйлансын әле патша, бәлки, хак сүздән дә көчлерәк әйбер булмавын аңлар.

# Что сильнее всего на свете?

Одному царю захотелось узнать, что всего сильнее на земле. Он оповестил об этом весь народ и человеку, который даст правильный ответ, обещал отдать половину своего царства.

Много ли, мало ли времени прошло, явилось к царю девять человек разного чина и звания: мельник, крестьянин-погорелец, рыбак, кузнец, военачальник, купец-барышник, сват-краснобай, молодой кудрявый парень и лысый мудрый старик.

Царь посадил их всех вместе и задал свой вопрос:

– Что сильнее всего на свете? Скажите, да так, чтобы было правильно!

Мельник сказал:

– Всего сильнее ветер. Он не только тяжёлые жернова легко вертит, но, если разбушуется, и крылья мельницы ломает.

Крестьянин-погорелец не согласился с мельником.

– Ветер подует, подует да утихнет, – сказал он. – А крылья мельницы сломает – не такая уж это великая беда, их можно починить. Всего сильнее огонь. От огня сгорел мой дом, сгорел дотла, даже головешки не осталось.

Рыбак в свою очередь не согласился с погорельцем.

– Огонь, рано или поздно, отпылает и погаснет. Сильнее огня вода. Разве вам не приходилось видеть, как по весне разливается вода и рушит на своём пути мосты и запруды, как размывает берега озёр, а потом уходит из них. Рыбаку возразил кузнец:

– Вода сильна лишь весной. В летнюю жару вода высыхает, а в зимние морозы превращается в лёд. Всего сильнее, конечно, железо. Железный топор рубит столетний дуб, стальное кресало извлекает из кремня огонь, стальная пушка бьёт на много вёрст, стальной меч рубит головы даже барам.

Заслышав разговор о пушках и мечах, вскочил со своего места военачальник.

– Ты забыл, что железо ржавеет! – напомнил он кузнецу. – Всего сильнее храбрый воин. Мои герои-храбрецы опрокидывают вражеские войска, если они даже вооружены пушками.

Молодой кудрявый парень возразил военачальнику:

– Как бы ни был силён и отважен герой, его может пленить красивая девушка. Никто не поднимет руку на красавицу. Она одним взглядом может покорить даже царя.

Купца-барышника такие слова парня рассмешили.

– Красивых девушек покупают на деньги. Всего сильнее на белом свете деньги! Если есть деньги, то и дурак может стать барином, а нет денег, то и барин становится дураком. За деньги поп дважды венчает. Деньги открывают тюремные ворота, деньги могут и для разбойника быть пропуском в рай. Без денег не может прожить даже царь! – тут купец вытащил из кармана мешочек с деньгами и потряс им.

Настал черёд высказываться свату-краснобаю. Ну, что сваты, что свахи, как известно, за словом в карман не лезут. Ведь их задача – даже за дурака-жениха уметь высватать хорошую девушку и последнюю дуру выдать за дельного умного парня. Язык у них должен быть хорошо подвешен. Свой язык и начал хвалить сват-краснобай:

– Это верно: за деньги можно купить всё-всё. Но ведь деньги-то водятся не у всех, надо ещё уметь добывать их. Всего сильнее на свете язык! Недаром про него говорят, что он без костей. Он может чёрное сделать белым. Может прельстить и героя, и красавицу. С помощью языка барышник обманывает барышника, льстецы задабривают грозных начальников, цари подчиняют себе целые народы. Слова, сказанные языком, могут и разрушать и воздвигать города и государства!

Последнее слово осталось за старым мудрым человеком.

– Кто, по-твоему, сказал правильно? – обратился к нему царь. – Что всего сильнее на свете? Скажи нам.

Старик сказал так:

– По-моему, сильнее всего – правдивое слово! Правдивое слово – остро и сильно, как ветер, горячо, как огонь, может заполонить, как вешняя вода, и пронзить насквозь, наподобие меча. Правдивое слово крепче железа, оно придаёт герою силы, укрепляет верой изверившихся, делает умными красивых девушек. Чтобы одолеть правдивое слово, барышнику приходится отдавать все свои барыши, а лжецу-краснобаю изворачиваться ужом. Правдивое слово не ржавеет, не стареет, не тонет в воде, не гниёт в земле, оно вечно молодо. Без правдивого слова нельзя править народом, нельзя его объединить в одно целое. Моё слово правильное! Если и твоё слово – о, царь! – твёрдое, то ты должен отдать мне половину своего царства.

Хорошо сказал мудрый старик! Но язык у царя, как и у свата-краснобая, оказался без костей, и он не только не отдал мудрецу обещанного полцарства, но и приказал вытолкать его взашей.

Всё же правдивое слово мудреца дошло до народа и распространилось по государству. Народ отнял власть у царя, а его самого сослали на необитаемый остров в океане. Чтобы подумал на досуге и понял, что нет на свете ничего сильнее правдивого слова.

# Кош томшыкларыннан сарай

Борын-борын заманда үзенең зирәклеге белән дан тоткан Сөләйман патша яшәгән. Аңа кешеләр генә түгел, җилләр дә, кошлар да буйсынган. Ул җир йөзендәге барлык кошларның һәм хайваннарның телләрен белгән дип сөйлиләр.

Хатынының туган көне алдыннан Сөләйман патша аннан нинди бүләк кирәклеген сораган.

– Кадерлем, миңа башка беркемдә дә булмаган бүләк бир, – дип җавап биргән хатыны. – Кош томшыкларыннан сарай сал!

Моны ишеткән Сөләйман җир йөзендәге бөтен кошларга томшыкларын китереп өяргә боерган. Бер көн дә узмаган, дөньядагы барлык-барлык кошлар Сөләйман патша сараена җыелганнар. Зур бөркетләрдән алып бик кечкенә колибриларга кадәр, чыпчыклар-сыерчыклар – барысы да килгән. Әлбәттә, берсенең дә томшыгыннан аерыласы килмәгән, тик ни хәл итәсең, патша боерыгына каршы барып булмый. Бары тик бер кош – үткер томшыклы чуар һөдһөд кенә күренмәгән. Сөләйман патшаның ачуы кузгалган.

– Кичекмәстән табарга һәм сараема китерергә! – дип боерган патша. – Боерыгымны тыңламаган өчен мин аны җәзага тарттырам!

Һөдһөдне тотып китергәннәр.

– Кая йөрдең? – дип сораган Сөләйман патша. – Ник көттерәсең?

– Бөек падишаһым, ачуланма, – дигән кош, – бу вакыт эчендә мин күп җирләрдә булдым. Чәчәкле бакчаларны һәм коры чүлләрне, калын урманнарны һәм иксез-чиксез диңгезләрне күрдем. Һәр барган җиремдә сиңа әйбәтрәк хезмәт итәр өчен акыл тупларга тырыштым. Сүз дә юк, мине җәзага тарта аласың. Тик иң элек минем вакытымны юкка сарыф итмәгәнемне раслап карыйм. Мин сиңа өч табышмак әйтәм. Җавабын әйтә алсаң җәзаларсың. Әйтә алмасаң, мине исән калдыр.

Кошлар гаҗәпләнүләреннән авызларын ачып калганнар. Шушы һөдһөд патшаның үзенә шарт куеп торсын әле!



– Синеңчә булсын, – дигән Сөләйман патша, – табышмакларыңны әйт. Барыбер синең акылың патша акылы белән ярыша алмас.

Һөдһөд әйткән:

– Менә беренче табышмак. Әйт әле, бөек падишаһым, кем беркайчан да тумаган һәм беркайчан да үлмәс?

Сөләйман патша уйлап та тормаган:

– Аллаһ, аңа мактауларыбыз булсын, – дип җавап биргән. Үзе эченнән генә: «Аллаһыбыз бөтен җан иясен ирекле итеп яралтты», – дип уйлаган.

Һөдһөд дәвам иткән:

– Икенче табышмак. Әйт әле, падишаһым, нинди сыеклык җирдән пар булып күтәрелми һәм күктән дә төшми?

Сөләйман елмаеп куйган, әлбәттә, җавабын белә ул табышмакның.

– Күз яше, – дип җавап биргән патша, – хәсрәтләнгәндә күзләрдән ага торган яшь.

Бу сорауга җавап биргәч, Сөләйман патша томшыкларының киселер минутын көтеп торган кошларга күз йөртеп чыккан. Хәсрәтләреннән башлары иелеп, күзләре мөлдерәп түгелергә торган кошларга карап, аның үзенең күзләренә дә яшь тулган. Шул вакытта үзенең зирәклеге белән дан тоткан Сөләйман патшаның башына уй төшкән. Кош томшыкларыннан сарай төзүнең бик акыллы эш булмавын аңлый башлаган ул.

Һөдһөд соңгы соравын бирергә әзерләнгән. Аның тавышы калтырап чыккан, чөнки кошка гомерен саклап калу өчен соңгы мөмкинлек булган ул.

– Бөек падишаһым, соңгы соравым: баласының авызына ризык салырлык дәрәҗәдә йомшак та, иң каты агачны тишәрлек дәрәҗәдә каты да әйбер нәрсә ул?

– Әлбәттә, томшык, – дип җавап биргән патша. Тирә-ягына күз йөртеп чыккан.

Чынлап та, кошларның һәрберсенә дә бик кадерле бит ул томшык дигән нәрсә.

Һөдһөд башын игән дә әйткән:

– Син җиңдең, падишаһым, үзең теләгәнчә җәзага тарта аласың. Мин синең иркеңдә, – дип, ул патшаның хөкем карарын көтә башлаган.

Сөләйман патша елмайган.

– Кадерле һөдһөд, – дигән ул, җыелган кошларның барысы да ишетерлек итеп, – дөньяга минем зирәк дигән даным таралса да, бүген син үзеңнең зирәк булуыңны күрсәттең. Мин бары тик синең аркада патшаларның да үз горурлыкларын җиңеп, хаталарын таныргa тиешлеген аңладым. Мин кош томшыкларыннан сарай салырга тиеш түгел икәнмен бит!

Бу сүзне ишетеп, кошларның шатлыкларыннан сикерәселәре, канатларын чабасы килгән, бары тик патша сүзен бүлдерергә кыюлыклары гына җитмәгән.

– Ә син, һөдһөд, җәзага түгел, зирәклегең өчен бүләккә лаек, – дигән Сөләйман патша.

Ул зәркәнчедән үзенекенә охшаган кечкенә таҗ ясатып алып, һөдһөднең башына кигертеп куйган.

Менә шул вакыттан бирле һөдһөд башында таҗ йөртә икән. Шул таҗга карап, калган кошлар үзләренең томшыкларын коткарган зирәк кошчыкны һәм Сөләйман патшаның аңа бүләген искә алалар.



# Дворец из птичьих клювов

Давным-давно жил на свете царь Соломон, который славился своей мудростью. Он повелевал ветрами и птицами, и те всегда исполняли его приказы. А ещё Соломон знал языки всех птиц и зверей, живущих на земле.

Когда приблизился день рождения жены Соломона, царь спросил у неё, какой подарок она хотела бы получить.

– Дорогой, я хотела бы иметь то, чего нет ни у одной другой царицы в мире, – ответила Соломону жена. – Построй для меня дворец из птичьих клювов!

Выслушав жену, царь приказал всем птицам, живущим на свете, прилететь в его дворец и отдать ему свои клювы. Не прошло и дня, как небо над царским дворцом заполнили тысячи птиц. Прилетели могучие орлы и крошечные колибри, синички и скворцы – все-все птицы, живущие на земле. Конечно же, они очень огорчились, ни одна птица не хотела расставаться со своим клювом. Но разве могли они ослушаться царя? И вот у дворца Соломона собрались все птицы, кроме одной. Только удод – маленькая пёстрая птичка с острым клювом – не исполнил царского приказа. Время шло, а птичка всё не появлялась. И тогда Соломон разгневался.

– Немедленно поймать удода и доставить его во дворец! – приказал царь своим слугам. – Я сурово накажу его за неповиновение.

Удода поймали, и он предстал перед Соломоном.

– Где ты был? – строго спросил птичку царь. – Почему ты заставил меня ждать?

– Великий царь, не гневайся на меня, – ответил удод. – За это время я побывал в разных странах. Я видел цветущие сады и мёртвые пустыни, густые леса и бескрайние моря. И всюду старался набраться мудрости, чтобы как можно лучше служить тебе. Ты можешь наказать меня, если такова твоя воля, но позволь мне сначала доказать, что я не напрасно потратил время. Разреши мне загадать тебе три загадки. Если ты их разгадаешь, поступай со мной как пожелаешь. Но если ты не сможешь разгадать хотя бы одну из этих загадок, то сохрани мне жизнь.

Все прочие птицы от удивления раскрыли клювы. Эта птичка осмелилась ставить условия самому царю! Но Соломону понравился храбрый удод.

– Будь по-твоему, – сказал он, – загадывай свои загадки. Всё равно твоя мудрость не может сравниться с мудростью царя!

И тогда заговорил удод:

– Вот тебе первая загадка. Скажи мне, великий царь, кто никогда не рождался и никогда не умирал?

Соломону не понадобилось и минуты на размышление.

– Наш Господь, да будет Он благословен, – ответил царь. И подумал при этом: «Наш Господь, который сотворил всех тварей на земле свободными».

Тогда удод продолжил:

– Вот тебе вторая загадка. Скажи мне, великий царь, какая влага никогда не поднимается от земли и никогда не падает с небес?

Соломон улыбнулся – он знал, как ответить на этот вопрос.

– Это слёзы, – сказал царь. – Слёзы, которые льются из глаз в минуту печали.

Разгадав вторую загадку, Соломон огляделся вокруг себя и увидел птиц, которые печально ожидали, когда у них отрежут клювы. Царь тоже опечалился, и его глаза наполнились слезами.

И тогда произошло кое-что необычное. Хотя царь Соломон был уверен в своей мудрости, ему на мгновение показалось, что строить дворец из птичьих клювов не очень-то мудро.

А удод снова заговорил, и на этот раз голос его дрожал – ведь у птички осталась только одна загадка, только одна возможность спасти свою жизнь.

– Скажи мне, великий царь, что обладает такой нежностью, что может вложить пищу в рот детёныша, и одновременно такой силой, что может пробить дыру в самом прочном дереве?

Царю Соломону не понадобилось много времени для ответа и на эту загадку.

– Конечно, это птичий клюв, – сказал царь. Он снова огляделся вокруг, увидел множество птиц и понял, какие это прекрасные создания и как дорог каждой птице её клюв.

А удод склонил свою головку и сказал:

– Накажи меня по своей воле, великий царь, потому что ты разгадал все три загадки.

И стал молча ожидать царского приговора.

Но Соломон только улыбнулся.

– Дорогой удод, – сказал он так громко, что его услышали все собравшиеся птицы, – хотя я и прославился своей мудростью во всём мире, истинно мудрым показал себя ты. Благодаря тебе я понял, что и царям следует смирять свою гордость и признавать свои ошибки. И я решил не строить дворец из птичьих клювов!

В этот момент всем птицам очень захотелось захлопать крыльями от радости, но они не осмелились прервать речь царя.

– А ты за свою мудрость заслужил не наказание, а награду, – сказал Соломон.

Он призвал к себе придворного ювелира и приказал ему изготовить для удода маленькую корону, похожую на ту, что украшает голову самого царя. И когда корона была готова, Соломон возложил её на птичью головку.

Вот с того самого дня и до нашего времени удод носит эту корону, чтобы все птицы помнили о награде царя Соломона и мудрости маленькой птички, которая спасла их клювы.



# ЭЧТӘЛЕК


Тылсымлы шәмдәл. *Азәрбайҗан халык әкияте* (Р. Сәлах тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
Аю Һанс. *Алман халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Хәйләкәр белән беркатлы. *Ассирия халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . 22
Һөнәр алтыннан кыйммәтрәк. *Әрмән халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . 28
Гадел казый. *Әфган халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Камыр батыр. *Башкорт халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 38
Каня. *Белорус халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Байкал һәм Ангара. *Бурят халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Кечкенә балык саран байны ничек алдаган. *Вьетнам халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . 57
Зирәк бәдәви. *Гарәп халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
Бетмәс-төкәнмәс әкият. *Грек халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Көләргеч. *Грузин халык әкияте* (Ә. Закирова тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Яшьлек сере. *Дагыстан халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Карт шайтаннарны ничек алдаган. *Ингуш халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . 84
Алдар Көсә Җирәнчәне ничек акылга утырткан. *Казах халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Ширмага ясалган юлбарыс. *Корея халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . 96
Төлке, юлбарыс, аю, бүре. *Кыргыз халык әкияте* (Л. Шәех тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . 100
Аучы белән сандугач. *Лезгин халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . 105
Нончык патыр. *Мари халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 110
Йолдызчы. *Месхетин төрекләре әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 118
Тегүче, аю, шайтан һәм Вирява. *Мордва халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . 125
Ипи-тоз бәһасе. *Осетин халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 135
Үлмәс Кощей. *Рус халык әкияте* (Т. Шакирова тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 140
Алтын балта. *Сүрия халык әкияте* (Р. Вәлиев тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 152
Падишаһ һәм Ходай бүләкләре. *Таҗик халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . 156
Ак Елан. *Татар халык әкияте* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Келуглан. *Төрек халык әкияте* (Р. Сәлах тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 169
Кечкенә булса да, төш кенә. *Төрекмән халык әкияте* (К. Миңлебаев тәрҗемәсе) . . . . . . . . 174
Кокорикок. *Удмурт халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 182
Янчык. *Украин халык әкияте* (Р. Гарипов тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Зөмрәт белән Кыйммәт. *Үзбәк халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . 192
Үзен үзе һәлак иткән. *Һинд халык әкияте* (К. Сабиров тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 200
Бүре. *Чечен халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
Кайсы көчлерәк? *Чуваш халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 210
Кош томшыкларыннан сарай. *Яһүд халык әкияте* (А. Галиева тәрҗемәсе) . . . . . . . . . . . . . 215

# СОДЕРЖАНИЕ


Волшебный подсвечник. *Азербайджанская народная сказка* (перевод Э. Ибрагимова) . . . . 9
Ганс-медведь. *Немецкая народная сказка* (перевод И. Стребловой) . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Хитрый и простодушный. *Ассирийская народная сказка* (пересказ А. Саввы) . . . . . . . . . . . . . 25
Ремесло дороже золота. *Армянская народная сказка* (перевод И. Карумян) . . . . . . . . . . . . . 31
Мудрый судья. *Афганская народная сказка* (пересказ А. Шарифа) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Камыр-батыр. *Башкирская народная сказка* (перевод М. Лося) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
Каня. *Белорусская народная сказка* (пересказ С. Маруденко) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 50
О Байкале и Ангаре. *Бурятская народная сказка* (пересказ С. Бубеевой) . . . . . . . . . . . . 55
Как маленькая рыбка обманула жадного богача. *Вьетнамская народная сказка* (перевод З. Дама) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Проницательность бедуина. *Арабская народная сказка* (пересказ Я. Алхамсса) . . . . . . . . . . 63
Бесконечная сказка. *Греческая народная сказка* (пересказ Г. Анастасова) . . . . . . . . . . . . . 69
Нацаркекиа. *Грузинская народная сказка* (перевод Э. Джалиашвили) . . . . . . . . . . . . . . . 76
Секрет молодости. *Дагестанская народная сказка* (пересказ А. Балафендиева) . . . . . . . . 82
Как старик шайтанов перехитрил. *Ингушская народная сказка* (перевод А. Мальсагова) . . . 88
Как Алдар-Косе перемудрил Жиренше. *Казахская народная сказка* (перевод Т. Дауренбекова) 93
Тигр, писанный на ширме. *Корейская народная сказка* (пересказ Р. Кима) . . . . . . . . . . . . 99
Лиса, тигр, медведь, волк. *Киргизская народная сказка* (перевод Э. Хуснутдиновой) . . . . . . 103
Охотник и соловей. *Лезгинская народная сказка* (пересказ З. Османова) . . . . . . . . . . . . . 108
Нончык-патыр. *Марийская народная сказка* (перевод Вл. Муравьева) . . . . . . . . . . . . . . . 114
Звездочёт. *Сказка месхетинских турков* (перевод Н. Цветиновича) . . . . . . . . . . . . . . . . . 122
Портной, медведь, чёрт и Вирява. *Мордовская народная сказка* (перевод Э. Померанцевой) 130
Цена хлеба-соли. *Осетинская народная сказка* (перевод К. Казбекова) . . . . . . . . . . . . . . . 138
Кощей Бессмертный. *Русская народная сказка* (обработка А. Афанасьева) . . . . . . . . . . . . 147
Золотой топор. *Сирийская народная сказка* (перевод А. Галиевой) . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Дары падишаха и Бога. *Таджикская народная сказка* (пересказ Х. Гадоева) . . . . . . . . . . . 159
Белый Змей. *Татарская народная сказка* (перевод А. Каримовой) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 165
Кельоглан. *Турецкая народная сказка* (перевод Э. Хуснутдиновой) . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
Мал, да удал. *Туркменская народная сказка* (перевод В. Чулкова, О. Давлетовой) . . . . . . . . 179
Кокорикок. *Удмуртская народная сказка* (перевод З. Весёлой) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 184
Кошелёчек. *Украинская народная сказка* (перевод Г. Петникова) . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Зумрад и Киммат. *Узбекская народная сказка* (перевод А. Мордвилко) . . . . . . . . . . . . . . . 196
Сам себя погубил. *Индийская народная сказка* (пересказ А. Гилькар) . . . . . . . . . . . . . . . 204
Волк. *Чеченская народная сказка* (пересказ Е. Сусаева) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Что сильнее всего на свете? *Чувашская народная сказка* (перевод С. Шуртакова) . . . . . . . 213
Дворец из птичьих клювов. *Еврейская народная сказка* (перевод В. Генкина) . . . . . . . . . . 219

Литературно-художественное издание

Составитель **Галияхметова** Айсылу Фарсовна

## Сказки народов Татарстана

Казань. Татарское книжное издательство. 2016

*На татарском и русском языках*

Әдәби-нәфис басма

Төзүчесе **Галиәхмәтова** Айсылу Фарса кызы

## Татарстан халыклары әкиятләре

Мөхәррирләре *А. Ф. Галиәхмәтова, Э. Р. Хөснетдинова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н. П. Клипова*
Корректорлары *Г. М. Хәбибуллина, А. Р. Миңнуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 12.10.2016. Форматы 84×100 $^1/_{16}$.
Басма табагы 14,0. Тиражы 2000. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://www.tatkniga.ru**
**e-mail: info@tatkniga.ru**

**Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:**
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

**Маркетинг бүлеге:**
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

**Интернет-кибет: http://www.tatkniga.ru**

«Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.



ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ

ТАТАРСКОЕ
КНИЖНОЕ
ИЗДАТЕЛЬСТВО